Мәдәни җомга

www.madanizhomga.ru

1995 елның июленнән башлап чыга

№ 33 (1398) 26 август 2022 ел

Татарстанда язылу индексы – П2355.

БЕЗ СОЦИАЛЬ ЧЕЛТӘРЛӘРДӘ:
madani_zhomga
madanizhomga
madani_zhomga

6

Татар халкы үзенең шанлы дастаннарына нинди мөнәсәбәттә, аларны тиешенчә зурлый беләме?

12

Башкортстанның Яңавыл районындагы кайчандыр гөрләп торган Байсар авылын язмыш җиле аямаган.

24

Рәссам, мөгаллим Айзирәк Мостафина укучыларының рәсем ясауга сәләте ачылуга һәрчак ихлас куана.

Дастаннарга яшьтәш Татарстан, Туган көнең булсын мөбарәк!

БЕР ҖӨМЛӘ БЕЛӘН...

- Россия хөкүмәте рәисе Михаил Мишустин фәрманы белән Федерация советында Татарстан вәкиле Ленар Сафин Казан федераль университеты ректоры итеп билгеләнде.

- Кукмара шәһәренең Туеш микрорайонында «Һидаят» тәрбия үзәге ачылды.

- «Татар сүзе» нәфис сүз бәйгесен үткәрү хокукы «Татарстан – Яңа гасыр» телерадиокомпаниясе карамагындагы «Шаян ТВ» балалар каналына тапшырылды.

- «Болгар мирасы» мәдәни-тарихи фонды Самара өлкәсенең Ширәй авылындагы Попов тавында ислам динен кабул итүгә 1100 ел тулуга багышланган истәлекле билге куйды.

- «Татар гармунчылары» халык ансамбле житәкчесе Ринат Мөхетдинов «Играй, гармонь» илкүләм фестивальдә Россия гармунчыларының Алтын унлыгына керде.

- Казанның Горький паркында Идел буе халыкларының яңа этник мәдәниятенә багышланган «Итил» фестивале узды.

- «Хәзинә» милли сәнгать галереясында фотограф Фәрит Гобәевнең «Искусство присутствия» дип аталган күргәзмәсе ачылды.

- Казанның «Чулпан» мәдәният үзәгендә һәм Ленин исемендәге мәдәният йортында ачылачак «Апуш» балалар татар театр студиясенә сентябрь башында кастинглар оештырылачак.

- Татарстанның халык артисты, җырчы Зәйнәб Фәрхетдинова 55 яшьлек юбилее уңаеннан туган ягы Азнакайда «Авыл көе» фестивале үткәрде.

ӘЙТКӘН СҮЗ – АТКАН УК

Илшат ӘМИНОВ, «Татарстан – Яңа гасыр» телерадиокомпаниясе генераль директоры:

«Хәзер яшьләр: «Татар телен гадиләштерергә кирәк, катлаулы сүзләр кулланмаска. Яңача, шәһәр телендә сөйләшик», – диләр. Мин бу идеяне хупламыйм, чөнки татар теле – бай тел. Әдәби телне аңлап җиткермәсәк тә, аңа тартылырга кирәк. Ул телне массакүләм чаралар сакламаса, аны башка беркем дә саклый алмаячак. Без чын, бай әдәби татар телендә сөйләшергә, язарга тиеш».

СЫНАМЫШЛАР

26 августка каен яфраклары саргайса, тиздән кырау төшәчәк ● 27 августта талгын җил иссә, көз аяз килә; давыл купса, сентябрьдә яңгырлы була ● 28 августка кадәр уҗымнарны чәчеп бетерү мәслихәт ● 29 августта (Чикләвек Спасы) торналар киткән булса, 14 октябрьдән суыклар башлана ● 1 сентябрьдә көньяктан җылы җил иссә, солы уңышы мул булыр, дип фаразлана.

КОЯШ СӘГАТЕ

Бүген кояш **4 сәгать 36 минутта** чыкты, һәм ул **18 сәгать 53 минутта** офык артына күмеләчәк. Көн озынлыгы – **14 сәгать 17 минут.** Алдагы җиде көн дәвамында тәүлекнең якты вакыты **31 минутка кыскарачак** һәм киләсе җомгада, ягъни **2 сентябрьдә 13 сәгать 46 минут** тәшкил итәчәк.

БЕЛЕП ТОРЫГЫЗ

26 август – язучы, тәрҗемәче Гариф Шакир улы Гобәйдуллинның (Гобәй) тууына 115 ел (1907–1983).

28 август – рәссам, Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Фиринат Габделхәй улы Халиковка 65 яшь (1957).

29 август – язучы Нурия Камил кызы Сәяровага (Сәйяр) 70 яшь (1952);

– курчак театры актеры, Татарстанның атказанган артисты Дилүс Дамир улы Хуҗәхмәтовка 35 яшь (1987).

1 сентябрь – үзбәк режиссёры, актёр, мөгаллим, Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Ташхуҗа Гомәр улы Хуҗаевның тууына 100 ел (1922 –1975).

СӘЛАМӘТЛЕК КӨН ДӘ КИРӘК

Августның магнитлы авыр көннәрендә хезмәттәшләрегез, якыннарыгыз сәламәтлегенә һәм, әлбәттә, үз-үзегезгә аеруча игътибарлы булыгыз. **Андый көннәрне исегезгә төшерәбез: 26-29 август.**

* * *

Гадәттә, яңа айдан айның беренче чирегенә кадәр **(27 август – 3 сентябрь)** организм кысылуга бара. Мондый көннәрдә үз-үзеңә физик йөкләмә бирү файдалы.

Шунысын да онытмагыз: **14 августтан 24 октябрьгә кадәр** үпкә һәм юан эчәклек актив булучан. Шушы вакыт аралыгында аларны ныгыту һәм дәвалау уңай нәтиҗәләргә китерә.

ҺИҖРИ БУЕНЧА 1444 ЕЛ

Бүген мөхәррәм аеның 28 нче көне

ЖАН АВАЗЫ

Иршад ГАФАРОВ,
Татарстанның атказанган укытучысы

ТУГАН ТЕЛ сакланырмы?

«Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге» елы тәмамлануга алты айдан артык вакыт үтте һәм ирексездән «Аның нәтиҗәсе нинди булды соң?» – дигән сорау туа. Билгеле, районнарда Сабантуйлар, конкурслар, җыеннар, конференцияләр һ.б. чаралар үткәрелде. Тик Татарстанда яки Россия төбәкләрендә яңа татар мәктәбе ачылды, дигән хәбәрне, ни кызганыч, бөтенләй ишетмәдек. Ә бит «тел саклауга» аз акча тотылмады. Ирексездән Габделҗаббар Кандалый шигыре искә төшә: «Түбәтәйне кыңгыр салып, абыстайны (дус-ишләрне) янга алып»... Татар, аның бердәмлеге, теле язмышы өчен җавап бирергә тиеш түрәләребез шактый төбәкләрдә булды. Ә татар телен саклауга багышланган күп гамәлләр күләгәдә калды.

Тюрколог А.Н.Гаркавец сүзләрен искә алыйк:«Мине немецларның истәлекләрне нәшер итүгә булган мөгамәләсе таң калдырды. Әгәр нинди дә булса китапта Германия турында бер яки ике сүз генә табылса да, әлеге истәлекне тулаем бастырганнар», – дип яза галим. Шәхсән үзем ике дистә елдан артык Мәскәү, Казан, Ульян архивларында, китапханәләрендә газета, журналлардан бөртекләп татарлар, аларның теле, диалектлары турында мәгълүматларны аерым картотекаларга туплый бардым. Шуның нәтиҗәсендә «Әдәби тел һәм мишәр диалекты» исемле китабым дөнья күрде. Китапның төп фикере халкыбызның бердәмлеген, телен саклау иде һәм бу юнәлештә минем китабым да кулланышка керә алыр иде. Ни кызганыч, тырышлыгым бушка булды, чөнки әлеге китапны укучыларга җиткерүдә ярдәм сорап Телләрне саклау һәм үстерү комиссиясенә, Милли шурага, Бөтендөнья татар конгрессына, Мәгариф министрлыгына, бүтән кайбер оешмаларга, җитәкчеләргә, шәхесләргә мөрәҗәгать итсәм дә, минем үтенечем җавапсыз калды яки акча юк дигән хәбәр генә ишеттем. Язганымча, җырлап-биюләр, күңел ачуларны оештыруга, кыйммәтле бүләкләр алырга акча табылса да. Ә телебезгә, татарларның бердәмлегенә басым ясау һаман дәвам итә. Бу юнәлештә милләттәшләребез үзләре дә читтә калмый. Галим А.Борһанов әйтүенчә, Пенза өлкәсендә без «мишәрләр» түгел, ә «көнбатыш татарлар» дигән яңа атама да барлыкка килгән икән. Гәрчә, әле 1926 елның 17 декабрендә үткән беренче Бөтенсоюз халык саны алу вакытында да мишәрләр бары тик Башкортстанда һәм Пенза губернасында гына аерым халык итеп күрсәтелгән. Мәсәлән, ул вакытта Башкортстанда 137,9 мең, Пенза губернасында 100,6 мең мишәр яшәгән дигән саннарны очратабыз. Ике регионда да мишәрләр туган телләре итеп татар телен атаган. Бу турыда хезмәтемдә мин тулырак итеп язган идем. Шулай ук Ульяновскида «без болгарлар» дигән төркем барлыгын да искәртәсе килә.

Дөрес, татар телен өйрәнүгә бөтен мөмкинлекләр тудырылган диючеләр дә табылды. Мәсәлән, Дәүләт Думасы депутаты И.Гыйлметдинов «дәүләт тарафыннан туган телләрне өйрәнүгә бернинди дә киртә куелмый» дип матур итеп әйтеп тә куйды. Билгеле, өченче тапкыр депутатлыкка сайландырылгач, матур сөйләп була инде ул. Тик мәктәпләр программасыннан милли компонетны алып ташлау, бердәм дәүләт имтиханын бары рус телендә генә тапшыру турындагы карарлар күктән төшмәде бит! Уку елының яртысында мәктәпләргә, гимназияләргә канун саклаучылар килеп, меңләгән укытучыны аннан куып җибәрүне дә өстән җибәрелгән карар нигезендә эшләнде дип искә алырга кирәк. Шуның өстенә, татар телен өйрәнү өчен бары тик ике сәгать кенә калдыру. Анысы да әле мәҗбүри түгел, шулай булгач без ничек итеп киртәләр юк, дип әйтә алабыз соң?

Бу үз чиратында милли телдәге мәктәп һәм гимназияләрнең эшләүдән тукталуына һәм татар, чуаш,удмурт һәм предмет буларак өйрәнелгән башка телләрнең юкка чыгуына китерергә мөмкин. «Оптимизация» дигән сәбәп белән ябылган, ә алар барысы диярлек милли мәктәпләр, укучылар рус телендә һәм рус мәктәпләре программасы нигезендә укый. Шуның өстенә, татар телендә укыган балаларны бер татар мәктәбе итеп берләштермиләр, ә рус мәктәпләренә кушалар. Бу – татар теленең юкка чыгуына туры юл. Монысы инде урындагы түрәләр кулы белән эшләнә. Шуның өстенә кайбер саф татар районнарында да татар мәктәпләренең булмавы гаҗәпкә калдыра.

Заманында К.Д.Ушинский: «Милли тел юкка чыкса, халык үзе дә бетә», – дип язган иде. Ул хәзерге мәгариф мәктәпләрендә бер дәрес тә бирмәгән түрәләрдән акылсызрак булмагандыр. Ул шулай ук башлангыч мәктәптә туган телдә укытуның кирәклеген искәртә, шул вакытта гына бала катлаулы сүз төркеме төзи ала дип ассызыклый. Бу уңайдан СССРның булачак тышкы эшләр буенча халык комиссары Г.В.Чичеринга туган сеңел тиеш булган С.В.Чичеринаның сүзләренә дә тукталасы килә. Ул 110 еллар элек Чүпрәле якларында да була һәм чуаш мәктәпләрендә имтиханнар уздыра. Аларның нәтиҗәсе турында түбәндәгеләрне яза: «...Туган телләрендә укытылган мәктәпләрдә имтиханнарны канәгатьләнерлек дәрәҗәдә биргәннәр, ә урыс мөгаллиме укытып, дәресләр дә фәкать рус телендә генә барган мәктәпләрдә имтиханнарны тапшыра алмаганнар». Бу сүзләрне шәрехләү кирәк түгел.

Әле дөрес сөйләүне дә дөрес хәл дип әйтергә шөһрәт итә алмыйбыз. Хәзер республикада күп телле мәктәпләрдә татар теле дә өйрәнеләчәк дип лаф орабыз. Күп телле мәктәпләр бишәү булачак дип фаразлана һәм Казан, Чаллы, Әлмәт шәһәрләре, Актаныш күз алдында тотыла. Ә авылларда? Шуның өстенә сүз чынында татар телен генә түгел, ә гуманитар фәннәрне генә булса да туган телдә өйрәтү турында, моны тормышка ашыра алырлык укытучылар әзерләү турында барырга тиеш. Совет чорында педагогик институтта махсус татар группалары бар иде, ә хәзер болар юк.

Берничә ел элек ТНВ каналында И.Кыямов белән ярты сәгатькә якын әңгәмә корган идек. Сүз күбесенчә милли мәсьәләләр турында барды. Тапшыру вакыты җиткәндә мин телевизор каршында идем инде,тик безне күрсәтү урынына 30 минут балыкларның тавышсыз гына авыз кыймылдатканын карап утырдым. Тапшыру техник сәбәпләр аркасында күчерелде дип аңлаттылар. Сәбәп икенче атнада аңлашылды, минем: «Классик университет белән педагогик университетны кушу татар мәгарифе һәм мәдәнияте өчен зур афәт булды», дип әйтүем кайсыдыр түрәгә ошамаган икән. Хәзер инде бу хәл «мәнди анасына»да яхшы аңлашыла.

«Европаның җирле телләр һәм аз санлы халыклар теле Хартиясендә» түбәндәгеләр язылган: «Максат – төбәк телләрен һәм аз санлы халыклар телләрен өйрәнү өчен җитәрлек формада һәм кирәкле күләмдә укыту һәм өйрәнүне барлык этапларда да тәэмин итү». Дәвамы: «Университет һәм бүтән төрле югары белем алуны аз санлы халыклар телендә дә тәэмин итәргә». Ә безнең илдә туган телләр гомуми белем бирү мәктәпләрендә дә юкка чыгу алдында тора! Шуны да искәртәсе килә: Россия 2001 елда Хартияне имзаласа да, Дәүләт Думасы аны расламады...

Заманында Козьма Прутков «мәсьәләнең тамырына» карарга кушкан. Безнең очракта сүз авыл мәктәпләре турында барырга тиеш. Белгәнемчә, язучыларның, шагыйрьләрнең күбесе авыл җирендә туып, белемне дә туган телдә алган. Шулай булгач, мең елдан артык тарихлы татар әдәбиятының киләчәге булырмы соң, дигән урынлы сорау туа. Шуның өстенә әдәби телдә сөйләшә алырлык сәхнә әһелләребезне дә югалтабыз бит. Бу хәл инде хәзер үк күренә башлады. Мәсәлән, Идел Болгарстанында Ислам дине кабул итүнең 1100 еллыгында Багдад илчеләре белән очрашу мизгеле сәхнәләштерелгән иде. Шунда Алмуш хан авызыннан «традиция», «цивилизация» дигән сүзләрне ишетү акылыма сыймаслык хәл булып яңгырады.

Кемнәрдер, күпме генә кабул итмәскә тырышса да, төрки-татарларның рус мәдәниятенә, бигрәк тә аның теленә зур тәэсир итүен кире кагу мөмкин түгел. Кайберәүләр моны монгол чоры белән бәйләргә тырыша. Безнең карашка, бу, беренчедән, әле монголларга кадәр үк руслар, болгарлар, кыпчаклар һәм бүтән халыклар арасында тыгыз икътисад, сәүдә, хәтта кан бәйләнешләре дә булу белән бәйле. Икенчедән, Монгол империясе кул астында руслар да, төрки халыклар да булган. Алар, билгеле, үзара кушылган һәм гасырлар буенча ут күршеләр булып яшәгән. Әлеге хәл бүген дә дәвам итә. Бу үз чиратында телләрнең бер-берсенә тәэсир итүнең табигый күренеш булуын раслый.

Моның эзләре аеруча рус телендәге татар алынмаларында сакланган. М.Г.Худяков терминнарның төрле өлкәләрдә булуын күрсәтеп үтә. Төрки лексикасы: 1) кешеләрнең җәмгыятьтә тоткан урыны турында; 2) сәүдә өлкәсендә, товар һәм акча атамаларында; 3) хәрби өлкәдә; 4) атчылык белән шөгыльләнүдә; 5) хайваннар һәм үсемлекләр дөньясына карата; 6) кием-салым атамаларында; 8) дин һәм бүтән өлкәләрдә киң таралган.

Хәзер дөньяда «мәйдан» сүзен белмәгән кеше сирәк, ә ул бит татар сүзе. Аны заманында М.Шолохов үзенең атаклы әсәрендә дә кулланган иде. Ә рус телендә татар сөйләменнән алынган сүзләр – санап бетергесез.

ЧЫНГА АШМЫЙ КАЛГАН МӨМКИНЛЕКЛӘР

Татарстанда Республика көне якынлаша. Ирексездән, хәтердә шул шаулы көннәр, халыкның 90 нчы еллар күтәренкелеге яңара. Гасырлар дәвамында иреккә сусап яшәгән милләттәшләребезнең, «явызлык империясе» чагыштырмача тиз һәм тыныч җимерелүенә куанып, дәртләнү кичергән һәм, киләчәккә зур өметләр баглап, ирек даулап йөргән чагы. Татарстанның дәүләт суверенитеты турында декларация кабул ителгән көн ул чакта анда иң зур тантана – Бәйсезлек көне буларак бәйрәм ителеп килде һәм, республика халкы да, хакимият тә моны уртак рухи күтәренкелек кичереп башкарды. Республика җитәкчелеге башлангыч чорда Декларацияне реаль эчтәлек белән тулыландыру юнәлешендә дә җитди генә адымнар ясады (халык ихтыяры белән Татарстанда президент сайланды; бәйсезлеккә омтылу халыкара хокук нормаларына туры китереп үткәрелгән референдумда хупланды; аның нәтиҗәләре буенча, Россия белән яңа мөнәсәбәтләр урнаштыра торган Конституция кабул ителде һ.б.). Тик түрәләр тиздән, Мәскәү басымы белән иблис коткысына бирелеп, ясалма (шәхси мәнфәгатьләрне өстен куя торган) кыйммәтләр системасына күчеп эш итә башлады. Бу юнәлештә тәүге адым Казан белән Мәскәү арасында вәкаләтләрне бүлешү турында килешүне имзалаганда ясалды һәм 90 нчы елларда яулаган үрләрдән чигенү инде даими төс алды. Үзе өчен актуальлеге беткәч, Мәскәү ул килешүләрдән бөтенләй дә баш тартты һәм мөстәкыйльлекнең эзе дә калмаслык итеп «чистартты». Яңа ел башыннан аның соңгы атрибутлары – Конституция суды һәм «президент» атамасы да бетерелә. Әмма 1992 елның 21 мартында үткән референдум хокукый көчен югалтмый. Чөнки юриспруденциядә ул халык ихтыярын билдерүнең иң югары формасы булып тора.

Танырга кирәктер, дөнья тотучыларның геосәяси планнары да ул чорда, Урталык җирләренең бөтенләнгән җимерү яисә үзенең сәясәт коралыннан баш тарту түгел иде. Киресенчә, алар шунда ук аны бүгенге хәтәр хәлләргә әзерләүгә кереште, шул ниятләрдә, хакимияттәгеләргә карт-бланш бирелде. Ә алар үз эшен җиренә җиткереп башкарды: «Чечня эффекты» аша илнең бөтенлеге саклап калынды; «кесә» парламенты ярдәмендә үзләренә кирәкле законнар кабул ителде һәм Конституциягә дә төзәтмәләр кертелде; үзгәрешләр исә илдәге төп халыкларга үз хокукларын парламентта яклау мөмкинлеге дә калдырмады һәм, нәтиҗә буларак, алар хәтта Төп Законда гарантияләнгән хокукларыннан да мәхрүм ителде (туган телләре чикләнде, мәгариф системалары җимерелде һ.б.); милли республикаларның да Конституциядә беркетелгән хокуклары чикләнде, нәтиҗәдә, илдә хакимият вертикале урнаштырылды; сайлау системасы исә ошбу «демократия институты»н имитацияләү һәм режимны саклау механизмына әверелде. Шулай итеп, Урталык җирләрендә милләтара мөнәсәбәтләрне федерализм принципларында урнаштыру мөмкинлеге гамәлгә ашмыйча калды.

Әлбәттә, кулдан ычкындырылган мөмкинлекләрне искә төшерүе бик җиңел түгел. Чөнки илдәге барлык халыклар да аннан фәкать оттырды гына. Отучылар кем икәнлеге дә мәгълүм. Ә чынга ашмаган өметләрнең аяныч нәтиҗәләре - һәммәбезнең дә күз алдында. Әмма алар, үткәннәрдән сабак алып, алга таба хаталарга юл куймау мөмкинлеге дә бирә. Форсаттан файдаланып, яңа мөмкинлекләр турында да уйланыйк. Узган язмаларда алар хакында сүз инде шактый ук җентекле булган иде. Кыскача, менә алар: милләт күләмендә яңа нигездә үзоешу; илаһият кануннары буенча яшәүгә күчүдә башкалар өчен үрнәк һәм әйдәп баручы көч булу (ә ул Коръәннең тәүхиди-иҗтиһади асылын ислам метафизикасы дәрәҗәсендә аңлауга һәм илаһият кануннарының бар Җиһан өчен уртак булуына корыла); метасәясәт (илаһи яшәешкә күчү сәясәте) югарылыгында (шундый проектларны гамәлгә ашырып) эш итәргә өйрәнү; Аллаһ юлында иҗтиһат кылу, Җирдә гармония урнашуга хезмәт итү. Мондый үзоешуның иң отышлы ягы – ул кешенең рух ныклыгына һәм милли вә дини аңына таяна. Димәк, түрәләргә бәйле түгел һәм аның чынга ашуы кешенең фәкать үзеннән һәм шәхси сыйфатларыннан гына тора. Географик чикләрне дә, дәүләт чикләрен дә белми, чөнки Аллаһ кануннары уртак, ә үзоешу реаль вә виртуаль дөньяларда аралашу аша корыла. Шуңа күрә мондый үзоешу инде милләт алдында зур мөмкинлекләр ача.

Фоат УРАЗАЙ.

Тукайга Тукай килде

Тукай районының Яңа бистәсендә Габдулла Тукайга һәйкәл ачылды. Тантанада Татарстан Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Марат Әхмәтов, Тукай районы башлыгы Фаил Камаев һәм Бөтендөнья татар конгрессының Чаллы бүлекчәсе рәисе Факил Сафин катнашты. Бронза сынны скульптор Халит Мингалиев иҗат иткән. Район башлыгы сүзләренчә, шагыйрь исемен йөрткән районда Тукайга беренче һәйкәл куела. Моңарчы Иске Дөреш авылында шагыйрьнең бюсты гына бар иде.

«Уңайлы шәһәр мохите формалаштыру» программасы буенча Яңа бистәсендә парк, республика программасы буенча җирле мәдәният йорты төзекләндерелде. Кунаклар яңа парктан ерак түгел урнашкан чаңгы-биатлон базасы белән дә танышты.

Театр яңалыклары

Камал театры «Җәйнең бер кичендә» дигән яңа проект башлап җибәрде. «Шәрык клубы» ишегалдында ачык һавада җәйге кинотеатр форматында «Үлеп яратты» (2011 ел) спектакле күрсәтелде. Шул ук көнне Әгерҗе районы Иж-Бубый авылы мәктәбе укытучылары өчен Камал театры директоры Илфир Якупов интерактив комплекс буенча экскурсия үткәрде.

Кәрим Тинчурин театрында «Ядәч! Исемдә!» спектакле Фәрһад Мөхәммәтҗанов катнашында соңгы мәртәбә куелды. Театрның яшь актеры МХАТ мәктәбе-студиясенә Игорь Золотовицкий һәм Сергей Земцов курсына укырга кергән.

Кариев театры Тверь шәһәрендә узачак Халыкара балалар спектакльләре фестиваленә әзерләнә. 9 сентябрь көнне кариевлеләр Тверь яшь тамашачы театры сәхнәсендә «Мио, минем Мио!» спектаклен күрсәтәчәк.

Әтнә театры үз радиосын эшләтеп җибәрде. Радиода спектакльләрдән җырлар, радиопостановкалар тыңлап булачак. Гомәр абый Мәрдановтан калган уникаль язмалар да файдаланылачак. Алга таба артистлар радио өчен шигырьләр, монологлар яздырачак. Радионы тыңлау өчен Әтнә татар дәүләт театрының рәсми сайтында радио бүлегенә керергә кирәк.

Әтнә театры яңа сезонын 2 сентябрьдә ача. 2, 3 һәм 23 сентябрь көннәрендә бирердә Чыңгыз Айтматовның «Ак пароход» спектакле премьерасы тәкъдим ителә.

Әлмәт театры балалар өчен тарихи спектакль куярга җыена. Премьера сентябрьдә көтелә. Ул Мәдәният министрлыгы биргән грант акчасына куела. «Татар сторис» дип аталган бу проект мәктәп балаларын татар тарихы белән таныштыру максатыннан эшләнелә.

Театр директоры Фәридә Исмәгыйлева яңа сезонда балалар өчен тагын бер яңа спектакль чыгачагын хәбәр итте. «Ак/соры бүре» спектаклен Алмаз Садриев куячак, ул ике телдә булачак.

Балалар өчен радио

Балалар өчен татар телендә «Саф» радиосы эшли башлады. Аны интернетта saf-radio.ru сайтында тыңларга мөмкин. Радиода тәүлек буена балалар өчен татарча җырлар, татар классик музыкасы, шигырьләр, әкиятләр, әдәби әсәрләр, татарча радиоспектакльләр һәм кызыклы тапшырулар яңгырый.

«Статистика буенча, дүрт мең ярымнан артык уникаль тыңлаучыбыз бар. Соңгы арада алар арта башлады. Төп тыңлаучыларыбыз – Татарстанда яшәүчеләр. Шулай ук Россия төбәкләрендә, Төркия, Испания, Германия, Гарәп Әмирлекләрендә, Америкада да тыңлыйлар. Төп максатыбыз – балалар өчен татар телендә сыйфатлы, кызыклы, файдалы контент булдыру», – диде радионың PR белгече Алсу Хәбибуллина.

Аның әйтүенчә, хәзер музыкаль һәм әдәби контент туплау, яздыру, татар балалар бакчалары, мәктәпләр, музыкаль мәктәпләр белән элемтәгә чыгу эше бара. «Музыкаль мөхәрриребез Чулпан Яркәева радионың контентына татар классик музыкасын да кертүне максат итеп куйды. Шуңа күрә радиода Рөстәм Яхин, Салих Сәйдәшев, Нәҗип Җиһанов, Фәрит Яруллин композицияләре дә яңгырый. Балалар өчен яздырылган җырларны туплау, авторлык хокуклары мәсьәләләрен хәл итәбез», – диде ул.

Радиода төрле тапшырулар чыга. Мәсәлән, «Безнең табиб» тапшыруын танылган педиатр Илдус Лотфуллин белән әзерлиләр. «Тапшыруларга балаларны да җәлеп итә башладык. Айсылу Леронның кызы Фәридә Гатина «Гөлбакча» тапшыруын алып бара, ул анда үзләренең яшьтәшләрен дә чакыра. Мәрьям Җаббарова «Белмәмеш» сәхифәсен әзерли», – дип аңлатты А.Хәбибуллина.

Тапшыруларны әзерләүгә тәҗрибәле белгечләр һәм эксперт белгечләр җәлеп ителгән. «Алар арасында: психология фәннәре кандидаты Люция Закирҗанова, биология фәннәре кандидаты Гөлнур Фәхруллина, логопед, нейропсихолог, тәрбиячеләр, укытучылар бар. Хәзерге вакытта «Гаилә» мәчете белән дини темага тапшырулар әзерлибез. Спорт, фән турында да тапшырулар ниятлибез», – ди ул.

Алсу Хәбибуллина бүгенге көндә иганәчеләр, партнерлар эзләү белән мәшгуль булуларын әйтте. Проектның җитәкчесе – Марат Галимов. Ул техник һәм оештыру мәсьәләләрен үз өстенә алган.

Зилә МӨБӘРӘКШИНА.

Кабан буенда милли бәйрәм

30 августта, Татарстан Республикасы һәм Казан шәһәре көнендә, Кабан күле яр буенда «Милли кием» фестивале узачак. Казанлылар бәйрәмгә милли төсмерле киемнәрдә килә ала, аларга чулпы һәм билбау бүләк итәчәкләр. Бәйрәм программасы 13:00 сәгатьтә башлана.

Монда кастом зонасы эшләячәк, анда казанлылар киемнәренә татар бизәге – лалә чәчәген төшерә алачак. Проектның авторы – Казан рәссамы һәм каллиграф Назим Исмәгыйлев. Бәйрәм программасына «XIX-XX гасырлар чигендә татар хатын-кызы дөньясы» һәм «Татар ир-егете дөньясы» экскурсияләре дә кертелгән. Экскурсияләр 13:00 һәм 15:00 сәгатьтә Мәрҗани ур., 8 адресы буенча урнашкан ресторанннан башлана.

13:00 сәгатьтән 17:00 сәгатькә кадәр бәйрәм мәйданчыгында күнчелек һәм туку буенча осталык дәресләре узачак. Чәк-чәк музее вәкилләре чокер-муенсаларны ничек милли итеп бизәргә мөмкин икәнен сөйләячәк.

Бәйрәм ахырында шәһәр халкы алдында Г.Камал театры оркестры чыгыш ясаячак. 18:00 сәгатьтә фестиваль кунакларына «Театр & Музыка. Яхин» дигән спектакль күрсәтеләчәк. 19:00 сәгатьтә фортепиано концерты. 19:30 сәгатьтә Г. Камалның «Беренче театр» пьесасы буенча Айдар Җәббаров режиссерлыгында фэшн-уку башлана. Анда артист һәм хореограф Нурбәк Батулла, рәссам Радик Мусин, блогер һәм стилист Алия Мифтахова, автор-башкаручы Фәүзия катнашачак.

1 нче биттә – Казанда Татарстан Республикасы көненнән бер күренеш.
Фото: yakutians.com

Фотограф бәйрәме

Казанда «Татар-информ» мәгълүмат агентлыгы фотографы, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Солтан Исхаковның юбилей күргәзмәсе ачылды. Дәрвишләр бистәсендәге Сәет-Галиев мәдәният сараенда тәкъдим ителгән экспозициядә фотографның 30 еллык иҗаты чагылыш тапкан 80 нән артык фотохезмәтен күрергә була.

Фотографны 70 яшьлек юбилее һәм күргәзмә ачылышы белән Татарстанның мәдәният министры Ирада Әюпова шәхсән котлады. «Солтан Исхаковның фотохезмәтләре җәмгыятьтәге социаль проблемаларны ача һәм алга таба хәрәкәт итәргә көч бирә. Сез – үз эшегезнең остасы, танылган профессионал. Казанда мәдәни проектларны тормышка ашырырга мөмкинлек бирә торган бик күп мәйданчыклар бар: Сәет-Галиев мәдәният сарае, Ленин һәм «Мәскәү» мәдәният үзәкләре... Сезнең иҗади проектларыгызны башка мәйданнарда да күрәсе килә», – дип теләкләрен җиткерде Ирада Әюпова.

Министр сүзләренчә, мәдәният үзәкләренең бурычы – кешеләрнең сәләтен ачарга, зәвыгын тәрбияләргә, аралашырга шартлар тудыру. «Татарстан элек-электән талантлы фотографлары белән данлыклы. Без аларга фотография сәнгатен танытырга ярдәм итәргә әзер. Киләчәктә грантлар булдырырга планнар бар», – диде министр тантанага җыелган фотографларга да мөрәҗәгать итеп.

С. Исхаковка Татарстан Мәдәният министрлыгының Мактау грамотасын һәм хезмәттәшләре исеменнән котлауларны Татарстан Фотографлар берлеге рәисе Рамил Гали тапшырды. Ачылу тантанасында Валерий Павлов, Рифхат Якупов кебек танылган фотографлар да чыгыш ясады.

Республиканың беренче Президенты, бүгенге көндә Татарстанның Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиевнең котлау сүзләрен аның ярдәмчесе Нурсөя Шәйдуллина укыды. Күргәзмәдә Минтимер Шәймиев портретын, легендар артист Шәүкәт Биктимиров, латыш фоторәссамы Янис Глейздс һ.б. танылган шәхесләрнең фотосурәтләрен дә күрергә мөмкин иде.

Лилия ГАДЕЛШИНА.

Яңа образны таныту

Татар балалары өчен яңа татар герое барлыкка килде. Татарстан Милли китапханәсендә «Туган батыр» брендын һәм китабын тәкъдим иттеләр.

«Туган батыр» – балалар һәм яшьләр арасында татар батыры образын торгызу һәм популярлаштыру буенча чараларны гамәлгә ашыручы бренд. Татар батырын сәнгать әсәрләрендә күрсәтү өчен, тарих, халык авыз иҗаты, әдәбият, бренд тудыру буенча белгечләр җәлеп ителде. Концепция милли геройга хас иң кыйммәтле сыйфатлар чагылыш тапкан татар мәкальләренә, әкиятләренә һәм бәетләренә үткәрелгән контент-анализ нәтиҗәләре буенча булдырылган.

Проектның максаты: үз халкының игелекле, көчле рухлы сакчысы һәм улы – батыр образын торгызу һәм популярлаштыру; яшьләрне милли гореф-гадәтләргә тарту, өлкәннәргә хөрмәт тәрбияләү, гаилә традицияләрен, туган телне һәм мәдәниятне саклап калу.

Татарстан мөфтие фикеренчә, хәзер заман балаларының күз алдында сокланырлык образлар булырга тиеш. Чөнки балалар төрле геройларны үзләре өчен үрнәк итеп ала, аларга охшарга тырыша.

«Күп командалар катнашында зур эш башкарылды. Мөфти хәзрәт безнең рухи остазыбыз иде, барысы да аның командасы белән берлектә башланды. Командага гаҗәеп шәхес Зөлфәт абый кушылды – ул әкият-легенда язды», - дип таныштырды проект авторы, «Туган авылым» милли комплексын гамәлгә куючы Радик Абдрахманов.

«Безнең проект балаларны, бөтен дөнья татарларын гына түгел, ә талантлы кешеләрне берләштерә ала», – дип дәвам итте ул.

«Безнең мәдәниятебез күпмедер дәрәҗәдә хәзер формалаша. Балаларыбыз асылыбызга туры килмәгән мультфильмнар карый. Без традицион кыйммәтләребезне традицион булмаган фикерләүдән сакларга тиешбез дип уйлаштык. Татар батыры образы шулай туды», – дип аңлатты Камил хәзрәт Сәмигуллин.

«Мин элеккеге традицион әкиятләрдән китәргә тырыштым. Кызганыч, әкиятләребезнең күбесе примитив язылган. Балалар аңласын өчен шулай эшләнгән ул. Минем балалар өчен генә түгел, аларның әти-әниләре өчен дә язасым килде», - диде язучы, «Туган батыр» китабы авторы Зөлфәт Хәким.

Китап татар телендә язылган, ул рус, гарәп, инглиз телләрендә дә булачак. Китапның дәвамы да языла башлаган. Китапка өстәп, комикслар китабы да, мультфильм да эшләнәчәк.



Радик Абдрахманов Туган батыр брендын алга этәрү өчен бөтен заманча алымнарның кулланылачагын ассызыклады. Сайт та эшләнә, социаль челтәрләр аша да балалар аудиториясен яулау планлаштырыла.

«Батыр батл» биетә

«Чулпан» мәдәният үзәге каршындагы мәйданда татар халык биюе буенча «Батыр батл» узды. Остаханәне Татарстан дәүләт җыр һәм бию ансамбленең балет артистлары Владислав Уткин һәм Данил Исхаков үткәрде.

«Чара биюче егетләрнең перформансыннан башланды. Алар татар биюе буенча үзара батл (бәйге) оештырды. Соңыннан батлны караучылар биючеләргә бәя бирде. Владислав Уткин дип җан атучылар аның командасына кушылды, Данил Исхаков өчен тавыш бирүчеләр – икенче командага. Биючеләргә баянчы Газинур Равилов һәм битмейкер, диджей Malsi music ярдәмгә килде.

«Мастер-класс барлык яшьтәге кешеләр өчен дә туры килә. Безнең әби-бабаларыбыздан килгән гореф-гадәтләрне, хәрәкәтләрне балаларыбызга җиткерү – төп бурычыбыз», – диде Владислав Уткин.

Катнашучылар «борма», «чалыштыру», «өчпочмак», «кадак кагу» кебек татар биюе хәрәкәтләрен өйрәнде. Остаханә күмәк бию белән тәмамланды.

Татарлар гына түгел, башка милләт кешеләре дә әлеге остаханәне чын күңелдән тамаша кылды, биюгә кушылды.

Остаханәгә биергә килгән Татьяна ханым чараны зарыгып көтеп алган. «Биюче егетләрнең биюенә сокланып карап тордык. Үзебез дә әлеге мастер-класста бик теләп катнаштык. Мондый чаралар күбрәк булсын иде, чөнки алар бар кеше өчен дә кызыклы», – диде ул.

«Хәрәкәттә – бәрәкәт» паркларындагы җәйге иҗат һәм спорт дәресләре Казанда узган ел башланып китте. Узган ел 14 дәрес узды. Быел «Ярмәк вагы» татар биюе нигезләре, чечетка, аэробика, татар халык биюе, брейк-данс, җырлы-биюле «Зәлидә» уены буенча мастер-класслар үтте. Татар биюе буенча тагын бер остаханә 30 августта узачак.

«Ибн Фадлан» премьерасы – Мәскәүдә

Мәскәүдә Татарстан Республикасы Мәдәният көннәрен Үзәк кинематографистлар йортында ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең «Хозур ТВ» телеканалы көче белән төшерелгән документаль-нәфис фильмы башлап җибәрде.

«Хозур» нәшрият йорты җитәкчесе Ришат Хәмидуллин, кино йортында җыелган тамашачылар алдында чыгыш ясап, «Ибн Фадлан» фильмының Болгар дәүләтендә ислам дине кабул ителүнең 1100 еллыгына багышланган чаралар кысаларындагы төп проектларыннан берсе булуын билгеләп үтте. «Беренчедән, бу фильм белән без мөселманнарның илебездә төпләнеп яшәүче халыклар булуын һәм Россиянең кабатланмас күпконфессияле мәдәниятен формалаштыруда мөһим роль уйнавын күрсәтергә теләдек. Икенчедән, тамашачылар Россиянең бай, уникаль, күп гасырлык мөселман мәдәнияте булган ислам дөньясының бер өлеше икәнен күрәчәк», – диде ул. Әлеге фильмда болгарларның ислам динен ирекле рәвештә кабул итүләрен һәм бөтен кешелек дөньясына күрсәткән динара тынычлык һәм татулык үрнәген күреп була.

«Ибн Фадлан» Казанда, Мәскәүдә, Санкт-Петербургта, Төмәндә, Әстерхан өлкәсендә, Татарстанның Әтнә районында, шулай ук Үзбәкстанның Бохара һәм Хива шәһәрләрендә төшерелгән. Фильмда Эрмитажда, РФ Дәүләт тарихи музеенда, Татарстан Милли музеенда, Мәрҗани фондында (Мәскәү), Болгар тарихи-архитектура музей-тыюлыгында, Биләр дәүләт тарихи-археология һәм табигать музей-тыюлыгында, Әлмәт картиналар галереясында яздырылган кадрлар да бар.

Премьерадан соң, авторлар һәм тамашачылар фильм турында фикер алышты.

● Шпицберген утравында Бөтендөнья орлык саклау урыны, яки Кыямәт көне саклагычы урнашкан. Ул 2008 елда киләчәктә глобаль катастрофа булса һәм кешелеккә авыл хуҗалыгын торгызу зарурлыгы туса дигән нияттән төзелгән. Төньяк полюстан 1300 км ераклыкта, җир астында 120 м тирәнлектә урнашкан саклагычта даими 18 градус салкынлыктагы өч бүлмәгә барлыгы 4,5 миллион орлык үрнәге сыя. «Үрнәк» дигәндә исә 500 әр орлык салынган герметик алюминий контейнерлар күздә тотыла.

● «Промрейтинг» агентлыгы тикшеренүеннән күренгәнчә, Татарстан ЮХИДИ камералары саны буенча Россиядә беренче урыны били. Республикада барлыгы 4723 камера куелган. Мәскәүдә аларның саны 3969 га җитә, өченче урындагы Свердловск өлкәсендә – 2705.

■ Атнаның сәяси мизгелләре

Шөбһәле вәзгыять

Һәр нәрсәдәге кебек, күрәсең, ялганда да чама белү кирәк. Билгеле бер чикне узгач, хәрәмзә инде үз ялганына үзе үк тә абына башлый. Охшаш хәлләр Украина тирәсендә дә күзәтелә. Әле күпләр хәтерли булыр, Минск килешүләре турында сүз барганда, Мәскәү үзенең Украинадагы низагта катнашучы як булмавын һәрчак искәртә килде. Шуңа да карамастан, бүген махсус хәрби операция бара һәм Россия аның БМО уставына туры китереп эшләнүе турында да әйтә. Донбасстан тыш, бу чорда ул Херсон өлкәсен һәм Запорожьеның да бер өлешен үз контроленә алды, аларда хәрби администрация урнаштырды, рубльне әйләнешкә кертте. Бу өлкәләрдә Россиягә кушылу турында референдум үткәрүгә дә әзерлек бара кебек...

Кызганычка, Украинадагы вәзгыять соңгы көннәрдә бөтенләй дә фаҗигале төс ала. Запорожье АЭСы тирәсендә киеренкелек инде бөтен Европага (шул исәптән Россиянең үзенә дә) куркыныч тудыра. ЕС һәм дөньяның 42 иле, әлеге вәзгыятьне җайга салу өчен, Россиядән АЭСны Украина контроленә кире кайтаруын таләп итте. Провокацияләр туктатылмый дигән сәбәп белән, бу мәсьәлә буенча Россия БМО КШның тагын бер ашыгыч утырышы җыелуына иреште. Әмма КШ әгъзалары АЭС тирәсендә киеренкелекне көчәйтүдә кабат Мәскәүнең үзен гаепләгән. Вәзгыятьне ачыклау өчен, МАГАТЭ миссиясе анда инде бу атнада ук килергә мөмкин.

Башка вакыйгалардан игътибарны журналистларның Украинадагы хәрби операция максатлары турындагы соравына В.Путинның: «Конечная цель мной обозначена – это освобождение Донбасса, защита этих людей, и создание усилий, которые гарантировали бы безопасность самой России. Вот и все», – дип җаваплавы да җәлеп итә. Кырым һәм Севастопольдә күзәтелгән дроннар һөҗүме, Мәскәү өлкәсендә автомобильдә барганда шартлатылган журналист Д.Дугина турындагы хәбәрләр дә вакыйгаларга шөбһә өсти. Соңгысы хакында җинаятьнең инде ачылуы, аны Украина махсус хезмәтләре оештыруы турында да әйтелде.

Фоат УРАЗАЙ.

Яшьләргә кыюлык хаҗәт

Быел Бөтендөнья татар яшьләре форумы җыенына меңгә якын яшьләр чакырылган. Зур чара алдыннан форумның шура әгъзасы, тарихчы Илнар Гарифуллин белән яшьләрдә милли хисләр тәрбияләү турында сөйләштек.

– Илнар, милли активистлар картая бара, ә хәзерге татар яшьләре сүлпәнлектә, йокыда хөкем сөрә кебек. Бездә Конституция хуплаган милли мәнфәгатьләрне яклый, хакимияткә үз сүзен җиткерә алырдай кыю егет-кызларыбыз бармы?

– Алар үзебезнең Бөтендөнья татар яшьләре форумында да җитәрлек. Төбәкләрдә эшләүче яшьләр аеруча үҗәт. Мәсәлән, ике ел элек Саратов өлкәсендә татар яшьләре берничә авылда татар мәктәпләрен ябылудан саклап калды. Алар массакүләм мәгълүмат чараларында бу проблеманы күтәреп чыкты, дәүләт органнарына күп мөрәҗәгатьләр юллады. Шулай ук, Екатеринбургтагы әйдаман Илдар Хәбибуллин тарихи татар биналарын саклау буенча зур эш алып бара. Хәлбуки, Татарстаннан читтә татарлыкны саклау җиңел эш түгел бит. Нәрсәнедер үзгәртү өчен нык үҗәт булырга һәм үз позицияңне яклый белергә кирәк. Татарстанда Айрат Фәйзрахманов, Бөтендөнья татар яшьләре форумы җитәкчесе Ленария Мөслимова милли мәсьәләләр буенча үз сүзләрен хакимияткә җиткерә һәм нәрсәнедер үзгәртүгә этәргеч ясый белә. Аннары татар блогеры Айнур Әхмәтовны да кыюлар сафына өстим. Ул Башкортстанда туган, хәзер гаиләсе белән Татарстанда яши. Ул да матбугат чараларында үз сүзен ачыктан-ачык әйтә. Кайбер фикерләре дәүләт оешмалары җитәкчеләренә ошап та бетми, ләкин Айнур чигенми...

Татарларның начар бер ягы бар: һәрвакыт нәрсәдәндер кыенсынабыз. Бу куркаклыктан яисә комфорт зонасыннан чыгарга теләмәүдән килә. Күбебез: «Ярамаган сүз әйтсәм, мине читкә кагарлар инде», – дип фикер йөртә. Башка халыклар исә кыенсынмый, үз мәнфәгатен кайгырта, үз максатын тормышка ашыра. Без үз-үзебезне «дисциплинар халык» дип юатабыз, аннары ник безнең проблемалар турында беркем дә сөйләми, безнең мәнфәгатьләрне беркем дә кайгыртмый, дип аптырап утырабыз. Яшьләр үзебезгә кирәген сорарга, тиешлесен таләп итәргә өйрәнергә тиеш.

– Башкорт яшьләре һәм күрше республикада туып-үскән татарлар милли хәрәкәттә үзләрен кыюрак тота кебек. Бу ни өчен шулай?

– Казан ханлыгы җимерелгәч, күп кенә Казан арты татарлары, чукынырга теләмичә, Татарстанның көнчыгышына һәм Башкортстанның көнбатышына күченгән. Динен саклап калу өчен үз җирен кыю кешеләр генә ташлап китә ала. Күндәм, вәзгыятькә ераклаша ала торган кешеләр, гадәттә, күченми. Шуңа күрә бу җирлектә буйсынмас халык күп җыелган. Икенчесе – татарларның башкортлаштыру сәясәтенә каршы көрәштә чыныгуы белән бәйле. Бу сәясәт бер гасырга якын бара инде. Аңа каршы тору рәхәт булмаса да, татарларны чыныктыра. Башкортларда милли идеология дә көчле. Алар шуның белән башка халыкларга да үрнәк күрсәтеп тора. Чуашларның да, мариларның да иң көчле милли активистлары Башкортстанда туып-үскән. Бүгенге көндә төбәкләрдәге татар милли оешмалары җитәкчеләренең күбесе Башкортстаннан чыккан.

– Ә татар яшьләре форумы нинди башлангычлар белән танылды?

– Мәсәлән, 2017 елда татар теле өчен көрәшне безнең активистлар башлап җибәрде. Бу хәрәкәткә төрле милләт активистларын җәлеп итеп, илкүләм туган телләрне яклауны оештырып җибәрә алдык. Соңгы елларда Башкортстанда татар теле белән бәйле проблемаларны күтәрдек. 2019 елда Башкортстанда татар диктантын тыярга тырыштылар. Без нык торгач, тыя алмадылар. Башкорт теленең төньяк-көнбатыш диалекты дигән уйдырманы җәелдерүгә каршы тордык... Безнең уңышлы эшләп килгән даими проектларыбыз да бар. Шуларның берсе – «Ачык университет». Татар теле фәннән чыгып барганда, туган телдә белем алуны саклап калырга, татар телендә лекцияләр укырга кирәк. Кызганыч, татар теле хәзер югары уку йортында ишетелми диярлек. Хәтта мәктәптә дә ул кими бара. «Ачык университет» проекты аша без татар телендә лекция укый алырдай кешеләрне җәлеп итеп, туган телдә белем бирүне сакларга омтылабыз. Моннан тыш, без «Печән базары», «Мин татарча сөйләшәм», «Таткультфест» кебек чаралар үткәрәбез.

– «Ачык университет»ның укучылары бармы?

– Әлбәттә, бар. Укулар хәзер дә дәвам итә. Пандемия башлангач, без онлайн форматка күчтек. Аңарчы лекция тыңларга 30-40 кеше килә иде. Онлайнга күчүнең тагын бер сәбәбе – аудитория табу кыенлашты. Үзебезнең даими урын булмагач, һәр лекциягә яңа урын эзләргә туры килә. Шуңа күрә яшьләргә мәдәни үзәк кирәк дип әйтәбез дә инде.

– Анда уку түләүлеме?

– Бушлай. Без аны иганәчеләр ярдәме белән оештырып җибәргән идек, соңгы ике елда грант акчасына тормышка ашырабыз. Проектның төп идеологы Айрат Фәйзрахманов икәнен әйтеп үтик.

– Бөтендөнья татар яшьләре форумы күпме кешене берләштерә?

– Җыеннарга бер меңгә якын кеше килә. Быелгы җыенга тугыз йөз кеше чакырабыз. Ул 28-30 августта булачак. Соңгы мәртәбә шундый зур форматта 2018 елда үткән иде.

– Җыенга делегатлар нинди принцип буенча сайлап алына?

– Төбәкләрдәге яшьләр оешмаларына квоталар бүлеп бирәбез. Татарлар яшәгән төбәкләрдән күбрәк кеше чакырырга тырышабыз. Татарстаннан, Башкортстан һәм Мәскәүдән катнашучылар күп булачак. Татар яшьләре оешмасы булмаган төбәкләрдән делегатларны милли-мәдәни оешмалар аркылы чакырабыз.

– Бөтендөнья татар яшьләре форумы «тусовка»сына ничек эләгергә була?

– Берәр милли иҗтимагый оешмада яисә татарлар тормышында актив эшчәнлек алып барырга кирәк. Милли хисләр белән янып йөрүче журналист яисә блогер булсаң, милләткә файдалы проект башкарсаң, үз арабызга чакырабыз.

Элегрәк иҗтимагый оешма чараларына җырчылар чакыру традициясе бар иде. Янәсе, ул популяр. Кайберләре чарага килеп тә тормый, ә кайберләренең татар җәмәгатьчелегенә берникди эш күрсәткәне юк. Мин андый «туй генералларын» чакыруның мәгънәсен күрмим. Бервакыт конгресс чараларында җырчы Альбина Шаһиморатова катнашып йөргән иде. Бер интервьюсында чит илгә барганда үзен татар итеп хис итмәве турында сөйләп, безнең биткә төкергәндәй итте. Татар оешмаларына андый кешеләрнең кирәге юк. Аның онытканда бер татарча җыр башкаруыннан милләткә файда килми.

– Быелгы җыенда нинди яңалык, үзгәреш көтеләме?

– Форумның шурасында, ягъни аның идарәсендә бүген сиксәнгә якын кеше бар. Без аны кырык-иллегә калдырырга ниятлибез, чөнки кеше саны арткан саен оештыру мәсьәләсе кыенлаша бара. Кайбер әгъзалар олыгайды. Бу яшьләр оешмасы булгач, утыз биш-кырыктан артканнар безнең форматка туры килми. Олырак яшьтәге берничә генә кеше бар, ләкин аларга әлегә алмаш юк.

Быел төп тема төбәкләрдә татар яшьләре оешмаларын торгызып җибәрүгә багышланачак. Яшьләрдә милли идеологияне ныгытуга басым ясаячакбыз, чөнки татар милли оешмаларында бу төп проблема. Милли идеология кризиста. Үткәргән чараларның эчтәлегенә, аларның максатына игътибар итми башладык. Сабантуйның да миллилеге югала дип юкка гына чаң сукмыйбыз бит. Күптән түгел Бөтенроссия татар теле һәм әдәбияты укытучылары форумы узды. Анда төрле чыгышлар яңгырады, мастер-класслар узды, ләкин яңа идеяләр булмады. Бөтен төбәкләрдән җыелган татар теле укытучылары исеменнән Мәскәүгә милләт өчен мөһим берәр мөрәҗәгать юлларга булыр иде.

Рифат КАЮМОВ.
intertat.tatar

Татар чынбарлыкны танырмы?

«Тормыш өслүбе – мәдәни код» II халык иҗаты һәм гамәли бизәү сәнгате этно-fashion фестивале кысаларында узган дастаннар турындагы «түгәрәк өстәл»дә байтак проблемалар күтәрелде. Берүзе бер институт эшен башкарган язучы, фольклорчы галим Нәкый Исәнбәтнең сиксән процент хезмәтләре ник әлегә кадәр бастырылмаган? Ә башкортларның «Урал батыр» дастаны 20 телгә тәрҗемә ителгән, аңлатмалар, чыганаклар белән бик әйбәтләп дөньяга чыгарылган һәм аны халыкка таныту өчен төрле фестивальләр үткәрелә, чичән мәктәпләре эшли. Безнең «Идегәй» дастаны кайчан шундый бәхеткә тиенер? Һәлакәт алдында торганда халыклар дастаннарга таянып исән калырга мөмкинме? Татарстан, Башкортстан, Кыргызстан, Казахстан, Пермь крае галимнәре шушы һ.б. сорауларга җавап эзләде.

Филология фәннәре докторы, аксакалыбыз Марсель Бакировның чыгышыннан бер иш дастаннар җәһәтеннән галимнәребезнең һаман бер фикергә килә алмаулары аңлашылды. Мәсәлән, галим исемнәр охшашлыгына гына таянып «Чура батыр» дастанының прототибы дип морза Чура Нарыковны атау җәһәтеннән ризасызлыгын белдерде. «Чура батыр» кырык батыр турындагы «Шура батыр» шәлкеменең бер өлеше булarак, казахлар һәм калмыклар арасында сугышлар алып барылган Көнбатыш Казахстан җирләрендә барлыкка килгән, әсәрдә телгә алынган шәһәр Идел буендагы Казан түгел, Семиречьедагы бер шәһәр, дип үз фикерен җиткерде. Чура Нарыков Мәскәү яклы булып, Казанга яу белән килүләрен сорап, ике тапкыр Явыз Иванга сәрән салган. Ахыр чиктә гаиләсен, хезмәтчеләрен, сакчыларын ияртеп, Казаннан чыгып качкан һәм Сафа-Гәрәй тарафыннан үтерелгән, дип язды тарихчылар. Бер чыганакта, бер истәлектә дә Казанны яклап сугышкан батырлар арасында Чура Нарыков исеме очрамый. Шуңа күрә Чура батыр билгеле бер шәхес түгел, Казанны яклап сугышкан яугирләрнең җыелма образы булырга тиеш, дип фикерен тәгаенли төшә.

Хәер, галимнәребезнең бер фикергә килә алмавы элек-электән күзәтелгән. Татар галимнәре бердәм булса, тел, әдәбият белгече, драматург, фольклорчы Нәкый Исәнбәтнең мирасы бүген шундый аяныч хәлдә булыр идемени? Аның исемен аклау һәм әсәрләрен нәшер итү эшен филология фәннәре кандидаты Миләүшә Хәбетдинова берүзе күтәрергә тиешме? Миләүшә ханым Н.Исәнбәтнең, Уфада «Хөсәения» мәдрәсәсендә укыганда ук, 10 яшьлек чагында 110 табышмак туплап чыгаруы, «Шүрәле»не язып алуы, аңа иллюстрацияләр ясап «Хөсәения» мәдрәсәсе өчен «Шүрәле» китабын әзерләве, шул ук елны «Шүрәле» шигырен иҗат итүе турында сөйләде. Казанда «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә укыганда Н.Исәнбәт Х.Бәдигыйнең фольклор түгәрәгендә белемнәрен тагын да тирәнәйтеп, 1928 елда Башкортстандагы күренекле чичән Сукыр Фәррах (Дәүләтшинның) авызыннан сөйләткәннәрне җыентык итеп бастыра, кереш сүзендә исә чичән сәнгатенең үзенчәлекләрен билгели. Тагын ике елдан янә бер китаплык язмаларын күтәреп, Исәнбәтне эзләп, Сукыр Фәррах үзе Казанга килә. 1940 елда «Совет әдәбияты» журналында «Идегәй» дастанының 500 еллыгы уңаеннан мәкаләсендә чичән һөнәренең асылын аңлатып кына калмый, Алтын Урда заманнарыннан башлап атаклы чичәннәрнең исемнәрен дә китерә. Галимә диссертация язучыларның Исәнбәт эзләп тапкан бу мәгълүматларны файдаланып та, исемен һәм чыганагын күрсәтмәве җәһәтеннән борчылуын белдерде. Исәнбәтнең «Идегәй» трагедиясендә чичән образын әдәбиятка кертүе, «Җирән чичән һәм Карачәч Сылу» пьесасында исә чичән хатын-кыз образын барлыкка китерүе шулай ук чичән сәнгатен халыкка таратырга ярдәм итте. 1959 елда чыгып, бөтен Советлар Союзы буенча таралган «Татар халык мәкальләре» берничә мәртәбә кабат бастырылды һәм бүген дә тиңсез хезмәт булып кала. Аннан соң дөнья күргән татар халык табышмаклары арасында чичәннәр турында табышмаклар да тупланганын искә алсак, галимнең чичән сәнгатен һәрьяктан өйрәнгәне һәм танытырга омтылганы яхшы күренер.

Үткән гасырның җитмешенче еллар уртасында басылып чыккан «Мырау батыр мажаралары»нда исә галим Н.Исәнбәт чичән образын балалар әсәрләрендә куллану үрнәген күрсәтте. 1924 елда ук Башкортстанда «Идекәй һәм Морадым» дастанының өч төрен язып кайткач, 1940 елга Н.Исәнбәтнең шулар нигезендә «Идегәй» дастанының татарча һәм башкортча җыелма текстларын эшләп тапшыруына карамастан, татарларның да, башкортларның да галимнең бу хезмәтен әлегә кадәр тиешенчә бәяләмәүләре башка сыймый. Башкортстанда башкорт булып язылмаганы өчен каксалар, үзебездә Н.Исәнбәтне тирән белеме, киң карашы, эрудициясе өчен күрә алмаганнар булса кирәк. Галимнәребез арасында дуслык, фикердәшлек булса, 1944 елда «Идегәй» дастанының язмышын хәл иткән җыелышта Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать галимнәре, «Идегәй»не Исәнбәт табып алып кайтып тапшырды, ул җавап бирсен дип, бер үзен авыр хәлдә калдырмаган булыр иде. Дошман белән күзгә-күз калса да, Нәкый ага үзе исә бер вакытта да «Идегәй»дән баш тартмаганы билгеле. 1990 елларда да Исәнбәт белән мәчеле-тычканлы уйнаган сыман, аны авторлык хокукыннан мәхрүм итүләре, картаймыш көнендә аксакалны һәм аның гаиләсен мәхкәмә юлында йөрергә мәҗбүр итүләрен көнчелек димичә, тагын ни дип атарга? Исәнбәткә бу газаплар нәрсә өчен? Бөек Ватан сугышы алдында торганда, татарны берләштерүче Идел-йорт образын торгызганы өченме? Филология фәннәре кандидаты М.Хәбетдинова Исәнбәтнең исемен акларга алынмаса, бу сораулар бүген дә күтәрелмәс иде әле...

Башкортстанның М.Акмулла исемендәге педагогика университетыннан филология фәннәре кандидаты Шәүрә Шәкүрованың чыгышыннан галимнәр һәм дәүләт эшлеклеләре бер фикердә булса, байтак эшләр майтару мөмкин булуы аңлашылды. Анда «Урал батыр» дастаны Башкортстанның җиде могҗизасының берсе дип игълан итеп кенә калмыйча, ТЮРКСОЙның матди булмаган мирас исемлегенә (башкорт балы, курай, Салават Юлаев һәйкәле һ.б. белән бергә) кертүгә ирешкәннәр. Акмулла исемендәге университетта башкорт фольклорын фәнни өйрәнү үзәге ачып, мәктәпләр өчен белгечләр һәм методик материаллар әзерләү эшен җайга салганнар. Шул ук университетта чичәннәр мәктәбе эшли, республикада аннан башка да мәктәпләр байтак. Без «Идегәй» дастанын язып алып әзерләгән Нәкый Исәнбәтнең авторлык хокукларын торгызып, әсәрне ул язганча нәшер итә алмыйча вакыт сузып йөргән арада, Стәрлетамакта драма театры «Урал батыр»ны язып алган һәм шуның өчен байтак еллар әзерлекләнгән Мөхәммәтша Буранголов турында «Ашкадар» исемле спектакль иҗат итте. Аның бер сюжет сызыгы Буранголов язмышы булса, тагын берсе – «Ашкадар» пьесасы. «Урал батыр»ның сәхнә тормышына күз салсаң, башың әйләнә. Ул өч тапкыр курчак театрында, ике тапкыр Башкорт дәүләт драма театрында куелган. 2018 елда Якутиянең танылган режиссеры Андрей Борисов куйганын Казанга гастрольгә дә алып килгәннәр иде. Спектакльдәге байлыкка-муллыкка, режиссерның иҗат куәсенә, хыял байлыгына ис китте. Моннан тыш «Урал батыр» буенча дүрт мультфильм, «В поисках Акбузата» исемле дүрт серияле фәнни-популяр фильм төшерелгән. Рус драма театры рок-опера куйган. Сибайдагы «Чулпан» балалар эстрада театры «Урал батыр» буенча сәхнәләштергән заманча кызыклы спектакльне Казаныбызга да алып килгән иде. Заманга яраклаштырсалар да, асылын җуймаганнар, дип тел шартлаткан иде анда да Казан тамашачысы. Урал батырга гына түгел, Башкортстанда Акбүзатка да хөрмәт зур. Былтыр Өлфәт Кубагушев эскизы буенча атның сынын бастырып куйганнар. 2015 елда 28 километр озынлыкта 7 тукталышлы «Урал батыр билбавы» исемле туристик маршрут булдырганнар. Дуслык, бердәмлек буй ашмас биеклекләргә дә күтәрә. Пегас йолдызлыгында башта - Урал батыр, берничә елдан соң Акбүзат исемле йолдызлар барлыкка килү моңа дәлил. Бездә берәр рок музыканты «Идегәй» дип җырлаганын күргәнегез бармы? Рок җырчылары бездә никтер үзләре аерым «җенләнә». Уфада рок фестивальләренә кадәр «Урал батыр» исеме, шигаре, әләме белән үткәрелә. «Урал батыр» истәлегенә корылган тарихи-мәдәни музей-тыюлык бинасы гына ризасызлык уятты, чөнки тышкы кыяфәте белән безнең булачак Камал театры бинасына охшаган тыюлык күңелдә академия театрыбызны үзәктән ераккарак күчерү белән бәйле тискәре фикерләрне яңартты.

Былтыр бөтендөнья фольклориадасын Башкортстанда уздырулары гына җитмәгән, 2024 елда башкортлар балалар бөтендөнья фольклориадасын үзләрендә уздырырга план кора...

Кыргызстаннан филология фәннәре докторы, «Манас» һәм Чыңгыз Айтматов милли академиясенең президенты, үзе манасчы Талантаалы Бакчиев манас үрнәгендә, дастаннарның зур көчкә ия булып, авыр вакытта кешегә ярдәм итүен дәлилләде. Егетләрне Бөек Ватан сугышына озатканда манасчыларның чакырулары тарихта теркәлгән. Гражданнар сугышы ветераны С.Каралаевның сугышчыларны җиңүгә рухландыру өчен ял вакытларында манас башкаргалы шулай ук кәгазь битләренә язылып калган. Элгәре вакытларда мәрхүмнәрне күмгәндә, ашларда да кыргызлар манас башкара торган булса, вакыт үткән саен, бу гадәт юкка чыга барып, бүген зур дәүләт эшлеклеләре, атаклы шәхесләрнең җеназаларында гына күзәтелә.

(Ахыры 11 нче биттә).

Гөлфия ИСХАКОВА

Бу эссе җәй үтмәс сыман иде, – Күрәсезме, алма коела?..

КАБАТ КАЙТСАҢ ИДЕ ЯШЬЛЕГЕҢӘ...

Бу эссе җәй үтмәс сыман иде, –
Күрәсезме, алма коела?
Каеннарда сары яфрак күренә,
Искән җилләр усал тоела.

Бакчаларда инде көз гөлләре,
Кашкарыйлар кыса күзләрен.
Хушлашалар җәйләр яме белән,
Әйтәлмиләр бары сүзләрен.

Яшел үлән, сутын югалткандай,
Алыштыра җәйге киемен.
Их, күрмәссең инде яланнарда
Яшел таҗлы печән өемен!

Кошлар тынган, сайрау ишетелми,
Балалары канат үстергән.
Ишетелми күл буенда чыр-чу,
Истә генә калган су кергән.

Табигать тә йөзен алыштыра,
Келәм җәя кара җиренә.
Сары сарган, әби-чүәк җиһан
Алтын бишек булып күренә.

Ел фасылы көзгә кереп бара,
Килер өчен кабат әйләнеп.
Кайтсаң иде кабат яшьлегеңә,
Алда килер язга бәйләнеп.

* * *

Дусларыма теләк телим иртә таңнан.
Уйлавымча, йөз җыермас беркем аннан.
Яхшы уйлар уйлап һәркем уяныр да,
Онытмас ул кояш сыман елмаерга.

Кошлар җырлап тирә-юньгә бәхет теләр,
Шатланышып яңа көнгә кызлар көләр.
Җәйге гөлләр күңелләргә ямь иңдерер,
Җем-җем килеп таң чыклары сөендерер.

Өләшик без шатлыкларны дус-туганга,
Рәхмәт әйтик бу дөньяда без булганга.
Изге теләк тели-тели көнгә керик,
Сөйгән ярга, якыннарга бәхет телик.

БӘХЕТ

Бәхет ул гел минем янда,
Елмаеп кына тора.
Бар дөньямны нурлы итә,
Язмышны меңгә бора.

Бәхет ул – син булу янда,
Балалар, оныкларым.
Аларның шатлыклы йөзе,
Тоюы алар барын.

Бәхет ул – күрү язларны,
Көзен – яфрак яңгырын.
Ишетү күгәрченнәрнең
Иртүк сузган таң җырын.

Бәхет ул – яшәү һәм яшьнәү,
Сөенеп бар булганга.
Елавы да бәхеттер ул
Кайчак күңел тулганда.

Бәхет ул – матурлык күрү,
Яшәештән, дөньядан.
Сокланып калыйк, бер киткәч
Кайтып булмас яңадан.

КЕМ НИ ӨЧЕН ТУА?

Кем ни өчен туа җиргә?
Һәркемнең үз язмышы.
Кем туып бәхет китерә –
Бар җанга ут салмышы.

Кем өнәми дөреслекне,
Алдашудан тәм таба.
Шулай да кайчак үзенең
Тозагына ул каба.

Кемдер туган сыман бары
Игелекләр эшләргә.
Бар усал эт сыман кайсы,
Ыргып тора тешләргә.

Икейөзлеләр бар җирдә,
Күзләреңә багучы.
Башкалар алдында көлеп,
Дуска яла ягучы.

Йөрәксез туучылар бар,
Җанында кояш сүнгән...
Нурлары бозга әйләнеп,
Башка җанын көйдергән.

Гомер иткәч күрәсең шул,
Сизәсең бит барыбер...
Андыйларны аңлар дуслар
Ялгызлыкта калыр бер.

И ТУГАН ҖИР

Чит җирләрдә йөремәдем,
Күңел никтер тартмады.
Шаккатып мактасалар да-
Аннан нәфсем артмады.

Үз җиремнең матурлыгы
Гашыйк итте җанымны.
Бүләк сыман каршы алам
Яңа туган таңымны.

Илһам алам табигатьтән,
Сайрар кошлары белән.
Аллы-гөлле чәчәкләре –
Ямь биреп тора гелән.

Ак каеннарны яратам,
Чыршы, төз наратларны.
Күз алдына китерәлмим
Талсыз туган якларны.

Кырларның киңлеген тоям
Йөрәгем түрләрендә.
И туган җир, бишек җырым,
Моң саркый күкрәгемдә.

Удмуртия, Воткинск.

Әгъния МИҢНЕБАЕВА

Кавышуга түземлекләр җитсә, Аерылуга ничек чыдарсың?..

АРЫШЛАРЫМ

Сездән башка яшәү мөмкин түгел,
Йөрәкләрне баса сагышлар.
Бер күрим дип тагын кайттым әле,
Саулармысез, саумы, арышлар!

Кем уйлаган, әйтче, юрауларым
Юш килер дип шушы иртәдә.
Туегызга туры килгәнмен ич, –
Басу өсте кабат серкәдә!

Килегез, кил, барыр юлда туктап,
Бер иркәлим кайнар сулыштан.
Алар сүзсез иңнәремә үрелә,
Башаклары шундый тулышкан!

Сөн буенда йөрим сезне уйлап,
Иртәгәдән юлга чыгасым.
Кавышуга түземлекләр җитсә,
Аерылуга ничек чыдарсың?

Җылылыгы туган туфрагымның
Табаныма сеңгән яшь чактан.
Арышларым, үзәк тамыр булып,
Йөрәгемә минем тоташкан.

АВЫЛЫМА КАЙТАМ

Бик сагынып авылыма кайттым,
Яз башлангач туган җиремдә.
Сөндә боз кузгалган! Бу хисләрне
Ничек аңлатыйм соң шигырьдә?

Бик сагынып авылыма кайттым –
Ямьле җәйләр иде илемдә.
Иген шавын, арыш җырлаганын
Салып килдем тагын күңелгә.

Бик сагынып авылыма кайттым –
Кайттым тагын алтын көзләрдә.
Андый матурлыкны язар өчен
Җитмәс кебек нинди сүзләр дә.

Мин кышларда авылыма кайттым,
Төренгәндә дөнья сафлыкка.
Авылыма кайтам, бик сагынып,
Җаным сусаганда аклыкка.

Күңелемдә җылы сакладым
Язмыш мине бик еш сынаса да,
Күз яшьләрем җиргә түкмәдем.
Горур була белдем, беркемгә дә
Баш имәдем, тез дә чүкмәдем.

Кеше учагында җылынмадым,
Үземнекен үзем кабыздым.
Хисләремне талгын елга итеп,
Сагышларым шунда агыздым.

Гел елмаеп яшәдем мин җирдә,
Назлы язлар булды көткәнем.
Калсын әле, әйдә, калсын әле,
Якты булып бөтен үткәнем.

Югалтулар санап бетергесез,
Аз булса да җыйган-тапканым.
Күңелемдә ләкин бар дөньяга
Ачу түгел, җылы сакладым.

УҢ БУЛСЫН ЮЛЛАРЫ

Ак яулыгым бәйләп, камыр басам,
Ак мамыкка бата кулларым.
Уңып пешсен диеп бәлеш салам,
Кайтыр юлга чыккан улларым.

Тәрәзәмне ачам, яз кояшы
Өй эченә сипсен нурларын!
Якты булсын йортым, җылы булсын,
Кайтып килә әнә улларым!

Сезгә биргән назым, җан җылысын
Кайтарасыз хәзер үземә.
«Кара алтын» табып йөрсәгез дә,
Кара якмадыгыз йөземә.

Олы юлга тагын озатып калам,
Йа, Раббым, уң итче юлларын.
Өмет-ышанычым, шатлыкларым
Сез генә бит, сез бит, улларым!

ҮЗ-ҮЗЕМНЕ ЭЗЛИМ

Йөгереп үттем гомер сукмагыннан,
Салмак кына атлый белмәдем.
Давылларда, бураннарда калдым –
Язмышымны әллә эзләдем?

Йөрәгемне ялкын чорнаганда,
Хисләремә йозак элмәдем.
Очкын идем, уһак булып яндым –
Мин бит бәхетемне эзләдем.

Тугайларда, болыннарда йөрдем,
Чыклы үләннәрдә эзләрем.
Күкрәгемә тулган моң-сагышны
Басар өчен җырлар эзләдем.

Хыялларым ашкындыра мине,
Сабыр гына яши белмимен.
Гел чайкалган тормыш диңгезендә
Үз-үземне һаман эзлимен.

Чаллы.

●Мәрьямбану Искәндәрова.

●Камил Мотыйгый уң якта.

●Сәхибҗамал Гыйззәтуллина-Волжская.

Тәүге татар җырчылары

(XX гасыр башы татар эстрадасының Франция архивында табылган язмалар нигезендә)

20 нче гасыр башы татар язучыларының күп кенә әсәрләрендә (Г.Исхакый «Ике йөз елдан соң инкыйраз», Г.Ибраһимов «Яшь йөрәкләр» һ.б) музыканың татарларга «нихәтле кирәге» турында мотивлар сызылып үтә. Музыка мотив кына түгел, ул «татарны инкыйраздан саклап калучы» итеп күрсәтелә. Нинди булган соң ул 20 нче гасыр башы татар музыкасы? Нинди җырлар популяр булган? Ул җырларны кем башкарган? Бу теманы Татарстан һәм Башкортстанның халык артисты Идрис Газиев өйрәнгән. Бу мәкаләдә аның диссертациясендәге мәгълүматлар файдаланылды.

КАМИЛ МОТЫЙГЫЙ-ТӨХФӘТУЛЛИН

Күп еллар буе Камил Мотыйгый тарих битләрендә Тукай шәүләсе артында калучы шәхес буларак өйрәнелде. Бу факт белән тарткалашып та булмый. Ул гына түгел, хәтта бүтән бөек татар шәхесләре дә Тукай йолдызы артыннан гына балкый алды. Шуңа да карамастан, Мотыйгыйның татар мәдәниятен, аңын үстерүгә керткән өлеше бөек татар шагыйре белән бер рәттә каралса да ялгыш булмас. Мотыйгый беренчеләрдән булып татар сәхнәсенә менә, беренчеләрдән булып профессиональ рәвештә татар көен, формасын төзүгә адымнар ясый.

Бүген без Мотыйгыйның патефон тәлинкәсенә яздырылган 11 җырын тыңлый алабыз. Көн кадагының тенденцияләренә күз салсак, бу бер тулы альбом. Әлбәттә, 20 нче гасыр башы татар көйләре, бүгенге җырларда ишетелә торган «төрлелек» белән мактана алмый. Җырлар бер-берсенә охшаш. Ул вакытта алгы планга җырчы тавышының көче, мөмкинлекләре чыккан. Көй бары тик аккомпанемент рәвешендә генә җырчы тавышына кушылган дип, әйтергә кирәк. Чагыштыру өчен, Мотыйгый һәм ТР фольклор музыка ансамбле башкаруында бер үк җырны тыңлау сорала. Мотыйгый җыры - Франция архивындагы аудиотасмада, ә фольклор музыка ансамбле чыгышы үз сайтларында сакланган.

Камил Мотыйгый - үз заманының иң популяр җырчыларының берсе. Бу популярлыкны беренче татар музыкасы белгече, танылган композитор Солтан Габәши болай аңлата: «...күп очракта К. Мотыйгый рус көйләрен алып, аларны җиңел шаян сүзләр белән җырлап, татар дөньясында популярлык казанды».

Франция Милли китапханәсенең аудиовизуаль документлар департаменты коллекциясе архивында табылган язмаларны тыңлаган кеше өчен, Солтан Габәши сүзләре субъектив булып күренергә мөмкин, чөнки Мотыйгый репертуарында татар тарихы фаҗигасен чагылдырган, татар җәмгыятенең караңгы якларын фаш иткән, тәнкыйтьләгән, фәлсәфи уйларга чумдырган җырлар шактый. Шуны да әйтеп узу зарур, Камил Мотыйгый репертуарының күп өлеше Тукай шигырьләренә салып язылган. Алар арасында «Кичке азан», кара реакция елларында язылган «Тотса мәскәүләр якаң» һәм «Пар ат» җырлары аерым игътибарга лаек.

Гасыр башында татарларда уяна башлаган кайсы гына өлкәне алсак та, аларны Тукайдан башка күз алдына китереп булмый. Җырлар белән дә шул ук хәл. Әлбәттә, Тукай махсус рәвештә җырлар өчен сүзләр язмаган, җырчылар үз теләкләре белән аның шигырьләрен көйгә салган. Шагыйрьнең граммофон язмаларына бик зур тәнкыйть белән караганы да билгеле. «Граммофонда татар җырлары» дигән дүртьюллык шигырендә Тукай үзенә генә хас сатира белән граммофонга яздырылган җырларга характеристика бирә:

Тынычлыкны боза аның әче таушы,
Килә аннан, бер тыңласаң,
мәче таушы;
Бер тыңласаң, чинау килә;
бер тыңласаң –
Майламаган арба тәгәрмәче таушы!

(«Ялт-йолт»ның 1910 елгы 14 нче санында «Шүрәле» имзасы белән басылган).

МӘРЬЯМБАНУ ИСКӘНДӘРОВА

Алдагыда әйтелгәнчә, ул заманның күренекле язучылары музыканың татар халкына «сулыш кебек кирәк» икәне турында яза. Әлбәттә, язучылар фантазиясе күрергә омтылган көйләр, сәхнәгә менгән көйләр белән чагыштырганда, йомшак кына әйтсәк, туры килми. Мәсәлән, Мәрьям Бану (Мәрьямбану) Искәндәрова – шундый көйләрнең авторы һәм җырчысы. 20 нче гасыр башында татар хатын кызының сәхнәгә чыгып җырлавы, ә Искәндәровага килгәндә, аның трактир-ресторан җырчысы булып танылуы нинди тәнкыйтькә дучар булганы турында исбатлау кирәк түгелдер.

Мәрьямбану Искәндәрова - каршылыклы шәхес. Татар җәмгыятендә аның турында төрле сүзләр йөргән. Кемдер аны яраткан, кемдер тәнкыйтьләгән. Бу фикерләрнең күплегенә, мөгаен, Тукайның «Хайлыйм, хайлыйм хайларга...» дигән шигыре генә тулысынча җавап бирә алыр. Ул «Яшен»нең 1909 елгы 8 нче санында рәсем астында имзасыз басылган:

Хайлыйм, хайлыйм хайларга,
без керештек байларга.
Сторожлыкка ялландык
Чәйдәш абзыкайларга.
Яшенче дип әрлибез,
доносчы дип хурлыйбыз;
Проститутка Мәрьям белән
парлап торып җырлыйбыз.

Бу шигырьнең язылу тарихы кызык. 1909 елда Сәгыйть Рәмиев, сәяси эшчәнлеге өчен бер ай төрмәдә утырып чыккач, «Бәянелхак» газетасына эшкә урнаша. Ул бер төркем яшьләр белән газетада «Уен-көлке музее» һәм «Без» исемле көлке сәхифәләре оештырып, «Музей сторожы», «Музей сторожы Тимербулат» һ.б. псевдонимнар астында Тукай редакциясе астында чыккан «Яшен» һәм «Әл Ислах» газеталарына каршы юнәлдерелгән мәкалә-фельетоннар, шигырьләр бастыра башлый. Тукайга С.Рәмиевнең әлеге гамәлләре бер дә ошамый. Ул аны кайда гына күрсә дә, әлеге шигырьне җырлап хурлый торган була. Шигырьне тулысынча аңлау һәм кем турында язылганын аңлау өчен искәрмәләрне уку кирәк:

Сторожлыкка ялландык Чәйдәш абзыкайларга. – 1906-1914 елларда Казанда нәшер ителгән «Бәянелхак» газетасын чыгаручы нашир-мөхәррир Әхмәтҗан Сәйдәшев турында әйтелә.

Проститутка Мәрьям белән парлап торып җырлыйбыз. – Шагыйрь С.Рәмиев яхшы җырчы да була. Аның граммофон пластинкасына берничә татар көен яздырганлыгы билгеле. Мәкәрҗәдәге зур рестораннарда Мәрьям Искәндәрова белән бер-ике дуэт та җырлаганнар. Шигырьнең соңгы ике юлы шуңа ишарә булса кирәк.

Соңгы мәгълүматларына караганда, Мәрьям Искәндәрованың дискографиясе 54 язма тәшкил итә. Алар 1907-1912 еллар аралыгында яздырылган. Бу факт аның 20 нче гасыр башында граммофон пластинкасына иң күп җыр-

лар яздыручы җырчы булуын дәлилли. Әлбәттә, бу популярлык турында сөйли. Мәсәлән, татар профессиональ театрының беренче хатын-кыз актрисасы Сәхибҗамал Гыйззәтуллина-Волжская үз истәлекләрендә Мәскәүдә Мәрьям Искәндәрова белән танышуын менә ничек тасвирлый: «... матур гына бүлмәдә безне озын буйлы, матур бизәнгән, кулына папирос тоткан серле бер хатын каршы алды. Ул миңа, мул тормыш вәгъдә итеп, рестораннда биергә тәкъдим итте. «Мин «ЯР» ресторанында эшлим, мин – Мәрьям Искәндәрова». Бу истәлек Искәндәрованың Мәскәүнең ул вакытта танылган «ЯР» ресторанында эшләвен раслый. Шулай ук аның «Мәкәрҗә» ярминкәсенең югары класслы рестораннарында чыгышлар ясавы билгеле.

МИРФӘИЗ БАБАҖАНОВ

Мирфәиз Бабаҗанов - шулай ук үз заманының иң популяр җырчыларының берсе. Биографиясенә килгәндә, аның Троицк шәһәрендә тууы билгеле. Шунысы кызык, хатын-кыз тавышы белән җырлаган өчен халык аңа «Троицкий Мирфәйзә» дигән кушамат биргән. Гомумән, ул вакыт өчен ир-ат җырчыларның кычкырыбрак, ярым фальцет белән «чинабрак» җырлавы модада булган.

Бабаҗановның гастрольләрдә күп йөрүе, яхшы гармунда уйнавы, төрле ярминкәләрдә чыгышлар ясавы, шулай ук «Мәкәрҗә» ярминкәсенең мәдәни-күңел ачу программаларында даими катнашып торуы билгеле. Замандашлары истәлекләрендә аның тышкы кыяфәте, тавышы, башкару манерасын тасвирлаган хатирәләр бар. Кызганычка, җырчы популяр булса да, аның фоторәсемнәре табылмаган.

Бабаҗанов репертуарына килгәндә, «Баламишкин» җыры игътибарга лаек. Ул риваятьләргә нигезләнеп язылган, дигән фикер бар. Имеш, Габделгалим Мишкин дигән сәүдәгәр бик күп байлык туплап, акчасын өч улына мирас итеп калдырган. Шуларның икесе, без эшләргә җыенмыйбыз, акчабыз болай да җитәрлек булачак, дип яшәгән. Бер көнне алар акчаларын туздырып бетергәннәр, истәлеккә бары тик «Баламишкин» көе калган. Кызыклы факт: шушы риваятькә нигезләнеп, Кәрим Тинчурин «Соңгы сәлам» драмасын язган.

Тагын бер фараз — бу көйне бай сәүдәгәр Мишкин үзе заказ биреп яздырган, шуңа күрә җыр аның хөрмәтенә аталган булырга мөмкин, ул вакытта мондый әйбер модада булган.

ХӨСӘЕН ЙОСЫПОВ

Хөсәен Йосыпов җырлары язылган күп тәлинкәләр Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты фондында саклана. «Диск Пате» дип исемләнгән язмалар арасында «Ай, һайли Зиләли», «Волков сазы», «Тай да тройка», «Порт-Артур», «Агыйдел», «Ай бәгърем» җырлары бар. Йосыпов шулай ук "хатын-кызлар тавышы" белән җырлаган. Сез аның башкаруында «Кара болыт» җырын тыңлый аласыз.

НӘФИСӘ ПСНЯКОВА, ХӘДИЧӘ ГАМБИТСКАЯ, ФАТЫЙМА МОРАТОВА

Әлеге өч җырчының биографиясе, кызганыч, билгеле түгел. Без бары тик аларның җырларын гына тыңлый алабыз. Пснякова, Гамбитская һәм Моратова беренчеләрдән булып татар музыка дөньясында дуэт һәм трио рәвешендә җырлый башлый. Мисал өчен, «Аппагым-былбылым» җыры нәкъ шушындыйларның берсе дип әйтергә кирәк.

Шулай ук Франция Милли китапханәсенең аудиовизуаль документлар департаменты коллекциясендә «Женские дуэты» дип исемләнгән ике пластинка бар. Аларның авторлары билгесез. Кайбер тарихчылар фикере буенча, исемнәрне мондый рәвештә яшерү - татар хатын-кыз җырчыларының күңел ачу биналарында, фахешханәләрдә чыгыш ясауларын белдерүдән куркып эшләнелгән әйбер.

КАРИЕВ VOICE

Франция Милли китапханәсенең аудиовизуаль документлар департаменты коллекциясендә шулай ук татар профессиональ театрына нигез салучы, «Сәйяр» труппасы җитәкчесе - Габдулла Кариев тавышы да сакланган. Әлеге ике патефон тәлинкәсе язмасында ул Габдулла Тукайның «Буржуаз фикре» һәм «Ысул кадимчә» әсәрләрен укый. Шулай ук язмада авторы билгеле булмаган «Зилзилә» һәм «Байбәтче» хикәяләрен ишетергә була. Әлеге язмалар 1912 елдан да соңрак яздырылмаган дигән фактлар бар. Шуңа күрә ни өчен Тукайның тавышы да патефон тәлинкәсенә яздырылмаганы сер булып кала…

ӘЙЛӘНӘ ТӘЛИНКӘ, ӘЙЛӘНӘ...

Монда 20 нче гасыр башы татар эстрадасының «беренче җимешләре» турында сүз барды. Саналып киткән һәр җырчы, нинди генә шәхси тормыш алып барса да; Тукай язганча «мәче тавышы» чыгарып чинап җырласа да; күбесе төрле кабак, трактир сәхнәләрендә, фахешханәләрдә, күңел ачу биналарында чыгыш ясап танылса да, бу - безнең тарих. Ә үз тарихыңны, ул нинди генә булса да, кабул итәргә, яратырга, белергә кирәк. Бу җырчылар - беренчеләр. Ә беренчеләрне гел тәнкыйтьлиләр, ләкин вакытлар уза, тарих битләре күбәя, ә алар барыбер халык хәтерендә уелып кала, чөнки алар - беренче…

Ильяс ХАҖИЕВ.

Чынга ашарлык хыялмы?

Салават Камалетдинов фотосы.

Татарстанда Әмирхан Еники хикәяләре буенча «823 километр» дип аталган тулы метражлы нәфис фильм төшерелә. Аның сценарий авторы – Мәскәү киносценаристы Валерия Байкиева, өч хикәяне берләштерү өчен, яңа персонаж керткән: хикәяләрдә сурәтләнгән вакыйгалар татар язучысы аша бирелә. Валерия Байкиева әлеге зур язучыны Казаннан читтә яшәүче итеп күз алдына китерә һәм аның Нобель премиясе лауреаты булуын да билгеләп үтә.

Киносценарий уңышлы дип бәяләнде. Әмма геройның, ягъни татар язучысының Нобель премиясе лауреаты булуы әлеге фильмда төшүчеләрдә бераз каршылык тудырган.

«Минем персонаж Әмирхан Еники әсәрләрендә юк. Өч новелла аның карашы аша күрсәтеләчәк. Ул – бүгенге көн кешесе. Өлкән яшьтә. Әле сценарийда аны Нобель премиясе лауреаты дип тә язганнар. «Сызып ташлагыз, анысы бөтенләй әкияткә китә, җитдирәк карагыз»,» – дидем. Анысын алып ташладылар...» – дип аңлатма бирде танылган язучы ролен башкаручы, Татарстанның халык, Россиянең атказанган артисты Илдар Хәйруллин.

Татар язучысының Нобель премиясе лауреаты булуы мөмкин хәл түгелмени?

Илдар Хәйруллин: «Мин, безнең язучылар Нобель премиясе алырга мөмкин, дип уйлыйм. Ләкин булмаган әйберне теләк белән генә күрсәтү, миңа калса, дөрес түгел. Башта бирсеннәр! Безнең Гаяз Исхакыйдан башлап искитмәле язучылар бар. Бервакыт аның китабын үзем белән ял йортына алдым. Кич белән «Сөннәтче бабай»ны укый башлаган идем... югыйсә кат-кат укылган... китапны укый-укый таң аткан икән, балконга чыктым... шул кичерешләрдән күземнән яшь ага башлады. Мондый язучы, әлбәттә, Нобель премиясенә лаек. Аяз Гыйләҗев, Әмирхан Еники... искитмәле... 47 ел Казан театр училищесында укытам – студентларга иң элек Әмирхан Еники әсәрләрен бирәм. Анда тел дә, гореф-гадәт тә, рух та, татарның моңы да. Миңа калса, ул Нобель премиясенә лаек. Тагын да бар...»

Ркаил Зәйдулла: «Мин дә каршы булдым. «Татар язучысы» темасын юмор-сатирага әйләндермик, дип шалтыраттым. Дөнья мәйданына чыгу бит әле ул – әсәрең югары дәрәҗәдә язылган дигән сүз генә түгел. Бик күп факторлар бар. Мәсәлән, Европа, Америка язучылары белән шәхси танышлыгың да кирәк – практика шуны күрсәтә. Әйтик, Светлана Алексиевич (2015 елда Нобель премиясе алды. – **Авт.**) озак еллар Европада яшәде, аның үзен дә белделәр, әсәрләре дә чит телләрдә чыкты. Аны бит, дөресен генә әйткәндә, коеп куйган язучы дип тә булмый, нигездә публицистика. Андый әсәрләр дөнья әдәбиятында бик күп. Әмма рус телендә язучы белорус язучысы шулай калкып чыга алды. Җыр текстлары авторы, бард Боб Диланга да бирделәр бүләкне. Һәр премия кебек, Нобель премиясен дә 100 процент объектив була, дип уйламыйм. Бохараев Лондонда яшәде, аның Нобель премиясен алу өчен мөмкинлекләре бар иде, дип уйлыйм – иртәрәк үлеп китте.

Тагын бер нәрсә бар – анда, әдәби әсәрнең сыйфатыннан тыш, язучының нинди шәхес булуына игътибар итәләр. Дөньяның агышы белән риза булмаган протестлы шәхесләргә бирәләр. Монда хайп та бар. Мәсәлән, Орхан Памукка Нобель премиясе сәясәттә ниндидер сүз әйткәнгә бирелде. Ул әрмәннәргә карата геноцид булуын, көрдләр проблемасын күтәреп чыкты. Нобель премиясен алганнан соң, тавышын ишеткәнем юк. Ә менә итальян язучысы Умберто Эконың «Имя Розы» дигән гениаль әсәре бар. Аның буенча фильм да төшерелгән. Ул язучы Нобель премиясенә лаек булмады. Димәк, Нобель премиясен алмаган язучылар көчлерәк тә булырга мөмкин.

Татар язучыларының һәр икенчесе Нобель премиясенә лаек димим – сүз дә юк, ләкин андыйлар бар. Мәсәлән, Әмирхан Еники. Мин аны кайта-кайта укыйм, Нобель премиясе алганнардан ким түгел. Фикерле шәхес иде. Кыскасы, Нобель премиясе алу мөмкинлеге бар, ләкин ул миңа рәшә сыманрак тоела».

Рузилә МӨХӘММӘТОВА.

intertat.tatar

Антон ЧЕХОВ

КУРАЙ

Өс-башына пәрәвезләр, ылыс энәләре ияреп беткән, куе чыршылыктагы бөркүдән әлсерәгән, Дементий хуторының Мелитон Шишкин атлы приказчигы әкренләп урман авызына таба чыгып килә. Аның нәселсез эт белән сеттер кушылмасы булган Дамка дигән коточкыч ябык, авырлы маэмае, юеш койрыгын бот арасына кысып, хуҗасы артыннан сөйрәлеп кенә бара, үзе борыныннан берәр төрле чәнечкеле нәрсәгә китереп төртмәскә тырыша. Көн болытлы, ямьсез. Җиңелчә томанга төренгән агачлардан, абагалардан эре-эре тамчылар коела, юеш урман эченнән черегән әчкелтем ис бөркелә.

Алда, ешкынлык беткән җирдә, каеннар тезелешеп киткән, шул каеннарның кәүсәләре һәм ботаклары арасыннан томанлы булып офык күренә. Каеннар арасында кемдер берәү үзе ясаган кураенда уйный. Уйнаучы иренеп кенә бишме-алтымы гына нота ала, алардан ул көй чыгарырга да тырышмый, шулай да, курай чыелдавында ниндидер үзе кырыс та, үзе үтә ямансу да моң ишетелә.

Ешкынлык сирәгәеп, чыршылар яшь наратлар белән аралаша башлаган җирдә Мелитон көтү йөргәнен күреп алды. Урман үләнен исни-исни, чыбык-чабыкны чатырдатып, тышаулаган атлар, сыерлар, сарыклар йөри. Урман авызында, юеш каенга сөялеп, өстенә сәләмә чикмән кигән ябык кына, ялан башлы карт көтүче басып тора. Ул аска карап нидер уйлана һәм кураен да аңсыз гына уйный иде бугай.

– Исәнме, бабакай, Алла ярдәм бирсен! – дип, нечкә генә карлыккан тавышы белән сәламләде аны Мелитон. Бу тавыш аның озын буена, итләч табак битенә һич ятышмый иде. – Оста сызгыртасың икән бит син курайны! Малларың кемнеке соң?

– Артамоновларныкы, – дип, теләр-теләмәс кенә җавап бирде дә көтүче, кураен куенына тыгып куйды.

– Алайса урманы да Артамоновларныкы инде? – дип сорады Мелитон, тирә-ягына каранып. – Кара әле, чынлап та Артамоновларныкы икән бит. Адаша язганмын ла! Ешкынлыкта битемне сыдыртып бетердем.

Ул юеш җиргә утырды да газета кәгазеннән тәмәке төрә башлады. Бу кешенең бөтен нәрсәсе дә: елмаюы да, күзе, төймәләре, кырылган симез башына көчкә элгән торган картузы да – зәгыйфь тавышы сыман ук – буена, иңенә, итләч чыраена хас булмаганча вак иде. Сөйләгәндә яисә елмайганда, аның кырылган тулы йөзеннән, бөтен гәүдәсеннән юашлык, басынкылык сизелеп тора иде.

– Көннең бозылуын әйтәм әле! – диде дә ул, башын чайкап куйды. – Кеше әле солысын да җыеп алмаган, яңгырны күр инде син, Ходайның рәхмәте, ялланып явамыни!

Көтүче яңгыр сибәләп торган күккә, урманга таба карап алды, приказчикның өс-башына күз төшерде, уйлануын-уйланса да, бер сүз дә әйтмәде.

– Җәй буена шушылай булды инде... – дип көрсенде Мелитон. – Мужикка да начар, хуҗаларга да берниндн рәхәте дә юк.

Көтүче тагын бер кабат күккә карап алды, уйланып торды, аннары, һәр сүзен чәйнәп биргәндәй, иҗекләп әйтте:

– Һаман шул нитүгә таба бара инде... Юньлегә түгел.

– Сезнең монда ничек соң? – дип сорады Мелитон, тәмәкесен кабыза-кабыза. – Артамоновлар кисентесендә көртлек оялары очрамадымы?

Көтүче җавап бирергә ашыкмады. Ул яңадан күккә күз төшерде, тирә-ягына карангалап алды, уйланды, чет-чет итеп күзен йомды... Күрәсең, ул үз сүзенә шактый зур бәя бирә, һәр сүзенең базарын күтәрер өчен, аны беркадәр тантана беләнрәк, сузыбрак әйтергә тырыша иде. Аның карашы картларныкыча үткен, сабыр иде, ә инде, борынының урта бер җиренә ыңгырчак сыман аркылы эз төшкәнлектән һәм борын тишекләре өскә таба карап торганлыктан, йөзе хәйләкәр һәм мыскыллы сыман тоела иде.

– Юк, күрмәдем бугай, – дип җавап бирде ул көттереп кенә. – Безнең аучы Еремканы әйтүем әле, Элҗин бәйрәме көнне Ташландык җир буенда бер оя тоттым дип сөйләгән иде сөйләнүен дә, юктыр ла, шыттыра торгандыр. Кош-корт аз бит хәзер.

– Шулай шул, туганкай, аз шул... А-а-аз! Аек акыл белән исәпләп карасаң, аучылык – файдасыз, бер тиенгә кирәксез эш. Киек кош бөтенләй күренми, булганы да яшь, аның белән пычранып та йөрисе түгел! Шундый да вак инде менә, карар җире дә юк!

Мелитон елмаеп куйды да кул селтәде.

– Дөньядагы хәлләрне уйлап карасаң, адәм көлкесе бит! Кош-корты да аның хәзер әллә нинди мәгънәсезгә әйләнде, бала чыгарырга дип күкәй өстенә дә соң гына утыра, Пыкрау көненә хәтле тормыйча утырганнары да бар. Валлаһи дип әйтәм менә!

– Һаман да шул нитүгә таба бара бит, – диде көтүче, йөзен күккә таба күтәреп. – Узган ел кош-корт аз булган иде, быел аннан да азрак, берәр биш елдан соң гел дә калмас дип исәплә. Тиздән киек кош кына түгел, кош-кортның берниндие дә калмас дип уйлыйм мин.

– Шулай шул, – дип, бераз уйланып торгач, Мелитон да аның белән ризалашты. – Дөрес әйтәсең син.

Көтүче сызланып кына көлемсерәде дә башын чайкады.

– Шаккатарсың! – дип куйды ул. – Кая китә микән соң алар? Егерме еллар элек кенә әле кыр казы, үрдәге, көртлеге дисеңме – мыжлап торадырые. Хуҗалар ауга чыгып китеп, шарт та шорт мылтык атып йөрерләрие. Урман үрдәкләре, чуллык, кроншпильләр бихисап, вак-вак чүрәкәй, үрдәк бәбкәләре белән шөлдиләр, сыерчыклар яисә чыпчык ишеләр исәпсез-сансызые! Кая китеп беткән диген боларны! Усал кошлары да күренми бит аның хәзер. Бөркет, лачын, мәче башлы ябалагына хәтле юкка чыга бит... Җәнлекләр дә әзәйде. Аю белән чәшке генә түгел, бүре белән төлке дә сирәк очрый хәзер. Элек пошиларга хәтле барые. Менә кырык еллап инде мин елдан-елга Ходай тәгаләнең эшләрен күзәтә барып бер фикергә киләм: һаман да шул нитүгә таба бара бит...

– Нитүгә?

– Юньлегә түгел шул, бетүгә таба бара... Ахырзаман җитеп килә. – Карт, башына картузын киде дә, күкне күзәтә башлады.

– Кызганыч шул, – диде ул бераз дәшми торганнан сон. – Йа Ходаем, бигрәкләр дә кызганыч шул инде. Барысы да Ходай тәгалә иркендә инде ул үзе, югыйсә, дөньяны без бар итмәгән бит, шулай булса да, кызганыч. Берәр агач корыса яисә, әйтик, берәр сыер егылып үлсә дә, кызганыч бит әле ул, ә бөтен дөньяң бетә башлагач, ни хәлләр итмәк кирәк. Нихәтле нәрсә бит, Ходаем: кояшы, күге дисеңме, урманы, елгалары, бүтән төрле җан ияләре дисеңме – һәммәсе дә бар ителгән бит, бер-берсен җайлаштырып яратылган. Барысы да эш ителгән, һәммәсе үз урынын белә. Шуларның барчасы юкка чыгарга тиеш!

Көтүченең йөзендә моңсу елмаю кабынып китте дә, күзләре чет-чет йомыла башлады.

– Дөнья бетә дисең син... – диде Мелитон уйланып. – Заман ахыры тиздән житүен дә җитәр ул әллә, алай да кош-кортка карап кына фараз итәргә ярамый. Кош-корт кына әйтә алмас аны.

– Кош-корт кына әйтер димим мин, – диде көтүче. – Җәнлекләр дә, терлекләр дә, умарта корты да, балык та... Миңа ышанмасаң, картлардан сора әнә; балыкның да хәзер элекке кебек түгел икәнен һәрберсе әйтер. Диңгезендә дә, күлендә, дә, елгасында да балык елдан-ел кими. Әле үзем дә хәтерлим, үзебезнең комлыкта да аршын буе чуртаннар, жумбалар була торганые; бәртәсе дә, корбан балыгы да, һәр балыкның үзенең кыяфәте, тотар жире була торганые, ә хәзер чуртан баласы яисә чиркеле алабуга эләктерсәң, шөкрана кылырга тиеш буласың. Адәм рәтле шыртлакасы гына да юк бит ичмасам. Елдан-ел беткәннән-бетә, тора-бара бөтенләй калмас. Елгаларны ал инде син менә... Корыйлар бит!..

– Әйе, дөресе дә шулай – корыйлар.

– Шул шул менә. Елдан-ел саекканнан-саега, элекке чоңгылларга хәтле юк инде хәзер. Ә-ә-әнә тегендә, күрәсеңме куаклыкларны? – дип сорады карт. – Шулар артында елганың иске юлында бер култык барые; минем әткәй исән чакта Комлы елга шуннан агадырые, ә хәзер әнә, күрәсеңме, кайдук киткән! Шулай юлын үзгәртә-үзгәртә корып та бетәр инде ул. Кургас артында сазлык та буалар иде, хәзер кая киткән алар? Инешләр кая киткән? Безнең генә шушы урманда бер инеш ага иде, шул инешкә сөкә салып, авыл халкы чуртан тотадырые, хәзер язгы ташуда да юньләп суы булмый бит аның. Кая гына карама – рәттән бетүгә бара. Кая гына карама?

Шуннан соң тынып калдылар. Мелитон, карашын бер ноктага төбәп, уйга талды. Бөтен дөньяны биләп килгән һәлакәт әлегә кагылмаган берәр генә урынны исенә төшерәсе килде аның. Кыйгачлап яуган яңгыр һәм томан пәрдәсе артында якты таплар йөгерешеп үтте, бу – чыгып килә торган кояшның болытлар аша шулай җиргә күз төшерергә маташуы иде.

– Ә урманнар... – дип мыгырдады Мелитон.

– Урманнары да шул инде аның... – дип кабатлады көтүче. – Кисәләр дә урманны, яна да урман, корый да, ә яше үсми. Үссә дә хәзер кисәргә генә торалар; бүген үсеп чыктымы, иртәгә карыйсың – инде аны кешеләр кисеп тә өлгергән була – гел шулай бит, беткәнче кыралар. Мин үзем, беләсең килсә, ирек алганнан бирле мир көтүе көтәм, аңынчы да байларда көтүче ием, шушы төштә үк көттем көтүне, үз гомеремдә мин җәйнең җәй буена шушында булмаган көнемне хәтерләмим. Үзем гел Хак тәгаләнең эшләрен күзәтеп торам. Гомерем буена бөтенесен күрә-күрә мин шуны аңладым, туганкай: үсемлекнең һәртөрлесе хәзер бетүгә таба бара. Арышны әйтәсеңме, яшелчәнеме, чәчәкләрме – һаман да шул нитүгә таба бара...

– Аның каруы халык әйбәтләнде, – дип куйды приказчик.

– Кай ягы белән?

– Акыллырак ул хәзер.

– Акыллырагын акыллырак, анысын дөрес әйтәсең, ә соң аннан ни файда? Бетәр вакыты җиткәч ни пычагыма ул кешегә акыл? Акылсыз килеш кенә дә үләргә була бит. Аларына киегә булмагач, ниемә ул аучыга акыл? Ходай тәгалә кешегә акыл биргән дә, көчен алган дип уйлыйм мин. Буынсызга әйләнде халык, йомшады. Менә мине генә алыйк. Потым бер тиен минем югыйсә, бөтен авылында миннән дә йолкыш мужик юк, ә шулай да җегәрем бар әле.

(Дәвамы киләсе санда).

С.ИБРАҺИМОВА тәрҗемәсе.

Татар чынбарлыкны танырмы?

(Ахыры. Башы 6 нчы биттә).

Мәсәлән, мәшһүр язучы Чыңгыз Айтматовны шулай озатканнар. Манас мәрхүмнәрнең туганнарына көч өсти, күрәсең. Мәрхүмнең үзенә дә манас белән ике дөнья чиген кичүе җиңелрәк, дип ышаналардыр, бәлки. 1972 елда Социалистик Хезмәт Герое Океш Түлебердиевнең җеназасында туганнары соравы буенча өч көн дәвамында манас башкарулары билгеле. Бүген бу гадәт хакасларга да кайта, Алтай халкында да җеназа өстендә дастан башкарыла, ди. Т. Бакчиев 2010 елгы сәяси болганышлар вакытында ярсыган халыкны туктату өчен, сакчылар белән сөйләшеп, өч манасчының, шул исәптән үзенең дә хакимият бинасында манас башкара башлавы, ишекләрне бәреп кергән халыкның, бу хәлләрне күреп-ишетеп, манасчылар алдында тезләнеп утыруы, бераз сәгать кузгалмыйча тыңлаганнан соң, гафу үтенеп, хакимият бинасыннан чыгып китүе турында искә алды. Кызыл төс күргән үгез сыман ярсыган халыкны да туктатырлык булгач, дастаннарның бүген бернинди файдасы, беркемгә кирәге юк, дип әйтеп кара инде! Халыкны тамырлар, бергә үткән юл, уртак милли сыйфатлар гына берләштерә ала һәм манас авыр көннәрдә моны раслады, ди Бакчиев. Кыргызстан кунагы ахырда ярты сәгать дәвамында манас башкарды. Борынгы дастаннарны көйли белгән академия президентларын тагын кайда күргәнегез бар?! Кыргызстандагы кебек фәнне гамәл белән үрелдереп барганда гына, яхшы нәтиҗәләргә ирешеп була, күрәсең.

Тарих фәннәре докторы, профессор Александр Черных махсус проект нигезендә экиятләрне Пермь краеның брендына әйләндерүләрен, экият фестивальләре үткәрүләре, музей, сайт булдырулары, 70 экиятне күренекле артистлар башкаруында аудиоязмага яздырулары турында сөйләде. Һәм бүген халыкларның исән калырга тырышып, халык авыз иҗатына сыенулары экият түгел, чынбарлык. Кайчандыр тормыш хәлләре экиятләр, дастаннар китереп чыгарган булса, бүген адәм баласы шулар ярдәмендә аяусыз чынбарлыкны үзгәртмәкче. Татар халкы исә бу экияти чынбарлык яисә чынбарлыкка охшаган экияттә адашып калды бугай...

Миләүшә ГАЛИУЛЛИНА.

Казан очкычлары күк гизә

Татарстан авиация сәнәгате тарихы 1927 елның 14 мартыннан гына башлана. Димәк, быел аның юбилее – 95 еллыгы. Ул көнне СССРның Хезмәт һәм оборона советы тарафыннан заводны оештыру турында карар чыгарыла. Шунлыктан авиация сәнәгатен республикабыз өчен хаклы рәвештә XX гасыр вакыйгасы дип атарга мөмкин.

Ул вакытта завод ремонт мастерскоена, җиһазландырылмаган корпуска урнаша. Биредә барысы 300 кеше эшли. Беренче самолетлар ачык һавада җыела. Коллектив алдына гаҗәеп мөһим бурыч куела: кыска вакыт эчендә тоташ металлдан торган самолетларны күпләп (серияләп) чыгаруны тәэмин итәргә!

Коллективның гаҗәеп тырышлыгы, оешканлыгы нәтиҗәсендә ремонт мастерское биш ел эчендә заводка әверелә, хәтта бик таләпчән белгечләрнең дә ихтыяҗларын канәгатьләндерерлек самолетлар эшләнә башлый.

1930 елда тоташ металлдан торган беренче гигант – дүрт двигательле ТБ-3 (АНТ-6) дөньяга килә. Тагын шунысын да искәртергә кирәк, ул вакытта СССР киләчәктә авиация үсешенә хәлиткеч йогынты ясаган АНТ-4 һәм АНТ-6 самолетларын җитештерүче бердәнбер ил була. Алар Казан авиация заводы цехларында җыела. Ул чорда ук бу самолетларга хөкүмәтнең бик җаваплы бурычларын үтәргә туры килә. Мәсәлән, 1934 елда Төньяк боз океанында «Челюскин» пароходы һәлакәте бөтен дөньяны тетрәтә. Кешеләрне мөмкин кадәр тизрәк коткару кирәк була. Һәлакәт урынына Казанда эшләнгән самолетлар оча. АНТ-4 самолетында челюскинчыларның беренче төркемен – балаларны, хатын-кызларны коткаруы өчен очучы А.Лапидевскийга илдә беренче буларак Советлар Союзы Герое исеме бирелә. 1937 елда исә И.Папанинның беренче экспедициясе дүрт АНТ-6 самолетларында Төньяк полюска озатыла.

Яңа тип самолетлар җитештерүне үзләштерү һәм аларны күпләп чыгару моңарчы күрелмәгән кызу темплар белән бара. Завод коллективы беренче бишьеллык планны ике ел ярымда үти. Авыр самолетларның махсус типларын төзегән, эшне яхшы оештырган өчен, 1933 елның 17 августында завод Ленин ордены белән бүләкләнә.

Ул елларда заводта партия, хөкүмәт җитәкчеләре, халыкара эшчеләр хәрәкәтенең күренекле вәкилләре еш була. Завод төзелеше барышын үзәк башкарма комитеты рәисе М.И.Калинин күзәтә. Заводны ачу тантанасында Бөтенсоюз халык хуҗалыгы советы рәисе В.В.Куйбышев чыгыш ясый. К.Е.Ворошилов, Г.М.Димитров, А.М.Горький заводның мактаулы эшчеләре дип игълан ителә.

Ф.С.Малахов директор булып озак эшләми. Аны 29 яшьлек С.П.Горбунов алыштыра. Тәҗрибәле инженер, сәләтле оештыручы, Жуковский исемендәге хәрби һава академиясен тәмамлаган Сергей Петровичны коллектив нык хөрмәт итә. Әмма аның тормышы фаҗигале тәмамлана. 1933 елда авиация һәлакәтендә аның гомере өзелә. Коллектив соравы буенча заводка С.П.Горбунов исеме бирелә. Завод коллективы самолетларның яңа конструкцияләрен эшләү буенча хөкүмәтнең җаваплы бурычларын еш үти. Конструкторлар А.Туполев һәм А.Архангельскийның иҗат җимеше булган тиз очышлы бомбардировщик АНТ-40 һавага күтәрелә. 1937 елда Парижда үткәрелгән авиация күргәзмәсендә бу самолетка «Алтын медаль» дипломы тапшырыла. 1939 елда заводта технологик яктан бик катлаулы булган Пе-8 самолетлары чыгарыла башлый.

Бөек Ватан сугышы бөтен планнарны чәлпәрәмә китерә. Бөтен көч фронт өчен бик кирәкле булган Пе-2 самолетларын күпләп җитештерүгә юнәлтелә. Цехларда эш тәүлек буе дәвам итә. Норманы үтәмичә берәү дә эш урынын ташламый. Горбуновлылар арасында, Җиңү көнен якынайту өчен, унар норма бирүчеләр дә күп була. Фронтка киткән әтиләре, абыйлары урынына яшүсмерләр баса.

Бөек Ватан сугышы елларында Казан авиация заводы меңнәрчә самолетлар эшләп чыгара. Пе-2 самолетларында совет очучылары явыз дошман белән көрәштә төп көч булып торалар. Алар дошманның ныгытмаларын, Мәскәү янында, Сталинградта, Смоленскида, Ржев, Харьков, Курскида, Берлинны алганда туздырып ташлыйлар. Горбуновлылар фашистик Германияне җиңүгә зур өлеш кертәләр. Сугыш чорында партиянең һәм хөкүмәтнең бурычын үрнәк төстә башкарганы өчен заводка даими саклау өчен Оборона дәүләт комитетының күчмә Кызыл байрагы тапшырыла. Ул Кызыл Байрак ордены белән бүләкләнә. Завод хезмәткәрләренең зур төркеме хөкүмәтнең югары бүләкләренә лаек була. Сугыш елларында завод коллективын талантлы оештыручы В.Окулов җитәкли.

Сугыштан соң сәнәгатьне тыныч максатлар өчен үзгәртеп кору бурычы куелды. Күп тә үтмәде конвейердан реактив двигательле Ту-104 пассажир самолетлары чыга башлады. Озак еллар буе алар «Аэрофлот» паркының төп өлешен тәшкил иттеләр. Ту-104 Брюссельдә үткәрелгән бөтендөнья күргәзмәсендә алтын медальгә лаек булды.

1965 елда завод бөтен дөньяга танылган Ил-62, Ил-62М лайнерларын чыгара башлый. Бу самолетлар тукталыш ясамыйча Мәскәүдән Токиога, Нью-Йоркка, Гаванага очалар. Сигезенче бишьеллык планны уңышлы үтәве өчен завод коллективына 1971 елда Ленин ордены тапшырыла.

Соңрак та самолет төзүчеләр сынатмадылар. Продукция җитештерүне елдан-ел арттыруга ирешәләр. Торак йортлар салалар, мәдәният-көнкүреш корылмалары булдыралар. Дәвалау, сәламәтләндерү үзәкләре бик яхшы җиһазландырыла. Эшчеләргә дә, аларның балаларына да ял итү өчен бөтен шартлар тудырыла. Берләшмәнең ярдәмче хуҗалыгында хезмәткәрләр өчен азык-төлек җитештерелә.

Икътисадны базар шартларына күчерү башлангач Горбунов берләшмәсе авыр хәлдә кала. Россия икътисадындагы тирән кризис берләшмәгә зур зыян китерә. Хәрби заказлар юк, эшләнгән продукция сатылмый. Самолетларга ихтыяҗ кимеми, билгели. Алар һәрвакыт кирәк. Авиакомпанияләрдәге очкычларның күбесе искергән. Әмма аларны алыштырырга, яңа самолетлар сатып алырга акча юк. Продукция сатылмый яткач, хезмәт хакы түләү авырая. Шунлыктан берләшмә квалификацияле кадрларының бер өлешен югалта.

Авиация берләшмәсендәге хәлнең торышы турындагы мәсьәлә Татарстан парламентында да берничә тапкыр карала. Республика Дәүләт Советында «Хөкүмәт сәгате» лизинг оештыру юлы белән Ту-214 самолетларын сату мәсьәләсенә багышлана.

Белгечләрнең бәяләвенчә, Ту-214 Россиядәге иң яхшы самолетлардан санала. Әмма күпме генә мактасаң да, сатылмый яткан самолеттан берәүгә дә файда юк. Коллектив чыгымнарын каплый алмый. Югыйсә, әле кайчан гына берләшмә республика бюджетын формалаштыручы предприятиеләрнең берсе була. Әмма дүрт ел дәвамында авиация техникасына бер генә лизинг та оештырылмый. Бу максат өчен бер сум да акча сарыф ителми. Оборона комплексы Россия карамагында булса да, берләшмәгә бернинди ярдәм күрсәтелми. Татарстан хөкүмәте, республиканың Икътисад һәм сәнәгать министрлыгы Горбунов исемендәге авиация берләшмәсе җитәкчеләре белән берлектә самолетлар сатып алу белән кызыксынган авиакомпанияләрне эзлиләр. Бер үк вакытта самолетларны төзеп бетерү һәм сатуга әзерләүне финанслау схемасы билгеләнә.

Самолет – кыйммәтле товар. Акчаны тулы күләмдә кассага китереп түләп, самолетны заводтан алып китү берәүнең дә көченнән килми диярлек. Шунлыктан бөтен дөньяда самолетлар нигездә лизингка сатыла. Әмма алга киткән илләрдә самолетлар үзләрен акласын өчен салым ташланмалары каралган. Ә Россиядә лизинг системасы тиешле тәртипкә салынмаган. Лизинг турында закон да эшләнмәгән.

Соңгы берничә елда Казанда самолетлар бөтенләй төзелмәде дияргә дә була. Заказлар булмагач, акча да булмады. Һәм, ниһаять, 2021 елда боз кузгалды. «Казанның С.П.Горбунов исемендәге авиация заводына яңарту эшләрен тулысынча тәмамларга һәм дәүләтнең оборона заказын үтәүне тәэмин итәргә кирәк, – диде республика җитәкчесе Р.Миңнеханов Дәүләт Советына еллык юлламасында. – Дәүләт оборона заказы күләме кимү шартларында безгә җитештерүдәге мөмкинлекләребезне һәм кадрлар потенциалын саклап калу, аны гражданнар продукциясе җитештерүдә нәтиҗәле файдалану зарур».

Әгъзам ФӘЙЗРАХМАНОВ.

Мәдәни җомга
26 август
№33, 2022

● Яңавыл районы чиге.

● Вояды авыл советы бинасы.

● Воядыдагы ябылган мәктәп бинасы.

ЯҢАВЫЛДАГЫ

Элекке гасырларда бүгенге Татарстан территориясеннән хәзерге Башкортстан җирләренә күчеп утырган татар авылларының төгәл санын беркем әйтә алмас. Моннан 30 ел элек «Сәет батыр» романын һәм «Татарлар Пугачев явында» хезмәтен иҗат иткән чакта Татарстаннан аерылып чыккан шундый йөзгә якын авыл исемен санаганым булды. Ә еллар үтә-үтә бер Актаныш районыннан гына да Уфа губернасы җирләренә барып сыенган 40 лап авылның исеме ачыкланды. Географиясе чиксез. Берничәсен генә телгә алыйк.

Иске Теләкәй – Иске Теләкәй (Илеш).

Актанышбаш – Актанышбаш (Краснокама).

Иске Әгъбәс – Яңа Әгъбәс (Бакалы).

Иске Богады – Иске Богады һәм Богады (Чакмагыш, Бүздәк).

Яңа Богады – Яңа Богады (Бүздәк, Краснокама).

Усы – Яңа Усы (Бакалы).

Аккүз – Аккүз (Илеш).

Уразай – Иске һәм Яңа Уразай (Бүздәк, Краснокама).

Солтангол – Солтангол (Балтач).

Карт – Карт (Балтач).

Карач – Карач (Бакалы).

Әҗми – Әҗми (Бакалы).

Сәфәр – Яңа Сәфәр (Бакалы).

Иске Уръяды – Уръяды (Мишкә).

Бурсык – Яңа Бурсык (Краснокама).

Такталачык – Түбән һәм Ары Такталачык (Краснокама).

Шәрип – Яңа Шәрип (Калтасы).

Мерәс – Яңа Мерәс (Краснокама).

Гәрәй – Каен-Гәрәй, Яңа Гәрәй (Краснокама).

Таймorza (Түмерҗә) – Таймorza (Дүртөйле.)

Балтач – Яңа Балтач-Усак (Краснокама).

Чөгәнә – Яңа Чөгәнә (Краснокама).

Куян – Яңа Куян (Краснокама).

Чат – Югары һәм Түбән Чат (Яңавыл).

Уръяды – Татар Урады (Яңавыл).

Апач – Апач (Краснокама).

Илчебай – Яңа Илчебай (Калтасы).

Әле Актаныштан тыш, Әгерҗе, Минзәлә, Азнакай, Әлмәт, Ютазы, Баулы, Лениногорск, Сарман, Тукай, Мөслим h.б. районнардан Башкортстанның Илеш, Дүртөйле, Борай, Краснокама, Калтасы, Балтач, Мишкә, Чакмагыш, Бүздәк, Туймазы, Бакалы, Ярмәкәй, Стәрлетамак, Шаран, Кушнаренко, Чишмә, Дәүләкән, хәтта Урал таулары буендагы Ишембай районына кадәр күченгән Нәдер, Калмия, Карабаш, Бүләр, Калмаш, Тымытык, Гөлек, Аю, Сәет, Абдул, Тулбай, Шыгай, Турыш, Тәмьян, Әлмәт, Исәнбай, Эсләк, Кодаш, Кадыбаш, Үтәгән, Әгерҗе, Камай, Иштирәк, Янурыс, Саклау, Вәрәш, Вәрәшбаш, Бикмәт, Бишенде, Кырым-Сарай... кебек йөзәрләгән авыллар бар. Яңа урында үз исемен саклап кала алмаса, әйтик, Яңавылның Яңа Мушта авылындагы шикелле, урамнарына Теләкәй, Мерәс, Уразай дип, кайдан күчеп килүләрен белдереп яшәүче авыллар да шактый...

● Туртык авылында 1847 елда төзелгән, быел 175 еллыгын билгеләп үтүче мәчет.

● Воядының үзәк урамы.

Бер Актаныш районыннан гына да 40 лап авыл күченү, әлбәттә, тирән уйга салды. Хәтта, «Үзем туган Байсар авылы ирләре генә нишләп читтә калган?» – дигән төшенке бер уй борaулап аптыратты. Юкка пошынганмын, Башкортстанның Яңавыл районында безнеке шикелле үк Байсар атлы авыл булганлыгын белмәгәнмен генә. Мин фәкыйрегез мәктәпне тәмамлаган 70 нче елларда ул Яңавыл Байсарында халык бик аз калган, ә 2015 елда ул аяк шәрифләрен тәмам «сузган» икән...

Барыбер үкендерә... Шул Яңавыл районыннан чыккан әдипләрне һәм байтак мөгаллимне 80 нче еллардан башлап белә идем. Очрашканда нишләп ялгыш кына да үзләренең туган якларындагы Байсар авылын телгә алмаганнар? Гәрчә... сиңа газиз Байсар алар өчен кардәш булалмый шул...

Менә, бушап калуына 7 ел үткәннән соң, туган авылым исемен йөрткән Байсар урынын эзләп, ерак юлга чыктым. Безнең Байсардан аерылып киткән булуына бер шигем юк. Бер Байсар халкы гына бүгенге Башкортстан җиренә күченмичә калса, сәер булыр иде. Чөнки безнең Иске Байсар (тәүге исеме Бүләр) ким дигәндә 1570 елларда ук нигез корган, ә Кыргыз волосте башлыгы Кушык бинең улы Күккүз-Күгәй-Күзәш би 1586 елда волостьның үзе һәм андагы авылларга беркетелгән җирләр өчен Уфа воеводасыннан вотчинная грамота алуга ирешкән. Күзәшнең оныгы, безнең авылга исем бирүче Байсар 1630-1632 елларда Кыргыз волостеның баш старшинасы булып торган, аннары инде безнең авыл 1795 елдан башлап – түбә, ә 1865 елдан соң волость үзәгенә әверелгән, үз канаты астына гомум яшәүчеләр саны 20 меңнән арткан 32 авылны сыендырган. 1870 елгы җанисәп вакытында безнең Байсарда яшәүчеләр саны – 800, ә 1905 елда инде 2000 чиген дә үтеп киткән. Басу-тугайлыклар күптән имана җирләре итеп бүлеп бетерелгән, яңа туганнарга яки күчеп килгәннәргә өлеш чыгарырлык бер запас юк. Башка чара калмагач, күрше авыл ирләренең Уфа губернасындагы волостьларда сыену табуын ишетеп торалар бит. Менә, 1870 еллар тирәсендә безнең Байсар ирләре дә ут күршеләр җиренә күчәргә ният кора. Әиң мөһиме – рөхсәт алу өчен Уфа түрәләре каршында тезләнеп йөрисе юк. Бөре өязенә караган, үзе исә бүгенге Пермь өлкәсенең Кыяды районы чигендә урнашкан Биз яланлыгында XVIII гасырдан бирле бабайлар исеменә теркәлгән «ящерен» бер атау бар. Андый борынгыдан бирле Байсар «асабаларына» беркетелгән аерым «утраулар» Бөре, Сарапул кирмәннәре, Зәй каласы янында да булган. Шул Бөре ягындагы Ямады (Яңавыл районындагы әлеге авыл татар халкына Илдар Юзеев атлы зур шагыйрьне һәм аның абыйсы, филология фәннәре докторы Нил Юзиевны бүләк иткән), Сөтле күлләре; Агыйдел арьягындагы Кабан-Ялан атлы күлләр һәм алар тирәсендәге тугайларны 1674, 1696, 1700, 1701... хәтта 1855 елларда да Уфа мещаннарына һәм Каракүлдәге дәүләт крестияннарына арендага биреп торулары турындагы килешү документлары архивта да сакланган. Байсарлылар, Әгерҗедәге Исәнбай авылы вәкилләре белән бергә, 1761 елда бүгенге Яңавыл районы күршесе булган Пермь өлкәсендәге Куеда районы чигендәге Сагадак күлен дә (ә ул Яңавылдагы Байсар авылына терәлеп кенә тора) каракүллеләргә 14 елга арендага биргән. Безнең байсарлылар Сарапул өязенең Кама буендагы Мостовой һәм Сыропятово авыллары арасындагы «вотчина»га да хуҗа булган һәм аны 1746 елда Глухово крестияннарына 20 еллык арендага тапшырган. Зәй елгасы буенда Бүләр волосте «вотчина»сы булып исәпләнгән җирне дә әүвәл арендага биреп «акча» эшләгәннәр, ә аннары 1785 елда генерал А.Г. Петров-Соловковка сатып җибәргәннәр. Нәкъ менә шулар шикелле үк, Биз инешенең ике як ярына урнашкан һәм һәр ягыннан урман уратып алган гаҗәеп зур аланлык та, мөгаен, Байсар авылына беркетелгән булгандыр. Кем белә, ул җирләрне Байсар Күзәш улының да, Кыргыз волосте старшинасы булудан файдаланып, 1630 елларда ук үз исеменә яки улы-оныклары атына беркетеп куйган булуы да мөмкин. Кызганыч, моны дәлилләрлек документлар гына табылмаган һәм аларны эзләп табу, гомумән, мөмкинме икән?..

Яңавылдагы Байсар шул райондагы Вояды җирлеге составында исәпләнгән. Әмма 1940 елда Вояды авыл советы бинасы ябып юкка чыккан, ягъни бу төбәктә XIX-XX гасыр чигендә һәм Октябрь инкыйлабыннан соң булган хәлләрне бар нечкәлекләренә кадәр ачыклау бөтенләй

● Воядыда Бөек Ватан сугышында һәлак булган якташлар истәлегенә куелган обелиск. Андагы исемлеккә Байсар ирләре кертелмәгән.

● Китапханә директоры Г.Вәлиевага китабымны бүләк иткән мизгел.

БАЙСАР

● Байсарда хуҗасы Айрат умарталык тота торган исән-сау йорт. Аның як-ягында Флорида һәм Фәрит Хәбибуллиннар.

мөмкин түгел. Әле өстәвенә, революциягә кадәр Уртавыл волостена караган 19 авыл Пермь өлкәсенең Уса-Оса өязендәге Камбарка түбәсе составында йөргән, әлеге волостьны 1929 елда гына Сталин фәрманы белән Башкортстан республикасына «кайтарганнар» һәм бернинди дә җанисәп яисә сораштыру үткәреп тормыйча, шул ук Уртавыл, Вояды, Туртык, Байсар, Татар Урады (Уръяды сүзен бозып ясалган) авыллары халкын тулаем диярлек «башкорт милләтеннән», дип теркәгәннәр. 30 нчы һәм 50 нче елларда үткәрелгән «йорт буенча җанисәп» вакытында бик санаулы гаилә башлыклары гына үзләрен татар яисә типтәр дип яздырырга батырчылык иткән, әмма «күпчелек бизмәне» буенча авыллар тулысынча «башкорт» булып киткән...

Мин Воядыны, исеме буенча фикер йөртеп, берәр ар авылыдыр инде, дип барган идем. Тик анда сыңар гына да удмурт яисә урыс кешесе дә яшәми, авыл тулысынча татарныкы икән. Тик, ни кызганыч, аны чәчәк ата яки гөрләп яши, дип телгә алып булмый. 130 лап йорты булса да, халыкның яртысы Яңавыл йә Нефтекамага, Удмуртиядәге Камбаркага, Пермь өлкәсенә китеп эшли. Авыл советында 500 дән артык кеше пропискада исәпләнсә дә, чынлап торып Воядыда һәм 6 чакрымдагы Туртык авылында яшәгәннәре 300 дән дә артмый. Яңа Уртавыл авыл советы, үз составындагы 19 авыл белән бергә, совет чорында «Яңавыл» терлек симертү совхозы булып исәпләнгән. Һәр авылда үгез яисә тана симертү, алардан тыш ат фермалары булган. Әлбәттә, терлек азыгы һәм бөртекле ашлык җитештергәннәр. Совет чорындагыча, почта, радио һәм электр станцияләре, фельдшер-акушерлык пункты, клуб яки мәдәният йорты, китапханә, совхоз бүлекчәсе һәм терлекчеләр йорты, ким дигәндә башлангыч мәктәп, промышленность тауарлары һәм азык-төлек кибетләре эшләгән. Бүген Вояды белән Туртыкта сыңар гына да терлек сарае калмаган, ашлык амбарлары юкка чыккан, сигезьеллык мәктәпләр ябылган, почта эшләми, мәдәният йорты дигәннәре атнасына бер-ике мәртәбә генә ачылгалый. 1832 елда нигезләнгән һәм 1920 елда халык саны 620 гә җиткән Вояды авылы бүген үлеп бара. Авыл кешесенә монда гомер итәргә бертөрле эш тә, хәтта элек волость үзәге булып торган Яңа Уртавылга барып кайту өчен юньле юлы да юк. Уртавылдан Воядыга кадәр арадагы юлга ташлы ком гына салып чыкканнар, яңгыр яуды исә аннан үтеп йөрү – олы бәла.

Туртык – Воядыдан 6 чакрымда. 1926 елда 686 кеше яшәгән авылга кадәр юлга да, урыны-урыны белән генә, ташлы ком чәчкәннәр. Туртык – якындагы 5-6 елда аяк сузар сыман. Анда бүген 88 йорт берничә урам ясап утырса да, кешеләр гомер иткән хуҗалыклар саны 30 га да тулмый. Анда бернинди ферма, амбар, келәт, кибет һәм, әлбәттә, мәктәп тә калмаган. Бер ягы сокландыра – туртыклылар тарихлары белән горурланып, аны саклап яши. Әле 1847 елда ук Пермь ягыннан килгән, анда Солтанай мәдрәсәсен тоткан ишан Мөхәммәт-Мөкыйм хәзрәт Туртыкта ике катлы, күренеше белән бүген дә сокландыргыч мәчет төзеттергән. Карагай һәм ак чыршы кебек агачларын туртыклылар үзләре Пермь ягыннан ат белән ташыган. Шук ук туртыклылар көче белән, әмма Мөкыйм хәзрәт хисабына ишан өчен ике катлы бик шәп йорт та тергезелгән. Имеш, ишан йорты 40 бүлмәдән хасил булган, дип сөйлиләр, иллә мәгәр бер хатыны, өч баласы булган хәзрәткә 40 бүлмәле мәшәкать нигә кирәксен, ди?.. Мөкыйм хәзрәт үзе 1897 елда Пермьгә барган җиреннән вафат булган, аны атлар белән алып кайтып, Туртык зиратында зурлап җирләгәннәр. Зират уртасында кызыл кирпечләрдән салынган, өсте тимер челтәрләр белән бизәлгән гаҗәеп зур төрбә бар, аның эченә дүрт ягы да матур язулар белән нәкышләнгән биек таш куелган. Ташның бер ягын мондый мәгълүмат бизи:

«Туртыйк Мөхәммәт-Мөкыйм ишан изге гомерләрен дин гыйлемнәре серен, изге пәйгамбәрлекне төшендерүгә һәм динебезне терелтүгә сарыф итеп, 66 яшендә, шәүвәл аеның 27 сендә, 1897 елда мәңгелек йортка күчте.»

Ташны Сарапул шәһәрендә оныгы Нияз Насретдинов ясаткан, язуларны Туртык вәкиле Габделхәким төшергән. Шушы ук төрбәгә ишанның хатыны һәм балалары да җирләнгән. Ямьле-шаулы булсын дигәннәрдер, каберләр янына чегәрчен (карагайны шулай дип атадылар микән?) агачлары да утыртканнар. Бер гасыр вакыт узгач, алар инде 40-50 метр биеклеккә үсеп җиткән, тамырлары төрбә диварын урыныннан этәрә һәм яргалый башлаган, шуңа күрә Туртыкның миһербанлы һәм булдыклы егетләре без килү алдыннан гына дәү кран яллаган да, төрбә эчендәге агачларны кистереп алган. Шундый ук булдыклы егетләр XIX гасыр уртасында Мөкыйм хәзрәт төзеткән мәчеткә 2005 елда затлы ремонт үткәргән. Ихатасы төзекләндерелгән, идәннәренә келәмнәр җәелгән Аллаһ йорты бүген дә сокланып туймаслык. Кызганыч, аңа хәзер Корбан гаете һәм Ураза бәйрәмендә генә ирләр җыела шул...

Байсар авылы урыны – Туртык карьясеннән 8 чакрым ераклыкта. Әле аңа да һичьюгы Воядыдан Туртыкка кадәр сузылган ташлы юл алып барадыр, дип өмет иткән идем. Әмма Туртыктан чыгуга ук – як-ягында биеклеге белән җиңел машина түбәсен дә узып китәрдәй үлән баскан сукмак. Ул әледән-әле куе агач баскан урман эченә боргаланып керә. Анда исә үзеңне бөтенләй тоннельгә эләккәндәй хис итмичә булмый, чөнки машина түбәсе өстендә ике яктагы агач кәүсәләре бер-берсенә килеп кушыла. Бу куелык тоташ арка-дуганы хәтерләтә, әмма аның эченә күп очракта кояш нурлары да үтеп керә алмый. Йә Ходаем, байсарлылар ни сәбәпле мондый ташландык ояга килеп урнашты да, мондый яшерен баз эчендә ни рәвешле гомер итте икән?..

Әле Воядыда чакта ук мин фәкыйрегезне Фәрит Хәбибуллин атлы 77 яшьлек агай белән таныштырдылар. «Яңавыл» совхозы чәчәк аткан чакта, ул мал табибе булып эшләгән, аннары ихтыяри-мәҗбүри рәвештә Вояды авыл советы рәисе итеп утыртканнар. Шунда 20 еллап камыт тарткан чакта кирпечтән авыл советының хәзерге бинасын төзеттергән, Вояды урамнарына су һәм газ керттерүгә ирешкән. Гаять туры сүзле кешедер, ахрысы, 90 нчы еллардагы «демократлар инкыйлабы»ннан соң совхоз техникасын җитәкчеләр кода-кодачага яисә бөтенләй чит-ятларга сатып җибәрә башлагач, Фәрит агай шул караклар өеренә каршы чыккан. Шуның өчен бичараны 5 ел буена суд юлына йөртеп тинтерәткәннәр. Бик нык таушалгандыр, хәзер кан басымы уйнаудан газаплана, кояш яктысына чыгып йөри дә алмый. Әмма «Байсар» дигәч, «йөгереп» чыгып машинага утырырга барыбер хәл тапты, чөнки үзе дә шушы авылдан бит!..

Мондагы Байсарның төгәл кайсы елда нигезләнүен һичкем әйтә алмый. Берәүнең истәлегендә - 1870, икенчеләрендә 1890 еллар телгә алына. Иң үкенечлесе – Байсар исеменең каян алынуын һәм иң тәүге булып килеп төпләнүче кеше атын төгәл белүче юк! Актаныштагы Байсар авылының Карабәк-Габдулла ханга бәйле шәҗәрәсендә бер тармак Хәбибулла улы Хәмидулла исеме белән тәмамлана. Вояды белән Туртыкта яшәүчеләр дә бүген, тәүге килүче дип, Хәбибулла бабай исемен телгә ала. Башкортстан архивларында Яңавылдагы Байсарның 1917 елга кадәрге тормышын раслаучы сыңар документ та табылмаган. Чөнки, алда әйткәнемчә, Байсар, Туртык, Вояды авыллары һәм тулаем Уртавыл волосте 1929 елга кадәр Уса өязенә һәм аның Камбаркадагы конторасына буйсынып яшәгән. Гаилә корганда, яшьләр шул Камбаркага барып документ юнәтергә, ә егетләр рекрут комиссиясе үтәргә мәҗбүр булган...

Яңавылдагы Байсар турында берничә хатирә яши, берсен бәян итик. Пермь өлкәсе чигенә терәлеп урнашкан һәм уртасында Биз инеше башланган аланга беренче гаиләләр килеп төпләнүгә үк, алар шушы Яңавыл районының Бәдрәш авылыннан законлы теркәлүләрнең барча рәтен белүче Мөэмин Ханнанов атлы кешене чакырып китергәннәр.

(Дәвамы 14 нче биттә).

Яңавылдагы Байсар

●Электры өзелмәгән, дача итеп кулланыла торган йортлар.

●Яңавыл районының әдәби картасы.

(Дәвамы. Башы 12 нче биттә).

Власть ияләре алдында гади халык хокукын яклау буенча «эт каешы» булып беткән Мөэмин агай Байсар авылында үз йортын калкыта башлагач та чамалаган бугай. Ул Минзәлә ягындагы ниндидер ярминкәгә чыгып киткән дә, шунда Кукмара тирәсеннән киез итекләр сатарга килгән Гобәйдулла Гобәев атлы бер кешене Байсарга күчеп нигезләнергә үгетли башлаган, яңа җирне оҗмах бакчасыдай итеп сурәтләп тә биргән. Гобәйдулла агай да туган төбәгендә кытлык-мохтаҗлыктан чыга алмый интеккәндер, көннәрдән бер көнне ул 11 малаен ияртеп, Байсар аланлыгы уртасына килеп төшкән. Киез итек басучыларның бик күбесе мич чыгару нечкәлекләренә дә үтә һәвәс була. Менә шуннан соң инде Байсар халкының һәр хуҗалыгы диярлек киез итек баса, мич чыгара, ә хатын-кызлар тегү тегә, шәлләр бәйли башлый. Билгеле инде, авыл абзарында сыер, бозау, тана, берничә баш кәҗә-сарык асрамыйча да булмый. Ә малны биредә көтүгә куып яки аларның кире кайтуын көтеп җәфа чигәсе юк. Капканы ачуга ук урман башлана бит, маллар шунда кереп китә дә, тамаклары туйгач, иске биш тиендәй ялтырап, үзләре кайтып җитә. Дөрес, кайчакларда байсарлылар урман эчләренә ауга кергәч, балалар иярткән аюларны да очраткалый, ләкин аларның абзар ишекләрен яки умарта оялары җимереп йөргәне юк. Кайчагында менә гөрнәдирдәй яшь егетләр Пермь ягына яки Уфага киткән җиреннән мәңгелеккә югала, әнә шулары эти-әнисе айлар буе өзгәләнсә дә кайтмый...

Җиңел генә уйласаң, Байсар халкын тәү чиратта урман үзе туендыра инде. Ирләр – ауга, хатын-кызлар җиләк-җимешкә йөри, төрле дару үләннәре җыеп кайта. Әмма өстәл һәр төрле сый таләп итә бит ул, шуңа күрә ирләр якын-тирәдәге аланлыкларда иген игә, ә өй янындагы бакчада хәтта 0,8 гектар мәйданда бәрәңге белән чөгендер, кишер, кәбестә үстерә, авылның ярты халкы умарталык тота, хуҗалык сыен күршедәге ярминкә-базарларга чыгармыйча калмый. Шушы иркенлек авыл халкын ишәюгә китерә. 1920 елның 1 гыйнварына Байсар авылында халык саны 542 кешегә җитә. Ләкин инде февраль аенда Сәнәкчеләр фетнәсе кабына, аның ак офицерлар җитәкләгән бер штабы Дүртөйле-Яңавыл зонасында урнаша бит. Ул фетнәдә, урман эченә качып яшәүләренә карамастан, Байсар гыйсъянчылары да катнаша. Ә аннары киләсе 1921-1922 ел кышында башланган коточкыч ачлык яңавыллылар белән берочтан байсарлыларны да кырып сала. Нәтиҗәдә, 1926 елда үткәрелгән җанисәп вакытында Байсар авылында 107 йортта гомер итүче 439 кеше генә теркәлә. Тик болары да әле соңгы афәт түгел. 1929 елда халыкны колхозларга куып кертә башлыйлар. Каршы чыкканнар, кулак ярлыгы тагылып, ерак Себергә яисә Магнитогорск каласын төзүгә сөрелә. Ни кызганыч, Байсар авылында сайлау хокукларыннан мәхрүм ителүчеләр яки сөргенгә озатылучылар турында да бер мәгълүмат та сакланмаган. Дөрес, авылда XIX гасырда ук ике катлы итеп төзелгән мәчет манарасын кисүче Фәрди Сәләховның исемен онытмаганнар, ул бәндә Бөек Ватан сугышыннан исән-сау әйләнеп кайтса да, бер елдан соң ук кое казыганда йөрәк өянәге башланып аяк сузган. Ә мәчет үзе революциягә кадәр башлангыч мәдрәсә булып та файдаланылган. Дөрес, утызынчы елларда «власть» таләбе буенча, Байсар уртасында мәктәп бинасы һәм клуб та төзеп өлгерткәннәр. Байсар авылыннан 38 кешенең яу кырында һәлак булуы билгеле. Байсар халкы авыл советы үзәге булган Вояды ясалган обелискка үз авылдашларының исемнәрен өстәп куюны ялварып йөрсә дә, ул үтенеч тә үтәлмәгән. Яңавылда яшәгән кәе Воядыга килеп «идарә итүче» Марат Яруллин кебек рәис өчен юкка чыккан Байсар ветераннары – бар ни дә, юк ни...

Колхоз чорын искә алган чакта Туртык авылында яшәгән Галия апа Шәйдуллина хатирәсен искә алу бик урынлы:

«Колхоз вакытында халыктан налог җыеп җанны ашадылар. Һәр йорт саен 8 кг сары май, 40 кило ит, 300 йомырка, мал тиреләрен, сарык йонын алдылар. Налог түләмәгән өчен сыерларга тикле алып чыгып киттеләр. Ач булдык. Аю көпшәсе, кукы, кычыткан ашап үстек. Черек бәрәңгедән күмәч пешердек. 9 яшьтән олыларга ияреп эшкә йөрдем. Сугыш вакытында сыер, үгез җигеп җир тырмаладык, кул белән чәчтек, урак белән урдык. Ашлык күп булса да, халыкка бирелмәде. Аны соңгы бөртегенә тикле җыеп, Яңавылга һәм мөгәҗәе (икмәк склады) булган ерак авылларга алып киттеләр, ә язын минем кебек яшүсмер кызлар һәм тол хатыннар шундагы амбарлардан 32 килолы капчыкларга тутырып, симәнәлек ашлыкны, буа-елгаларны ера-ера, кире алып кайтты. 38 әр чакрым ара үткән чакта суга төшеп үлүчеләр дә аз булмады. Бер кесә ашлык өчен дә төрмәгә утырттылар. Безнең авылдан Зөһрә Газизова, Фәсыйха Гайнуллина, Мәүҗия Рәхмәтуллина кебек апалар шулай утырып кайтты»...

Мин фәкыйрегезгә Яңавылның үзендә Байсарның 1926 елда үткәрелгән җанисәп кәгазьләрен, ә Воядыда Байсар хуҗалыкларының 1940 һәм 1949/1951 еллардагы исемлеген укып чыгу бәхете эләкте. Ләкин 1940 елгы кенәгәдә үк Байсар авылында инде 77 хуҗалык кына саналган. Барча исемлекләрдә дә Хәбибуллин, Гобәев, Вәлиев, Гәрәев, Ханнанов, Шәңгәрәев кебек фамилияләр күп теркәлгән – болар барысы да авылны саклап калырга тырышучылардыр, дип аңлыйм. Алардан тыш, бу Байсарда Дәүләтов, Бәшәров, Шәйморатов, Шәфыйков, Габдрахманов, Гарифуллин, Шакиров, Садыйков, Закиров, Гатин, Ситдыйков кебек фамилияләр дә аз түгел – аларын авылның баганалары дип санау артык булмас. Авыл әүвәл Шмидт исемендәге хуҗалык булып йөргән, аннары «Туры юл»га, 1957 елдан соң «Буй» совхозына әверелгән. 60-70 нче елларда «Яңавыл» совхозының бер бүлекчәсе булып торган, аның фермаларында 1200 баш тана симерткәннәр. Авылда әүвәл – җидееллык, аннары сигезъеллык мәктәп эшләгән. Урта белем алырга теләүчеләр йә Пермь өлкәсенең Буренка авылындагы, йә халык язучысы Нурихан Фәттах та укыган Уртавыл, йә Әмзә мәктәбенә йөргән. Фәрит абый Хәбибуллинның санап каравы буенча, кайбер елларда Байсардагы 30 га якын бала чит авыл мәктәпләренә йөреп белем алган.

Туртык, Вояды, Байсар авылларына замананың иң рәхимсез күсәге 1990 елда властька «демократик юл» белән менгән хөкүмәт тарафыннан килеп төшкән. Совхоз җимерелгән, караклар хакимиятенә «җәһәннәм»дәге ниндидер Байсар яки Туртык авылларына юл салуның һәм аларда нинди дә булса сәнәгать цехы-мастерское төзеп куюның, гомумән, илне тергезүнең бөтенләй кирәге юк. Җиде ел элек Байсар яшәүдән туктаган, хәзер, әнә, Туртык авылы соңгы сулышларын алып ята, Вояды өчен дә офыкта явыз аҗаган уйный. Авыл артыннан авыл юкка чыга, ил таркала...

Кичә генә елмаеп йөргән якын дустыңны соңгы юлга озату да читен. Ә юкка чыккан авыл кадәр авыл урынында басып тору газап. Бу Байсарда да бер ярым гасыр буена минем авылдашлар, туганнар яшәгән бит. Мәгъйшәт мохите җиңел булмагандыр, алар арасыннан үсеп чыккан талантлар исеме һаман яңгырамый. Авыл туфрагында басып торган чакта Байсар ахыргача үлмәгәндер сыман. Әнә бит, унлап иске йортны электр чыбыгыннан аерып бетермәгәннәр. Биш-алтылап хуҗалыкта йортлар түгел, мунчалар да исән. Берничә кеше умарталык тота. Хәтта, бер йортны ниндидер килмешәккә файдаланып торырга арендага да биргәннәр, ди. Авыл уртасыннан Биз елгасын бүлеп буа ясау гадәте дә калган. Анда, бәлки, нәкъ элеккечә үк, җәйге ялга кайткан бала-чагалар да суда коенадыр. Әмма бернинди моң да, сөйләшү авазы да, балаларын, малын, каз-үрдәген эзләп чакыручы газиз аналар тавышы да юк. Зираттагыдай тынлык... Әлеге Байсар уллары-кызлары кая гына таралып бетте дә, кайсы кавемнәрне баетып ята икән?.. Ходай ярлыкасын!..

Киткән чакта Яңавыл районының үзәк китапханәсенә сукмак салдым. Директоры Гөлнара Вәлиеваның әнисе шул ук Байсар авылында үскән булып чыкты. Ул да Байсар тарихын эзли, кызыксына икән. Әмма хезмәт вазифасы ныграк баса, ә аның буенча Яңавыл кешеләре өчен халыкара дуслык бәйрәме уздыру заллары да, кечкенә музей да кирәк. Күптән түгел генә районның Әдәби картасын булдырганнар, аны И.Юзеев, Н.Фәттах, К.Шәфыйкова, Г.Әмири фотолары бизи. Күз айлары кергүгә, Нурихан агага багышланган конференция дә уздырырга җыеналар икән. Мин фәкыйрегезне чакырырга да вәгъдә беркеттеләр. Шулай итеп, Ходай кушса, Яңавыл туфрагына әле янә баруым да мөмкин. Бәлки, Байсарның яңа кешеләре белән дә танышырмын. Бирсен Ходай!..

Вахит ИМАМОВ.
Автор фотолары.

●Туртык зиратында ишан Мөхәммәт-Мөкыйм төрбәсе.



●Биз елгасы буена төзеп куелган элеккеге клуб.

Илдар Әюпов – Казанның реклама һәм дизайн өлкәсендә креатив проектлар иҗат итә торган «Теория» дизайн-студиясе җитәкчесе. Аңа – 38 яшь. «Теория» студиясе, нигездә, видео һәм анимацияләр, логотиплар һәм фирма стильләрен әзерли.

Иң шәп проектым – «ӘЛБӘТТӘ»

– Илдар, сез кайсы яклардан?

– Мин 1983 елны Түбән Камада туганмын. Шул калада инглиз телен тирәнтен өйрәтә торган рус лицеен тәмамладым. Балачакта спорт белән дә шөгыльләнгән идем. Әнием Рита – хисапчы, соңрак салым буенча инспектор булып хезмәт куйды. Әтием Хәлил 1990-2000 елларда Татар иҗтимагый үзәгенең Түбән Кама бүлеген җитәкләде, шуңа чын татар мохитендә үстем. Мәктәпне тәмамлагач та, 2001 елда Казан дәүләт университетына юл алдым. Анда укыганда, «Студентлар язы» фестивален үткәрештем. Аннары БДБ илләре студентлары арасындагы проекта җиңеп, алмашу программасы буенча, 2004 елда беренче тапкыр АКШка киттем. Анда бер ел буе педагогика өлкәсе белән бәйле белем алдым. Ул вакытта безнең илдә һәр җирдә дә интернет юк иде әле. Шуңа күрә АКШта интернет киңлегендәге төрле блогларны өйрәнү минем өчен кызык булды, күп сайтларны да карадым.

2006 елда миңа «Алгарыш» программасы буенча АКШта тагын бер ел укырга насыйп булды. Әлеге дәүләткә җәмәгатем Айгөл дә барды. Беренче тапкырында ул анда бер ел татар телен укытты. АКШка икенче тапкыр баруы мәшһүр Фулбрайт уку-укыту программасы грантын отуы белән бәйле иде. Айгөл Аризона штатында бер еллык программаны ике ай эчендә узарлык суперинтенсив рәвештә укытыла торган татар теле дәресләрен алып барды. Әлеге дәресләргә йөрүчеләрнең татар телен өйрәнү буенча үз максатлары бар, АКШка инде өченче тапкыр барып, шул ук интенсив курсларда катнаштым.

– Әү дизайн өлкәсе белән кайчан кызыксынып киттегез?

– Компьютер программаларын яхшы белгәнгә күрә, миңа иҗади заказлар белән мөрәҗәгать итә башладылар. Иҗат белән кызыксынуым балачактан килә. Шуңа күрә дизайн өлкәсе күңелемә якынрак икәне бик тиз аңлашылды. Илебездәге беренче заказым мөселман киеме кибете өчен логотип булды. Россия һәм Татарстандагы компанияләр өчен яңа музейлар ясауда катнаштым. Төрле ширкәтләрдә эшләдем. Портфолио яхшы булгач, яңа эш табу да кыен булмады. Әмма кемдер җитәкчелегендәге оешмаларда эшләү туйдыра башлады, һәм мин 2012 елда үз эшемне ачып җибәрдем. Студиядә башта өч кеше генә хезмәт куйды, хәзер без – унбиш.

Без медицина мәгълүмат системасы дизайнын да эшләп чыктык, ул Татарстанда гына түгел, Россия күләмендә дә кулланышта. 2013 ел Универсиадасы өчен мобиль кушымталар ясадык. «Татнефть» заказын да үтәгәнебез булды. Укучылар өчен, балаларга һөнәр сайларга булыша торган платформа ясап бирү үтенече белән мәскәүлеләр мөрәҗәгать итте, алар бу эшебездән бик канәгать калды. Шулай итеп студиябез үз эшчәнлеген көннән-көн ныгытты.

– 2021 елда сез барлык иҗатчыларга мөрәҗәгать итеп, яңа типтагы татар бизәкләре бәйгесе игълан иттегез һәм I урын алучыга йөз мең сум премия дә тапшырдыгыз...

– «Яңа татар орнаменты» бәйгесен инде бер үк төсле милли орнаментларны кулланып тәмам аргач, игълан иттем шул. Чөнки мондый иҗади эшләнмәләр бер-берсен кабатлый башлады. Яңа үзенчәлекләр дә күренмәде. Татар дизайнерлары, рәссамнары һәм фикерли белүче, җитди рәсемнәр ясый алучы тележ кем... бу бәйгедә катнаша алса да, безгә нибары 28 иҗади тәкъдим килде. Бу бәйге бераз шау-шу да куптарды, чөнки кайберәүләр: «Сез безне традицион бизәмнәребездән читләштерергә телисез», – диде. Ә бит без бәйгедә катнашучыларга нибары тарихи нигезне исәпкә алып, әмма аларны кабатламыйча, күпләрнең күңеленә хуш килерлек яңа татар бизәкләрен иҗат итәргә генә өндәдек. «Смена» заманча сәнгать галереясында иҗатчылар өчен үз орнаментларыбыз хакында лекция дә укыдым. Татар орнаменты кулланышына багышланган лекцияләр Милли китапханәдә дә үтте. Конкурсның жюри составын практикага ия белгечләрдән сайлап алдык, аңа Ш.Мәрҗәни исемендәге Тарих институты этнологик тикшеренүләр бүлегенең фәнни хезмәткәре Динә Гатина-Шәфыйкова, «Лорен-Имидж» компаниясе директоры Илдар Әхтәмов, «Ак Барс Цифровые Технологии»ның арт-директоры Марат Хәбибуллин, татар фольклорчысы Фәнзилә Җәүһәрова, этно-дизайнер Лариса Чубукова, Милли китапханә директоры урынбасары Тәбрис Яруллин керде. Тәҗрибә туплаган иҗатчылар хезмәтләрен көтсәк тә, эшләрнең күбесе студентлар тарафыннан ясалган иде. I урынны борынгы руннарны сурәтләгән иҗатчы яулады. Әйе, премияләрне өләштек. Тик әлеге сәнгати тәкъдимнәрне, бизәмнәрне гамәлдә кулландык, дип әйтә алмыйм.

– Әлеге авыррак чор... Ә менә киләчәктә шушы конкурсны дәвам итәрсезме соң?

– Бу конкурсны кайчан да булса бер игълан итми калмас идем төсле. Чөнки дизайн студиябезгә мөрәҗәгать итүчеләрнең күбесе: «Безнең проектыбыз өчен татар бизәкләре кирәк, әмма алар оригиналь булсын», – дип сүз башлый. Минемчә, татар орнаменты – ул катлаулы түгел, мин – визуал, шуңа күрә дә милли, чәчәкле орнаментларыбызга бертөслелек хас дияр идем, орнаментларыбыз башкаларныкына да охшаш. Безгә үз, заманча яңа орнаментларыбызны, яңа символларыбызны тудырырга вакыт. Шуңа күрә әлеге конкурсның дәвамы булмый калмас, мөгаен!

– Илдар, мөһим проектларыгыз бик күп, шулар арасыннан татар теле белән бәйлеләрен барлыйк әле.

–Татар теле, татар фәне белән таныштыруны максат итеп куйган «Әлбәттә» фәнни-популяр проектым – elbette.ru – ул минем тормышка ашкан хыялым. Һәм иң әһәмиятлесе! Мин төрле фәннәрне яратам, фән яңалыклары белән даими кызыксынам, шушы темадагы видеоязмаларны карыйм. «Әлбәттә» өчен беренче тапшыруларыма университеттагы укытучыларымны чакырдым. Әйтик, филология фәннәре докторлары Әлфәт Закирҗановны һәм Дания Заһидуллинаны. Гомумән, «Әлбәттә» проекты – ул замана галимнәре, татар тарихы, тел белеме, татар әдәбияты, сәнгате һәм фольклоры белгечләре белән яздырылган кыскача (5-20 минутлык) компактлы видеолекцияләрдән гыйбарәт. Алар – тапшыру стилистикасы мондый темалар яңалык булган тамашачы өчен җайлаштырылган. Республика фәнни җәмгыятенең тәҗрибәсе зур һәм базасы киң булса да, фәнни потенциал шушы юнәлешле видеолекцияләр аша тормышка ашырылмаган иде. Бар галимнәребез дә киң катлау кешеләренә мәгълүм түгел, аларның фәнни хезмәтләрен белеп бетермиләр.

Архитектура докторы Нияз Халит белән әңгәмәләр язып калдыруыбызга да куанып бетә алмыйм. Кызганыч, бу хөрмәтле зат әлеге очрашулардан соң нибары ярты ел гына яшәде. Мондый язмалар тарих өчен дә кирәк. Кем, ни хакында сөйләгән, сөйләм рәвеше нинди булган, тышкы кыяфәте...

«Әлбәттә»нең бер юнәлеше – «Тыпыр-тыпыр грамматика». Аның аша без татар теленең төзелеше хакында лаконизм белән, күңелле итеп сөйлибез!

Укыту әсбапларының ничек язылуын, нәшер ителүен дә белән дияр идем. Чөнки Айгөл АКШта биреләчәк белем курсын язгач, бу китапның дизайн версткасын үзем әзерләдем. Ул курс бик үзенчәлекле иде: бер еллык программаны нибары ике ай эчендә өйрәтү. Бу максатны тормышка ашыру өчен Айгөл белән бергәләп инглиз телендә сөйләшүчеләргә татар телен өйрәтү буенча уку әсбабын төзергә туры килде.

Без татар грамматикасы, тарих, Г.Тукай, Ш.Мәрҗани, татар театры тарихы буенча видеороликлар, төрле видеолекцияләр, туган тел турында анимация роликларын да иҗат итәбез. «Татарча Әлифба» мобиль кушымтасын да ясадык. Ул түләүсез күчереп алына.

«Үчтеки» проекты буенча балалар өчен китаплар нәшер иттек. Чөнки беренче улыбыз тугач, берәр татар контентын эзли башладык. Ютубта бихисап рус, инглиз контентлары бар, әмма татарныкы юк иде. Нурбулат берчак инглизчә татарчага караганда да яхшырак белде әле. Хәзер без инде күп балалы гаилә. Улларыбыз Нурбулат, Нариман, Искәндәр, Арслан үсә барган саен, алар яратып укырлык татарча китапларын киләчәктә дә нәшер итәчәкбез. Чөнки без мондый татарча балалар китапларын үзебез булдырырга тиеш. Минем татарча белүем дә әлеге проектларны тормышка ашырырга булышты, җәмәгатем Айгөл дә – татар теле белгече. Айгөл шул чакта балалар китаплары өчен үзе әйтемнәр уйлап тапты, үзе шигырьләр барлады. Боларның барысына да вакыт кирәк. Аннары боларның берсе дә коммерция проекты түгел бит, моны без үз акчабызга эшлибез.

– Сезнең студия татар теле, тарихы белән бәйле заказларны да башкарамы?

– Әйе. «Теория» дизайн студиясенең заказ буенча эшләре дә байтак. Мәсәлән, Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институты белән берлектә иҗат ителгән тарихи темадагы «Татарларның кыскача тарихы» роликыбыз иң еш каралган роликлардан санала. Татар теленә өйрәтә торган «Әйдә! Online – Изучаем татарский» проекты өчен утызлап серия әзерләүдә катнаштык. Студиябез, Казан башлыгы кушуы буенча, метрополитен, кунакханәләр экраннарында татар теленең нигезләрен өйрәтә торган видеоязмалар ясады. Аннары «Сәлам!» проектын тормышка ашырып, Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыгы базасындагы Мәгариф структураларын үстерү институты заказы буенча татар телендәге уку әсбапларының дизайнын башкардык. «Сәлам» китаплары 2016 елны чыгарыла башлаган иде, быел инде бу серия китаплары тугыз сыйныф өчен әзер. Шушы проект белән якыннан танышырга теләүчеләр selam.tatar сайтына рәхим итә ала.

Зилә НИГЪМӘТУЛЛИНА.

Мәчкәрәдә фәнни җыен

Кукмарада «Бишенче Мәчкәрә укулары» төбәкара фәнни-гамәли конференциясе узды. Быел «Мәчкәрә авылы: тарих һәм яңарыш проблемалары» дигән темага багышланган җыен беренче тапкыр Россия күләмендә үтте.

«Мәчкәрә укулары» – Татарстан Диния нәзарәтенең зур эше. Укулар белән берләттән халкыбызга тагын да колачлырак идеяләр керә башлады. Хәзер мәчет янында кечкенә мәдрәсәләр салалар. Мәчетләр гыйбадәт йорты гына түгел, мәдәният, тәрбия йорты да булырга тиеш. Йөздән артык мәчеттә татар телен өйрәтәбез, 800дән артык мәчеттә гарәп телен өйрәнү мәктәпләре бар. Болар – шундый укулардан башлангыч алган чаралар», – диде чыгышында Татарстан Диния нәзарәтенең «Аксакаллар шурасы» рәисе Айрат хәзрәт Әюпов.

Аның әйтүенчә, бүгенге көндә 20 ләп районда шундый укулар бар. Кукмара районы мәгариф бүлеге җитәкчесе Илфат Әхмәдуллин, тарихны искә алып, Мәчкәрә авылы мәдрәсәсендә физика, астрономия, мантыйк, каллиграфия-язу, җыр һәм рәсем буенча да күнекмәләр бирелгән, гарәп һәм фарсы телләрен өйрәнгәннәрен әйтте.

Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге Казан югары мәдрәсәсе җитәкчесе Ильяс хәзрәт Җиһаншин Мәчкәрә авылының имам-хатыйбы Мөнир хәзрәт Йосыповка мондагы зиратны «үзенең өен караган кебек» карап торуы өчен рәхмәтен җиткерде.«Авылдан чыгып киткән кешеләр нәсел-тамырларын эзләп кайтсалар, иң элек, мәхәллә имамына килә. Зираттагы каберлекләргә дә игътибар итә. Имамнарыбыз вәгазьче генә түгел», – диде ул.

Яшь буынга динебезнең әхлакый принципларын, бай тарихыбызны җиткерү, мәдәни һәм рухи мирасыбызны саклап калу өчен конференциядә катнашучылар түбәндәге тәкъдимнәрне гамәлгә ашырырга кирәк дип тапты:

1. Мәчкәрә авылы Беренче җәмигъ мәчетен торгызу эшләрен дәвам итү.

2. Мәчкәрә авылы зиратында җирләнгән, изге хезмәтләре белән якты эз калдырган олуг шәхесләребезнең, галимнәребезнең, имамнарыбызның каберлекләрен саклау өчен эш алып бару.

3. Мәчкәрә укуларын ике елга бер үткәрү.

4. Конференция материалларын китап рәвешендә бастыру.

5. Алтынчы Мәчкәрә укуларын авыл мәчетенең 230 еллыгына багышлап үткәрү.

6. Кукмара районының мәктәп укучылары арасында Мәчкәрә авылы мәчетенең 230 еллык юбилее кысаларында татар халкының рухи мирасы буенча бәйге үткәрү.

7. Мәчкәрә мәдрәсәсе һәм мәчете турында документаль фильм төшерү.

«Алмачуар»

● Мөхәммәтхафиз үзе төзегән йорт.

Тормыш чынбарлыгына нигезләнгән әдәби әсәрләрдә чагылыш тапкан образлар һәм персонажларның, гадәттә, прототиплары була. Бу мәсьәләне татар классигы Галимҗан Ибраһимов та (1887–1938) читләтеп үтмәгән, әлбәттә. Аның «Кызыл чәчәкләр» повестендагы Фазыйлның чынлыкта журналист Хәлим Искәндәров (1888–1958), «Безнең көннәр» романындагы Баязит каринның журналист һәм тәрҗемәче, жандармерия белән яшерен хезмәттәшлек иткән Исхак Бикчурин (1886–1913) булганлыгы хакында язучы һәм әдәбият галиме Мөхәммәт Мәһдиев язып чыккан иде («Казан утлары», 1977, №1). Дөрес, ул үзенең дәлилләрен нинди дә булса документларга яки белгән кешеләрнең сөйләвенә нигезләнеп түгел, ә типологик фактлар ярдәмендә китерә. Бу уңайдан шунысын да әйтергә кирәк, әдипнең башка әсәрләре әлеге хосуста өйрәнелмәгән.

Әдип турында төзеп бастырган ике томлы хезмәтем өчен Авыргазы районының Г.Ибраһимов исемендәге бүләкне тапшыру тантанасына баргач, миңа Башкорт дәүләт университетының Стәрлетамак филиалы татар һәм чуаш кафедрасы мөдире, доцент Илсур Мансуров һәм шул ук кафедра укытучысы, доцент Нәсимә Мөкыймова «Алмачуар» исемле хикәядә исемнәре телгә алынган кешеләрнең кайберләре әдипнең авылдашлары булганлыгы турында әйткәннәр иде. Бу хакта белүчеләрнең берсе Нәсимә ханымның ире Фәнзилнең 90 яшьлек әтисе Рәшит ага икән. Әлеге мәсьәлә зур кызыксыну уятты һәм Солтанморат авылына махсус килергә вәгъдә бирдем.

Әсәр, автор үзе күрсәткәнчә, 1922 елның февралендә Казанда языла һәм шул ук елда нәшер ителә. Аннары ул тагын өч мәртәбә аерым китап буларак дөнья күрә (1927, 1967, 1990). Янә язучының төрле елларда басылган «Сайланма әсәрләр»ендә, төрле басмаларда урын ала.

Вәгъдә – иман, диләр. Алдан хәбәрләшеп куйганча, чираттагы җәйге ялымда Солтанморат авылына бардым. Анда мине әйтелгән мәсьәләне яхшы белүче Рәшит ага Рәхмәтуллин, аның улы Фәнзил, килене Нәсимә, аларның улы Данияр һәм кияүләре Таһир Стәрлетамак шәһәреннән махсус кайтып, авылдагы өйләрендә көтеп тора иде. Әүвәл Рәшит ага әсәрдәге вакыйгалар, андагы телгә алынган кешеләр хакында сөйләп бирде. Аннары Фәнзил үзенең җиңел автомобилендә йөртеп, «Алмачуар»дагы геройларның каберләрен, алар туып-үскән йортларның урыннарын, әсәрдә телгә алынган елга-күлләрне һәм башка топонимик объектларны күрсәтеп, үзе белгәннәрне бәян итте. Шулай йөргәндә, әсәрдә колыннар алдыннан тасвирланган бурлы бияне эзләтеләп, аркандагы шундый ук бер биягә тап булдык. Аны күргәч, тексттагы шундый юллар искә төште: «...минем бүген-иртәгә колынларга торган бурлы бия Өзән елга буенда, болынлыкта йөри. Әткәй аның муенына зур арканны бәйләгән дә тышауламый-нитми генә җибәргән. Арканның икенче башына кызыл калын дуга тагылган. Минем бөтен күңелем менә шул дугасын, арканын өстерәп, су буенда, таллар арасында акрын гына йөргән бурлы биядә».

Рәшит ага хатирәләрен, Фәнзил сөйләгәннәрне мин тарихи чыганаклар белән дә чагыштырып чыктым. Бу хосуста миңа Солтанморатта туып-үскән Мидхәт Алимбековның 2017 елда Уфада нәшер ителгән «Верой и правдой отечеству служили... История татарской деревни Султанмуратово XVII–XX вв.» дигән хезмәте зур таяныч булды.

Сүзне әүвәл әсәрнең төп геройларыннан берсе булган Хафиздан башлыйк. Аның турында мәгълүмат текстта болай китерелә: «...Безнең әткәй Мөхәммәтхафиз исемле булса кирәк. Буйга зурлыгы өчен аны Озын Хафиз дип йөртәләр. Ул яшь чакта имән кебек таза, лачын кебек үткен, арыслан кебек гайрәтле булган, дип сөйлиләр. Тирә-якта теләсә сугышка булсын, теләсә көрәшкә булсын, аңа тиңдәш чыкмаган. Иң зур Сабан туйларында да ул әллә кайлардан килгән данлыклы көрәшчеләрне шаяртып кына чөеп ташлый торган булган...»

Документларда Мөхәммәтхафиз (1853–?) буларак теркәлгән бу шәхеснең нәсел башы хәзерге Башкортстанның Балтач районы Чуртанлыкүл авылы мулласы Исмәгыйль Рәҗәповның улы Гобәйдуллага (1751–1814) барып тоташа. Аның ике улының берсе Рәхмәтулла (1784–?) булып, аның улы Мөхәммәтәмин (1817–?), аның улы Мөхәммәтхафиз. Аның фамилиясе бабасының исеменә нисбәтән Рәхмәтуллин дип йөртелә.

Мөхәммәтхафизның Мөхәммәтсадыйк (1879–1958), Әхмәтзакир (1883–1952), Мөхәммәтшәкүр (1887–1958), Мансур (1896–?) исемле уллары була. Әхмәтзакирдан башкалары Беренче бөтендөнья сугышында катнашкан. Димәк, әсәрдә Хафиз балалары буларак телгә алынган һәм кеше үтерүдә нахакка гаепләнеп егерме елга каторгага җибәрелгән Шәяхмәт, гармунчы Фәхригә ябышып чыккан Гайния язучы тарафыннан уйлап чыгарылган гына персонажлар яки чынлыкта авылда шундый хәлләргә дучар булган прототиплардан алынган.

● Закир һәм Маһитап кабере.

Билгеле ки, әсәр Закир исемле малай исеменнән бәян ителә һәм ул чынлыкта Мөхәммәтхафизның икенче улы Әхмәтзакир. Хатыны Дәүләкән районындагы Хөсәен авылы Хафиз кызы Маһитап (1897–1977) белән Зиннур (1927–2002), Әнвәр, Әлвидаг исемле уллар тәрбияләп үстерәләр.

Зиннур белән хатыны Миңнединә Сәмигулла кызының (1927–2001) (Чишмә авылыныкы) балалары Гөлйөзем Учалы, Марат Казан, Ришат (1957–2020), Ринат Чаллы, Лена Салават шәһәрләрендә яши.

Шунысы кызыклы, Мөхәммәтхафиз заманында үзе төзегән һәм шау-гөр килеп берничә буын гомер кичергән өй хәзер дә бар. Ихатага керер алдыннан әсәрдә сөйләнелгән капка төбендәге вакыйга исемә төште: «Миңа, күп дигәндә, җиде-сигез яшь булгандыр, әллә нинди коточкыч кара йөзле, усал жылтыр күзле бер башкорт һич күтелмәгән җирдән үзенең кара бурлы, матур, зур симез биясен безгә бүләк итте, – алай-болай гына түгел, үз кулы белән йортымызга китерә, капка төбендәге зур ташка утыра да кешеләр алдында дога кылдырып бирә. Авыл халкы бу эшкә башта аптырап кала: ни сәбәптән, бу тирә-якка усаллыгы, саранлыгы белән даны чыккан явыз көрәшче Әлемгол, тик торганда, үзенең гомерлек дошманы Хафизга (безнең әткәйгә) бер бия китереп, фатыйха кылдыра?!»

Шөкер, без Лена белән ире Илшат шәһәрдән ялга кайткан вакытларына туры килдек. Алар зур илтифат күрсәтеп, үзләре белгәннәрне сөйләде. Өйнең бары тик кайбер таушалган бүрәнәләре генә алыштырылган булып чыкты. Ләкин тарих ихатага кайбер үзгәрешләр дә кертмәнлеге ачыкланды: Алмачуар тугач, алып кайтып бияне баганасына бәйләп куйган кое инде юк икән, аның урынында җиләк түтәлләре хасыйл булган. Шунысын да әйтергә кирәк, Рәшит ага сөйләгәнчә, Әхмәтзакир белән Г.Ибраһимов бик дус булган.

Мөхәммәтхафизның өлкән улы Мөхәммәтсадыйкның хатыны Таибә Бакый кызы була (1887–1969). М.Алимбеков тикшеренүләреннән күренгәнчә, илдә күмәкләштерү шаукымы башлангач, 7 кешелек бу гаиләгә кулак ярлыгы тагылып, аның башлыгы 1926 елда сайлау хокукын-

эзләреннән...

Рәшит ага улы Фәнзил, килене Нәсимә белән.

нан мәхрүм ителә, 1929 да тегермәндә ашлык тарттырган өчен түләмәүне сылтау итеп барлык мөлкәт тартып алына, 1931 дә арендага тегермән алганы һәм яллы хезмәт көче кулланганы өчен төрмәгә ябыла. Бу вакытта гаиләнең 7 дисәтинә чәчүлек җире һәм бер сыеры була.

Мөхәммәтсадыйкның улы Ибраһим (1912–?) гомере буе механизатор булып эшли. Аның улы билгеле шагыйрь, татар, башкорт телләрендә күп кенә китаплары булган Салават Рәхмәтулла (1942–2021). Кызы Асия белгечлеге буенча икътисадчы булса да, мәктәп елларыннан ук район, республика матбугатларында шигырьләрен бастыра. 2013 елда «Илһам чишмәләре» шигърият фестивалендә катнашып, җиңүче була. Әйтергә кирәк, С.Рәхмәтулла туып-үскән йорт әле бар. Аннан ерак түгел генә 1929 елда төзелгән кирпеч келәтнең бинасы да үз урынында тора.

Салаватның кызы Резеда Хәсәнова (Рәхмәтуллина) психология фәннәре кандидаты булып җитешә. Казан дәүләт педагогика институтында, Россия Фәннәр академиясе Уфа фәнни үзәгенең Тарих, тел һәм әдәбият институтында, Мәскәүдәге Һөнәри белем үсеше фәнни-тикшеренү үзәгендә доцент, өлкән фәнни хезмәткәр вазифаларында эшли. Хәзерге вакытта Мәскәү шәһәрендә яши.

Мөхәммәтшәкүрнең ике улының өлкәне Әхәт (1920–1987) сугыш алды елларында ук Солтанморат тулы булмаган урта мәктәбендә математика һәм физика укыта. 1941–1942 елларда Кызыл Армия сафларында була. Сәламәтлеге буенча хәрби хезмәттән азат ителә. 1943–1945 елларда мәктәп директоры вазифасын башкара. Мәктәп, колхоз тормышында актив катнаша, колхоз партия оешмасы секретаре була. Аның Әсгать исемле улы мәгълүм. «Бөек Ватан сугышында фидакяр хезмәт өчен» медале белән бүләкләнә. Әлеге бүләккә Зиннур Закир улы, Ибраһим Мөхәммәтсадыйк улы да лаек була. Соңгылары һәм Рәшит «Урак» (Г.Ибраһимов исемендәге) колхозның атказанган колхозчылары исемен дә яулый.

Әхәтнең энесе, ягъни Мөхәммәтшәкүрнең икенче улы Рәшит һәм аның хатыны Рәйхана Зиннәтулла кызы (1933–2021) гомере буе колхозда механизатор, склад мөдире булып эшли. Аларның кызы Зөлфия озак еллар балалар бакчасында тәрбияче булып эшләп, хәзер лаеклы ялда. Өлкән уллары Рәсим Башкортстанда танылган шагыйрьләрнең берсе. Аның «Июль» (Сайланма әсәрләр), «Тәүге тукталыш», «Төймәләр дәвере» дигән шигырь китаплары дөнья күрде. «Гөлләр кешеләргә охшаш» исемле шигырьләр циклы «Офык яктысы» дип аталган җыентыкта басылды. Икенчесе – инде алда әйтелгән Фәнзил үз вакытында Уфада «Нур» татар дәүләт театрында да хезмәт куйган. Хәзерге вакытта Стәрлетамак шәһәрендә Россия тимер юллары системасында эшли. Фәнзилнең игезәге Фәнзилә – хуҗабикә.

Мөхәммәтхафизның дүртенче улы Мансур хакында мәгълүмат әлегә әлләни күп түгел. Без аны Солтанморат авылының беренче мәдрәсәсендә 1913 елда укучы шәкертләр исемлегендә күрәбез.

Билгеле булганча, әсәрдә староста бүләкне гадел өләшми. Шуңа Закир камчы белән селтәнеп, аның битен яра. Текстта бу вакыйга болай сурәтләнә: «Ул арада староста үзе дә килде. Йөзе чыннан да ярылган булса кирәк: ак яулык белән бер күзе бәйләнгән. Мин аңардан курыкмадым, тик аптырап калдым. Ул ачуланмады гына түгел, мине кочаклады, башымнан сыйпады да:

– Мин бала чакта үзем дә атка менеп күп чапкан кеше... Алдан килеп тә, икенченең бүләген бирсәләр, җан түзалмый аңа... Мин сиңа ачуланмыйм, аргансың. Бар кайт инде, – дип, миңа егерме тиенлек көмеш бирде».

Старостаның чынлыкта Җамал Хөснетдинов исемле кеше булганлыгы ачыкланды. Ул яшәгән йортның (Мөхәммәтхафизның бәрәңге бакчасы артындагы урамда) нигезендә хәзер башка кешеләр яши. Күркәм өй, матур хуҗалык. Кызганыч ки, без барганда, хуҗалар каядыр киткән булып чыкты.

Дөрес, әсәрдәге кайбер образларның прототиплары әлегә ачыкланып бетмәде. Әйтик, Әлемголның хәзерге Дәүләкән районындагы Кадыргол авылы кешесе булганлыгы гына мәгълүм. Вилдан һәм Мохтар хакында сүз барганда, Г.Ибраһимовның туганнан туган кардәше Вилдан Ибраһимов (Вилдан – Гыйрфанның бертуган энесе) һәм аның улы Мохтар Ибраһимов (1885–1969) күз уңында тотыла булса кирәк. Ә Хафизның кардәше, зур тормыш тәҗрибәсе туплаган ил карты Сафа бабай, һәр гамәлгә сизгер-уяу күрше карчык Фәтхия әби, Сабан туенда атлар чабышын хәстәрләүче Садыйк абзый, авылның гади кешеләреннән берсе булган Фәхри, аның чая уллары Апуш, Сәппәр, Галәвинең кем икәнлекләре әлегә билгесез кала.

Әсәрдә телгә алынган авыл һәм елга-күл атамалары да чынбарлыктан алынган. Хафиз Сабан туенда көрәштә беренче мәртәбә җиңелү вакыйгасы Чишмә дигән авылда була. Бу авыл Солтанморат җирле үзидарәсенә карый һәм өч чакрымда гына урнашкан. Закир язга чыккач, Алмачуарны Әпсәләм авылындагы байларда күргәнчә, матур итеп кыркытуын сөйли. Бу авыл хәзер Иске Әпсәләм аталышында Авыргазы районы Өршәк җирле үзидарәсенә карый, ул да Солтанмораттан ерак түгел.

Текстка игътибар итик: «Мин бер атуда ике куянны алмак булам: бияне дә сакларга, балык та тотарга. Балык дигәч, малайлар бары беравыздан Кондызлы күл ягына тарта». Бу күл Солтанморат авылыннан ерак булмаган. Хәзерге вакытта аның суы юк, кипкән, әмма ярлары күренеп тора. Бәлки аның чыганагы, ягъни кайчандыр суы агып торган чишмәсе томалангандыр. Чөнки яшәреп үскән агачлар моңа ныклы ишарә. «Юк, мин анда бармыйм, – дим, – әйдәгез Өзән елгага барыйк, анда да шәп каба, – дип, бурлы бия ягына тарта башладым», – ди Закир әсәрдә. Бу – авылдан ерак булмаган елганың атамасы.

Елгалар турында сүз алып барып, Закир янә болай ди: «Беләм, бик беләм: таулар, болыннар буйлап килеп, безнең авылның буеннан аккан бу елга – Өршәккә, Өршәк – Димгә, Дим – Ак Иделгә коя. Ак Идел кая барадыр – анысын бер Алла белә. Тик бик күп дөнья гизгән Сафа бабай гына кайвакыт сөйләп куя: көз көне кошлар китә торган якта, ди, Әчтерхан дигән бер зур шәһәр – борынгы ханнар шәһәре бар, ди, шуның аръягында, ди, гаҗәп зур бер диңгез бар, ди».

Өршәк – Агыйделнең сулъяк кушылдыгы. Башкортстанның Стәрлебаш районындагы Югары Гөлем авылыннан өч километр көньяктан башланып, Стәрлебаш, Стәрлетамак, Авыргазы, Дәүләкән, Кырмыскалы, Чишмә, Уфа районнары җирләреннән ага.

Дим – Агыйделнең сулъяк кушылдыгы. Фёдоровка районындагы Стәрлебаш-Фёдоровка калкулыгыннан башланып, Бишбүләк, Миякә, Әлшәй, Дәүләкән, Чишмә, Уфа районнары җирләреннән ага.

Ак Идел (Агыйдел) – Чулман елгасының сул кушылдыгы. Ул хәзерге Учалы районына караган Яңа Хөсәен авылыннан дүрт километр ераклыктагы Әвәләк сыртының көньяк итәгеннән башланып, Учалы, Белорет, Бөрҗән, Мәләвез, Күгәрчен, Куергазы, Стәрлетамак, Ишембай, Гафури, Авыргазы, Кырмыскалы, Архангел, Иглин, Уфа, Благовещен, Бөре, Дүртөйле, Борай, Илеш, Краснокама районнары җирләреннән ага.

Әчтерхан – хәзерге Әстерхан өлкәсенең башкаласы. Идел елгасының ике як ярына, дельтасының югары өлешенә урнашкан. Аның хакында беренче хәбәрләр 13 нче йөзгә карый. 1459–1556 елларда Әстерхан ханлыгының төп шәһәре була. «...Гаҗәп зур бер диңгез...» дигәндә Каспий диңгезе күз алдында тотыла, әлбәттә.

Шулай итеп, татар халкының этнографиясен чагылдырган, баланың атка карата булган тирән ярату хисләре белән сугарылган мөнәсәбәте тасвирланган, әмма тетрәндергеч драматизм белән тәмамланган «Алмачуар» эзләреннән йөреп, әнә шундый кызыклы һәм гыйбрәтле мәгълүмат тупладым. Димәк, Г.Ибраһимов иҗатын өйрәнү юнәлешендә киләчәктә тагын да яңалыклар табылачагына ышанасы килә.

Рәмил ИСЛАМОВ,
филология фәннәре докторы.

Айга кырын карама

Халык медицинасы чаралары белән дәвалануга керешкәнче, табиб белән киңәшү зарур!

27 август (шимбә). ***Мөхәррәм аеның 29 нчы көне. 30 нчы, 1 нче Ай тәүлекләре. Ай Кыз йолдызлыгында, 4.00 сәгатьтә калка, 19.24 сәгатьтә бата. 11 сәгать 17 минуттан яңа Ай. Көн озынлыгы 14.13 сәгать.***

Тәүбә итү, гармониягә ирешү көне. Иҗат белән шөгыльләнү, айлык план төзү яхшы. Әйләнә-тирәне дә, үз хисләреңне дә кабул итү кискенләшә, тәэсирләнүчәнлек, интуиция арта. Баш һәм йөрәк зәгыйфь. Арып-талганчы эшләргә, артык кайнар ризык ашарга ярамый. Төрле исләргә аллергия килеп чыгарга мөмкин.

Тахикардия

Тахикардия – йөрәкнең минутына 100 тапкырдан да артыграк тибүе ул. Йөрәк тибешен җайлау өчен, кипкән дүләнә, миләш, балан җиләкләрен, йөзем һәм күрәгәне тигез микъдарда кушып, шуның 1 стаканын термоска салалар, өстенә 1 литр кайнар су коялар, төнгелеккә калдыралар да, икенче көнне чәй урынына эчеп бетерәләр. Яисә 1 аш кашыгы киптереп төелгән шайтан таягы яфрагын 1 стакан кайнар суда, өстен томалап, 4 сәгать төнәтәләр, сөзеп, көненә 2-3 тапкыр яртышар стакан эчәләр. Дәва курсы – 4 атна. Яки 1 чәй кашыгы төелгән һиндыба тамырын 1 стакан суда 5-10 минут кайнаталар, 1 сәгать төнәтәләр дә, сөзеп, көненә 3 тапкыр, ашар алдыннан, яртышар стакан эчәләр. Бал яки шикәр кушып эчәргә дә мөмкин. Дәва курсы – 3-6 атна.

28 август (якшәмбе). ***Сәфәр аеның 1 нче көне. 2 нче Ай тәүлеге. Ай Кыз йолдызлыгында, 5.20 сәгатьтә калка, 19.32 сәгатьтә бата. 1 нче фаза. Көн озынлыгы 14.09 сәгать.***

Яңа туган Ай Җир белән Кояш арасында, үзенең караңгы ягы белән Җиргә караган. Ай идарә итә торган һәрнәрсә – хисләр, кәеф, хәтер, кан басымы зәгыйфь. Кан басымы болай да түбән булган гипотониклар өчен бигрәк тә авыр вакыт. Бу чорда укуда уңышлар, тиз савыгу, югары эшчәнлеккә өметләнергә ярамый. Ашаганда талымлы булу хәерле. Аралашуны чикләү зарур.

29 август (дүшәмбе). ***Сәфәр аеның 2 нче көне. 3 нче Ай тәүлеге. Ай Үлчәү йолдызлыгында, 6.40 сәгатьтә калка, 19.39 сәгатьтә бата. 1 нче фаза. Көн озынлыгы 14.04 сәгать.***

Бик актив көн, хәвеф-хәтәр инстинкты, агрессия белән бәйле. Бүген чирләп китү ихтыяр көченең җитәрлек булмавын күрсәтә. Күзне арытмаска кирәк.

Псориаздан - каланхоэ

Псориаздан котылу өчен, 10 ар грамм бал һәм эвкалипт мае, 30 грамм каланхоэ согын кушалар да, 2 көн төнәтәләр. Аннары шул катнашманы тиренең зарарланган урыннарына сөртәләр. Витилигодан исә мондый катнашма белән дәваланып була: 1әр аш кашыгы сары мәтрүшкә үләне һәм көнбагыш мае, 3 аш кашыгы зәйтүн маен кушып, 1 ай төнәткәч, сөзәләр, тирегә сөртәләр.

30 август (сишәмбе). ***Сәфәр аеның 3 нче көне. 4 нче Ай тәүлеге. Ай Үлчәү йолдызлыгында, 8.01 сәгатьтә калка, 19.47 сәгатьтә бата. 1 нче фаза. Көн озынлыгы 14.00 сәгать.***

(Дәвамы 18 нче биттә).

Айга кырын карама

Авыр энергетикалы көн. Теләсә нинди элемтә, танышулар, күмәк эш бүген кыен кичерелә. Озаграк йоклау хәерле. Тәмлерәк һәм күбрәк ашау теләге зур булса да, чаманы югалтмаска кирәк. Ач торырга ярамый.

Горчица сызлауны баса

Баш авыртканда, буыннар сызлаганда, ярты уч горчица порошогын 50 градуслы суда эретәләр дә, зәһәр ис чыга башлагач, ваннадагы 38-38,5 градуслы суга кушалар, шунда кереп, 5-10 минут яталар да, соңыннан яхшылап душта коеналар.

31 август (чәршәмбе). ***Сәфәр аеның 4 нче көне. 5 нче Ай тәүлеге. Ай Чаян йолдызлыгында, 9.23 сәгатьтә калка, 19.55 сәгатьтә бата. 1 нче фаза. Көн озынлыгы 13.55 сәгать.***

Бүген юлда булу әйбәт. Ач тору тыела. Күңел нәрсә тели, күпме тели – шулкадәр ашарга була, бигрәк тә яшелчә файдалы. Башлаган эшне ахырына житкезү зарур. Ашказаны-эчәк авырулары кискенләшү тискәре энергиянең артык күп тупланууын күрсәтә. Кан әйләнеше системасы, ияк, муен, бронхлар зәгыйфь.

1 сентябрь (пәнҗешәмбе). ***Сәфәр аеның 5 нче көне. 6 нчы Ай тәүлеге. Ай Чаян йолдызлыгында, 10.49 сәгатьтә калка, 20.05 сәгатьтә бата. 1 нче фаза. Көн озынлыгы 13.51 сәгать.***

Хисчәнлек арта. Һәртөрле аралашу күңелгә ятышлы. Бу көннәрдә әти-әнигә ихтирам көче аеруча куәтләнә, гаиләдә бергә җыелып, балачакның күңелле хатирәләрен яңарту яшәү көче өсти. Бизләр системасы, җилкә, кул,үпкә, бронхлар зәгыйфь, салкын тию ихтималы зур.

Аяк-куллар сызлаганда

Артрит, артроз җәфалаганда, болай дәваланалар. Термоска 2 шәр аш кашыгы каен һәм гөлҗимеш яфрагы, каз үләне (спорыш) салып, өстенә 1 стакан кайнап торган су коялар, 1 тәүлек төнәткәч, сөзәләр, 2 аш кашыгы тоз кушалар. Юылган сарык йонын (яки иске оекбашны) шул төнәтмәдә чылатып, сыкмыйча киптерәләр. Авырткан буынга куеп, өстеннән бинт урыйлар, бәйләвечне тәүлегенә 1-2 тапкыр алыштыралар. Хроник ревматизм булганда, буын сызлаганда, киҗе-мамык тукымадан кечкенә капчыклар тегеп, аларга каен яфрагы тутыралар, шуларны буынга 1-2 сәгатькә бәйләп куялар. Дәва курсы – 2 ай.

2 сентябрь (җомга). ***Сәфәр аеның 6 нчы көне. 7 нче Ай тәүлеге. Ай Чаян йолдызлыгында, 12.19 сәгатьтә калка, 20.19 сәгатьтә бата. 1 нче фаза. Көн озынлыгы 13.46 сәгать.***

Һава энергиясенә бәйле көн. Тынгысызланырга, гайбәт сөйләргә ярамый. Ялгыз калып уйлану файдалы. Нерв системасы, үпкә зәгыйфь. Ач тору, ашказаны һәм эчәклекне чистарту уңай нәтиҗә бирә.

Чүпрәле ипи

650 г җылымса су, 1 әр аш кашыгы коры чүпрә һәм тоз, арыш һәм бодай оннары кирәк. Кичтән җылымса суга чүпрә, иләнгән арыш оны салып, коймак камырыннан сыеграк итеп изеп, җылы урынга әчергә куялар. Иртән тоз, яңа гына иләнгән бодай оны кушып, камыр басалар, җылы табага салып, кабарталар, аннары газ мичендә 1 сәгать чамасы пешерәләр.

Тәкъвалыкның мәгънәсе һәм файдасы

Ислам динендә «тәкъва» дигән сүз Аллаһы Тәгаләнең газабыннан саклану мәгънәсен аңлата. Кеше Аллаһның барлыгына һәм берлегенә ышанганнан соң, Аның газабыннан саклый торган гамәлләр кылырга ягъни тәкъва булырга тиеш. Кеше Аллаһы кушкан гамәлләрне эшләп һәм харам кылган гамәлләрдән тыелып яшәсә, тәкъва була. Аллаһы Тәгалә Коръәндә адәм балаларына һәр эштә дә тәкъва булырга куша:

«Әй иман китергән кешеләр! Аллаһының газабыннан чын саклану белән саклагыз (ягъни тәкъва булыгыз)!» («Әли Гыймран», 102)

Ибн Мәсгуд радыйаллаһу ганһе исемле сәхәбә бу аятьне түбәндәгечә аңлата:«Аллаһының газабыннан саклану (тәкъва булу) – ул Аллаһыга буйсыну һәм аның әмеренә каршы килмәү, Аны һәрвакыт истә тоту һәм онытмау, Аңа шөкер итү һәм Аның нигъмәтләрен инкяр итмәү».

Аллаһы Тәгалә адәм баласының матурлыгына, байлыгына һәм дәрәҗәсенә игътибар итми. Аның каршында иң хөрмәтле һәм дәрәҗәле кеше – ул тәкъва кеше. Аллаһы Тәгалә әйтә: «Аллаһы каршында сезнең иң хөрмәтлегез – иң тәкъва булучыгыз» («Хуҗурат», 13).

Кешенең Аллаһы газабыннан саклануы, ягъни тәкъва булуы түбәндәге нәрсәләрдә күренә:

1. Аллаһы кушкан гамәлләрне үтәүдә. Ул биш вакыт намаз укый, Рамазан аенда ураза тота, байлыгы булса, зәкәт түли, әти-әнисенә, хатынына, балаларына карата игелек кыла һәм алар белән яхшы мөнәсәбәттә була.

2.Аның сөйләмендә. Тәкъва кеше үзенең телен сүгенүдән, ялганнан, гайбәттән, кешеләрне кимсетү, мыскыл итүдән һәм файдасыз буш сүз сөйләүдән саклый. Аның теле яки файдалы сүз сөйли, яки дәшми тора.

3.Аның ашаган ризыгында. Тәкъва кеше бары тик хәләл ризык кына ашый, хәләл эчемлекләр генә эчә. Аның карынына шикле, хәрам ризыклар керми.

4.Аның карашында. Тәкъва кеше урамдагы, телевизордагы һәм газета-журналлардагы ярым шәрә хатын-кызларга карамый. Әгәр дә күрсә, карашын алардан читләштерә.

5.Аның кулында. Тәкъва кеше башкаларга сукмый, гөнаһлы нәрсәләргә кулын сузмый, ә бары тик рөхсәт ителгән, файдалы һәм саваплы гамәлләрне генә кыла.

6.Аның күңелендә. Тәкъва кеше башкаларга карата көнчелек, тәкәбберлек, ачу-нәфрәт хисе сакламый һәм аларның кайгы- хәсрәтләренә дә шатланмый.

7.Аның ниятендә. Тәкъва кешенең нияте һәрвакыт ихласлыкка корылган. Ул бер эшне дә мактасыннар яки җәмгыятьтә берәр дәрәҗә ялау өчен эшләми. Һәр гамәлендә Аллаһы ризалыгын вә Аның җәннәтен өмет итеп эшли.

Әгәр кеше шушы сыйфатларга ия булса, ул Аллаһының газабыннан саклаучы – тәкъва кеше булып санала. Аллаһы Тәгалә андый кешегә түбәндәге рәхмәтен вә нигъмәтен күрсәтә:

1. Аллаһы Тәгалә ул кешене ярата башлый. Коръәндә болай диелә: «Кем дә кем Аллаһы Тәгалә белән төзегән килешүне тулысынча үтәсә, Аның газабыннан сакланса, дөреслектә, Аллаһы тәкъва кешеләрне ярата» («Әли Гыймран», 76).

2. Тәкъва кешегә Аллаһы Тәгалә рәхимле була. Аллаһы Тәгалә әйтә: «Һәм бу Без индергән бәрәкәтле китап (Коръән). Аңа иярегез һәм тәкъва булыгыз. Бәлки сезгә Аллаһы рәхимле булыр» («Әнгам», 155).

Аллаһы Тәгаләнең кешеләргә рәхимлелеге бик күп әйберләрне үз эченә ала. Моңа матди нәрсәләр дә һәм мәгънәви нәрсәләр дә керә. Мәсәлән, тормышның һәм күңелнең тыныч,балаларның тәрбияле булуы, кешенең авырулардан, кайгылардан имин булып яшәве, яхшы эштә эшләве, Кыямәт көнендә җәннәткә керүе – болар бөтенесе дә Аллаһының рәхмәтен вә рәхимлелеген күрсәтә.

3. Аллаһы Тәгалә тәкъва кешегә хаклык һәм ялганны аера белү сыйфатын бирә. Аллаһы Тәгалә әйтә: «Әй иман китергән кешеләр! Әгәр дә сез Аллаһының газабыннан саклансагыз, Ул сезгә аера торган сыйфат – «фуркан» бирәчәк һәм гөнаһларыгызны гафу итәчәк һәм ярлыкаячак. Аллаһы олуг нигъмәт Иясе» («Әнфәл», 29).

Гарәп телендә «фуркан» дигән сүз хаклык һәм ялганны, хәләл һәм хәрамны аера торган сыйфатны аңлата. Әгәр дә кеше тәкъва булса, тормыштагы сынаулар алдында югалып калмаячак. Аллаһы Тәгалә аңа һәрвакыт яхшылык һәм начарлыкны, ялган һәм дөреслекне аерырга ярдәм итәчәк.

4. Аллаһы Тәгалә тәкъва кешегә бәрәкәт бирә. Аллаһы Тәгалә шулай ди: «Әгәр дә авыл (шәһәр) кешеләре иман китереп тәкъва булсалар, Без аларга күктән һәм җирдән бәрәкәт ишекләрен ачар идек» («Әгъраф», 96).

Аллаһы Тәгалә тәкъва кешеләргә бөтен яктан да Үзенең нигъмәтләрен бирәчәк. Күктән бәрәкәт ишекләренең ачылуы яңгырны, ә җирдән бәрәкәт ишекләренең ачылуы уңыш, җиләк-җимеш бирүче төрле үсемлекләрне аңлата. Тәкъва булганнары өчен Аллаһы Тәгалә аларны фәкыйрьлектән, ачлыктан һәм корылыктан саклый.

5.Аллаһы тәкъва кешегә һәр авырлыктан да чыгу юлын күрсәтә һәм һәр эшен җиңел кыла:

«Кем дә кем Аллаһының газабыннан сакланса, Аллаһы аңа авырлыктан чыгу юлын күрсәтә» («Талак», 2).

«Кем дә кем Аллаһының газабыннан сакланса, Аллаһы аңа эшендә җиңеллек бирә» («Талак», 4).

Вакыт-вакыт кеше чишеп булмаслык авыр хәлләргә очрарга мөмкин. Менә шул вакытта Аллаһы Тәгалә аның тәкъвамы,түгелме икәнлегенә караячак.Әгәр дә тәкъва булса, Аллаһы Тәгалә аңа авыр хәлдән чыгарга ярдәм итә.

6. Тәкъва кеше җәһәннәм өстендәге сират күперен җиңеллек белән үтәчәк. Аллаһы Тәгалә әйтә: «Сезнең бөтенегез дә җәһәннәмнән узачак. Бу синең Раббыңның катгый карары булды. Соңыннан тәкъва кешеләрне Без коткарачакбыз, ә гаделсезлек кылучы кешеләрне (имансызларны һәм гөнаһлыларны) анда тезләнгән хәлләрендә калдырачакбыз» («Мәрьям», 71-72).

8. Тәкъва кешеләр җәннәткә керәчәк. Аллаһы Тәгалә шулай ди: «Дөреслектә, тәкъва кешеләр имин урында, җәннәт бакчаларында һәм чишмәләрдә булачак» («Духан», 51-52).

Аллаһы Тәгалә барчабызга да тәкъвалыкка ирешергә һәм бу дөньяда да, ахирәттә дә бәхетле тормышта яшәргә насыйп итсен!

Өч сәбәп

Иман ул – Аллаһка ышану хисе. Ислам галимнәре белдерүенчә, Аллаһка ышаныр өчен, һәр кешегә түбәндәге өч нәрсә төп сәбәп булып тора.

Һәр кешегә тумыштан бирелә торган Аллаһны тою хисе (фитрый иман).

Бала ана карынында формалаша. Тәне җыелып беткәннән соң, көннәрдән бер көнне яралгы «терелә», хәрәкәтләнә башлый. Халык телендә бу вакыйга турында «җан керде» дип әйтәләр. Ә кайдан килгән соң ул җан? Галимнәр аңлатуынча, ул ахирәттән җибәрелә.

Аллаһы әмере буенча фәрештәләр аны ана карынындагы яралгыга өреп кертә... Шулай итеп, җан ахирәт тормышын күргәнгә, белгәнгә күрә, шушы ахирәт тормышына әйләнеп кайтасын да белә. Менә бу – фитрый иман була да инде.

Һәрбер бала бу дөньяга мөселман булып туа. Бу дөнья тормышында мөселманлык Аллаһ билгеләгән кануннарга буйсынырга тиеш булуда да чагыла. Физиологик мәгънәдә һәрбер кеше – мөселман (Аллаһ билгеләгән кануннарга буйсынучы), әмма рухи мәгънәдә ата-аналар балаларын үзләренчә тәрбияли. Шуңа карамастан, фитрый иман кеше күңелендә гомерлеккә саклана һәм бердәнбер илаһи Зат – бөек Аллаһы Тәгалә барлыгына ышанырга этәреп тора.

Кешенең үз-үзен барлыкка китерүе мөмкин булмавы.

Коръәндә билгеләп үтелгәнчә, кеше хәтта чебенне дә бар итә алмый. Ә кеше хәтле кешене – аның катлаулы баш миен, нерв системасын, ризык эшкәртү, кан йөрү системаларын h.б. – бигрәк тә. Кешене бар итү, шулай итеп, Аллаһтан башка беркемнең дә кулыннан килми. Әлеге факт бөек илаһи Зат – Аллаһы Тәгалә барлыгына ышануга икенче зур сәбәп булып тора.

Галәм төзелешендәге тәртип.

Галәм – билгеле бер тәртипкә китерелгән төп-төгәл механизм. Әлеге тәртип үзеннән-үзе (очраклы рәвештә) берничек тә урнаша алмый, ә кешенең галәмдә тәртип урнаштырырга көче җитми.

Дәүләтле Надир Дәүләт

(Гүзин Берил Дәүләтнең 2022 елда Татарстан китап нәшриятында чыккан «Бер гомеренә алты тормыш сыйдырган Надир Дәүләтнең язмышы» исемле китабы турында.)

Төркиядә яшәүче татар профессоры Надир бәй белән беренче тапкыр 1990 елда Түбән Камада очраштык. Ул Америка профессоры Рифат Таби белән шул якларга килеп чыккан иде. Җитди оешмаларның җитди чикләүләре булган заманда Разил Вәли аларны ничек итеп туган ягына алып кайткандыр?.. Ике олы илнең ике олы профессоры бик шаян-шат күңелле кешеләр булып чыкты. Әллә алар Төркия белән АКШта сирәк күләме, әллә ул илләрдә Разил Вәли кебек мәзәк сөйләүчеләргә кытлыкмы, белмим, әмма бу ике ир-егетнең иркенләп көлүләре бөтен мәҗлескә йога: табын янындагылар кайгысыз күңел ача. Мин дә аларга сокланып багам. Горбәттә (чит-ят җирләрдә) дә саф килеш сакланган Ана телебезне тыңлап ләззәтләнәм. Аларның сөйләмендә бер генә чит-ят сүз дә ишетелми. Телләре тәмле, бай һәм тирән мәгънәгә ия, дип сокланам. Без бу ике дус белән Төркиядә дә, Америкада да берничә тапкыр күрештек. Алар һаман шулай көр күңелле булып кала бирә, шөкер.

Ләкин Надир бәй, көлүдән туктаган арада, кинәт җитдиләнә, аның аксыл йөзендә, күз карашында моңсулык пәйда була. Аның куллары, үзе дә сизмәстән, тәмәкегә үрелә, Надир бәй бик еш тарта. Миңа ул башта бераз чирләп торадыр сыман тоелган иде. Әмма еллар аша яңадан-яңа күрешүләрдә дә аны шушы ук халәттә күргәч, башыма уй йөгерде, Надир Дәүләтнең күңеле беркайчан да бетми торган сагыш белән тулган. Ул үзе сау-сәламәт, ләкин кара язмыш аның йөрәк тибешенә җирсү хисләре салган. Моның шулай икәнен Надир бәй Дәүләтнең тормышын якыннан белгәч кенә аңлап була. Аның узган юлы – трагик поэма, кызганыч сюжетлы фильм, еламыйча укып булмый торган кыйсса булып сузылган. Һәм ул китап язылыр, шәт!

Коммунизм аждаһасыннан качып, Кытай Маньчжуриясенә барып, тыныч куыш тапкан татар зыялысы Ибраһим Дәүләт-Килденең бәхетле гаиләсендә 1944 елда Надир исемле ир бала дөньяга килә. Бер яше тулар-тулмас вакытта Совет гаскәрләре Маньчжуриягә бәреп керә, атасы Ибраһим абзый белән анасы Рокыя ханымны кулга алалар, Себергә алып китеп, зинданга ябалар. Бер яшьлек сабыйны бер яһүд кешесе качырып алып кала да ятим Надирны миһербанлы Әхтәм абзый Ильясов белән Гайниҗамал ханымга китереп бирә, болары ятимне уллыкка ала (Әхтәм абзыйның чыгышы Актаныштан, Гайниҗамал Пенза якларыннан була). Надир үзенең ата-анасын күрми-белми үсә. Әхтәм абзый белән Гайниҗамал

● Надир әфәнде җәмәгате Гүзин Берил ханым белән.

Надир үсеп балигъ булгач кына серне ачарга тиеш була. Шулай итеп, Надир үзенең Ильясов түгеллеген, бәлки морза токымлы Дәүләт-Килде атлы икәнен белә. Ул бу хәбәрне башка кешеләр авызыннан ишетә. Үз балалары итеп, сөеп үстергән, аңа белем биргән кешеләрнең үзенең ата-анаң түгел икәнлеге Надирны бер тетрәндерсә, аларга сокланулы, рәхмәтле итсә, икенче яктан үз атасының совет зинданында җәзалап үтерелүе һәм анасы йөкле килеш кулга алынып, озак еллар совет сөргенендә җәберләнүе, төрмәдә туган сабый кызын кулыннан тартып алып, ятимнәр йортына тапшырылганын ишеткәч, Надир бәй икенче тетрәнү кичерә. Гаепсезгә җәзаланганнар, аларны җәзалаучылар турында уйлый-уйлый, зинданнан исән чыккан анасы, сеңлесе белән очраша алмаулары турында уйлый-уйлый, Надир Дәүләтнең күңелендә ризасызлык, кемгәдер нәфрәт юкныны урнаша, йөзенә сары сагыш булып сирпелә.

Алар очрашты. Абый белән сеңел (Фәридә) ниһаять, олыгаеп барганда Казанда очрашты. Бу очрашуны ничек сурәтләргә? Язып булмый, аңлатып булмый мондый халәтне. Бер ата, бер ана балалары булса да, икесе ике мохиттә тәрбия алган, берсе татарча да, инглизчә дә, төрекчә дә белми торган, йолаларсыз үскән, кияүгә чыкмаган хатын, икенчесе – дөньяның иң бай телләрен, ана телен мөкәммәл белгән профессор. Алар икесе ике милләт кешеләре кебек. Аларның сөйләшергә уртак теле юк. Күз карашлары тулы сагыш, ни өчендер, кемгәдер, адресы булмаган рәнҗеш мохитендә утыруы башка кешегә дә читен иде. Бичара хатын туганда ук хокуксыз булып туган икән, картаеп барганда да уртача гына булса да фатир алалмаган, боек, сагышлы, ятакханәдә кара ятим булып яшәп ятучы япа-ялгыз ханымга карап, абыйсы Надирның бәгыре киселмәгәндер, дип кем әйтә ала? Телгәләнгән бәгырьнең әчесе Надирның йөзенә язылган!

– Алар түгел, мин үксеп еладым, – диде Разил, абыйлы-сеңелле туганнарның беренче очрашуыннан соң.

... Яхшы ата, яхшы аналарның
Ямь түгел баласы идек.
Ямьлекнең күзенә баса-баса
Тантанага барасы идек.
Кемгә тидек?
Кемне рәнҗеттек соң?
Кем соң безне шулай каргады?
Сак белән Сок кебек моңаябыз,
Арабызда – Урал таулары...

(Хәсән Туфан).

Казанга килгән саен Надир бәй сеңлесе янында була. Ташламый ул аны. Тел бер булмаса да, кан бер. Халык депутаты, шагыйрь Разил Вәли белән икесе йөри-йөри, Надир Дәүләтнең сеңлесенә бер бүлмәле фатир алып бирүгә ирештеләр. Төркиягә барган кешеләр артыннан Надир һәрвакыт сеңлесенә күчтәнәч җибәрә. Мәрхүм ата-ананың рухы разыйдыр, мөгаен. Ике бертуган, ниһаять, очрашты, бер-берсен тапты, алар бер-берсенә ярдәмле, дип сөенә торганнардыр.

Үги эти-әнисе Надирга яхшы тәрбия, югары белем биреп, кеше итте. Инде алар да гүр иясе булды. Урыннары җәннәттә булсын. Надир Кытайда, Төркиядә, Алманиядә, Америкада алган белемен татар халкына хезмәт итүдә файдалана. Ул язган фәнни-гыйльми китапларның барысы да, дип әйтерлек татар халкына, аның тарихына, әдәбиятына, атаклы шәхесләренә багышланган. Надир бәйнең төрек, инглиз, татар һәм рус телләрендә басылган йөз иллеләп мәкаләсе һәм бернича китабы шулар хисабыннан.

Rusya Turklerinin Milli Mucedele Tarihi. (Русия төрекләренең милли көрәш тарихы), Ankara, 1985.

Ismail Bey Gaspirali. Ankara, 1988.

Cagdas Turk dunyasi. (Замандаш төркиләр дөньясы) Istanbul, 1989.

Хәзерге чор төркиләренең халыкара әлифба симпозиумы. Истанбул, 1989.

Чагдаш (замандаш) төркиләр. Истанбул, 1993.

Исмәгыйль бәй Гаспралы. Икенче басма, Казан, 1996.

Идел-Урал экспедициясе: Татарлар-Башкортлар-Чуашлар. Анкара,1997.

Русия төрекләренең милли мөҗәдәлә тарихы. Икенче басма, Анкара, 1998.

Ефәк юлы экспедициясе альбомы. Анкара, 1997.

1917 ел революциясе һәм Төрек-Татар Милләт Мәҗлесе. Анкара.

Әле күптән түгел генә Казанда «Милли китап» нәшриятында басылып чыккан «Русия төркиләренең милли көрәш тарихы (1905-1917)» дигән китап – Н.Дәүләтнең иң әһәмиятле хезмәтләренең берсе. Бу китап Төркиядә 1985, 1998 елларда ике тапкыр төрекчә басылып чыккан иде. Ниһаять, ул ана телебездә дә пәйда булды. Хөрмәтле профессорыбыз «Бу хезмәтне Төркия белән Татарстан арасында фәнни һәм мәдәни күпернең салынуына бик зур өлеш керткән, шушы юнәлештәге эшчәнлегемдә миңа һәрдаим ярдәм кулын сузган, татарларның чын мәгънәсендә горурлана алырлык күренекле шәхесе Разил әфәнде Вәлиевкә» багышлый.

Халкыбызның шушы чордагы көрәше турында аз язылмаган. Татар галимнәре бу чорны яхшы белә. Әмма Н.Дәүләтнең ошбу китабы шушы мәүзугъка багышлап, ватаныбызда чыгарылган хезмәтләрдән аерыла. Татарстан галимнәре нигездә ике телле архив материаллары белән генә эш йөртә ала: урысча һәм татарча. Татар галимнәре каршындагы икенче бер кыенлык, моңа кадәр татарларга чит илләрдәге материаллар белән танышу шактый чикләнгән иде. Өченчедән, галимнәребез гасыр башыннан алып унҗиденче елларга чаклы булган көрәшне таррак мәйданда, татар мәйданында гына тикшерәләр иде шикелле.

Шулай итеп, Н.Дәүләтнең татар телендәге бу китабы өч ягы белән отышлы һәм әһәмиятле. Н.Дәүләт милли азатлык өчен көрәш тарихын бер татарларга гына кайтарып калдырмый, бәлки Россиядәге бөтен төрки халыклар турында да яза: әзәриләр, Кырым татарлары, казахлар, үзбәкләр, башкортларның да милли азатлык өчен көрәшкә керткән өлешләре турында әһәмиятле материаллар бирә. Н.Дәүләт Татарстан, Мәскәү архивларыннан тыш, Төркия, Алмания һ.б. илләрдәге архивлар белән дә эш итә, һәр материалны ул оригинал текстта тикшерә, нәтиҗә ясый. Шуңа күрә, аның бу олуг хезмәте өстәмә материалларга бик бай.

Хөрмәтле галим, профессор, Төркиянең Мәрмәрә университетының җитәкчесе Н.Дәүләт үзенең чын ватаны, чын дәүләте дип Татарстанны саный. Ул Татарстанда татар халкының тарихы-әдәбиятына бәйле җыеннарда бик теләп катнаша, әйтергә кирәк, бу җыеннарда аның чыгышларын тын алмыйча, йотлыгып тыңлыйлар, чөнки Надир бәй буш сүз сөйләми, җитди мәсьәләләр күтәрә, милли хәрәкәттәге, тарих гыйлемендәге тайпылышлар аңа читтән яхшырак күренә булса кирәк.

Аның күп санлы мәкаләләре татар матбугатында басыла килә, менә, ниһаять, аның «Русия төркиләренең милли көрәш тарихы (1905-1917)» дигән олуг хезмәте дә дөнья күрде, без Н.Дәүләтне ватандашыбыз, үз галимебез дип хисаплыйбыз һәм ватан алдында, халкыбыз алдында күрсәткән хезмәтләренә күрә Татарстан хөкүмәтенең олы бүләкләренә лаек, дип саныйбыз.

Татарның олуг әдипләре Аяз Гыйләҗевнең тол калган хатыны Нәкыя ханым, Нурихан Фәттахның хатыны Руфинә ханым мәрхүм ирләренең архив материалларын күз карасы кебек саклап, аларга аңлатмалар язып, бастыра килә. Мәрхүм әдипләрнең бер җөмләсе дә югалмый, шөкер.

Тол калган шундый хатыннарның берсе – Гүзин Берил Дәүләт ханымдыр! Надир әфәнде вафатыннан соң ул үзенең хатирәләрен, башкаларның Надир әфәнде турындагы фикерләрен бергә туплап, бастырып чыгарды. Аның бу әсәрен Төркиядә яшәүче Рушания Алтай татарчага тәрҗемә итте һәм ул Татарстан китап нәшриятында басылып та чыкты.

Рабит БАТУЛЛА.

Ачуланма!

АКШтагы Айова университеты галимнәре 40 ел буе 1307 ир-атның сәламәтлеген күзәткән. Сынау башланганда, аларга 30-40 яшь булган. Тикшеренү барышында ирләр әледән-әле махсус сорауларга җавап биргән һәм үзләренең ачуы чыгу дәрәҗәсен махсус шкала буенча бәяләгән. Еш ярсыган ирләрнең күбесе 70 яшь тулганчы ук үлеп китә, ә тыныч холыклылары озаграк яши икән. Сынау җитәкчесе Грем Прайс әйтүенчә, яшьтәшләреннән иртәрәк бакыйлыкка күчкән ирләрнең ачу дәрәҗәсе басынкы холыклыларныкыннан 1,6 тапкырга югарырак булу ачыкланган. Галимнәр усал ирләрнең сабыр яшьтәшләреннән иртәрәк үлү сәбәпләрен ачыклау максатын куймаган, әмма тикшеренү ачуның сәламәтлеккә тискәре йогынты ясавын дәлилләгән. Күп ачуланган кеше инсульт һәм инфаркттан, колиттан ешрак интегә икән.

(“Медновости.ру”).

Сәламләшү нечкәлекләре

Дөньяда иң киң таралган сәламләшү ысулы – кул кысышу. Ул бик борынгыдан килә. Гасырлар буена исә исәнләшү этикеты эшләнгән. Мәсәлән, төрле яшьтәге кешеләр сәламләшкәндә, өлкәнрәге кулын беренче булып суза. Яшьрәге исә, икеләнеп тормыйча, шул мизгелдә үк аның кулын кысарга тиеш. Утырган килеш кул бирергә дә, перчатка кигән килеш исәнләшергә дә ярамый. Кул кысышу шактый нык булып, 2-3 секундтан артмаска тиеш. Россиядә бусага аша кул бирешмиләр. Сәламләшүнең иң сәер традицияләре Африка кыйтгасында очрый. Мәсәлән, Кениядәге акамба кабиләсе вәкилләре очрашканда бер-берсенә төкерә. Мозамбикның Замбезия провинциясендә, чүгәләп, кул чабалар. Конгода бер-берсенә кулларын сузалар һәм аларга өрәләр. Сахара чүле чигендәге кабиләләрдә исә сәламләшү ритуалы 100 метр ара калгач ук башлана. Аборигеннар башта баскан җирендә катып кала, аннары сикерә, чүгәли, бии. Мисырда учны маңгайга куеп исәнләшәләр. Гарәпләр күкрәк турысында кулларын чалыштыра. Лапландиядә борыннарын тидереп сәламләшәләр. Латин Америкасында кочаклашалар. Японнар һәм кытайлар баш иеп сәламләшә. Тибетта башта уң кул белән баш киемен салалар, аннары сул кулны колак артына куеп, телләрен чыгаралар. Төньяк Африкада, иелеп, кулны маңгайга, иренгә һәм күкрәккә тидерәләр, бу: “Мин синең турында уйлыйм, синең турында сөйлим, сине хөрмәт итәм”, – дигәнне аңлата. Һиндстанда, кулларны кушырып, күкрәк турысына куялар. Самоада бер-берсен исниләр. Франциядә исә символик үбешеп – башта 2 тапкыр уң яктагы, аннары 2 тапкыр сул яктагы яңакны тидерешеп сәламләшәләр.

(“Мир новостей”).

Мүкәләү даруны алыштыра

Иртәләрен Кытай паркларында дүрт аякланып йөрүче йөзләгән кешене очратып була. Читтән карап торучыга бик сәер тоелса да, аларның моңа бер дә исе китми, чөнки шулай дәваланалар – югары кан басымыннан, арка һәм муендагы авыртудан котылалар. Мондый дәва чарасы Борынгы Кытайда Хань династиясе вакытында (безнең эраның II гасыры) ук кулланылган. Борынгы табибләр, умырткалыктагы киеренкелекне киметү өчен, хайван хәрәкәтләрен кабатларга куша торган булган. Хәзерге табибләр дә мүкәләп йөрүгә каршы түгел, алар мондый күнегү кан әйләнешен яхшырта, радикулиттан һәм баш авыртудан булыша, дип саный. Кризис вакытында мондый дәва чарасы даруга дигән акчаны да янга калдыра.

(“China News”).

● **Дэвид Флакер Уэссекс графинясы Софи белән.**

Йөз яшьлек волонтер

Шотландиянең Эдинбург шәһәрендә яшәүче Дэвид Флакерга быел җәй йөз яшь тулган. Икенче бөтендөнья сугышы вакытында ул авиациядә хезмәт иткән. Исән-сау әйләнеп кайткач, һөнәри белем алган һәм Австралиядә, аннан соң Көньяк Африка Республикасында типография хезмәткәре булып эшләгән. Соңрак Шотландия башкаласына күченеп, 72 яшенә кадәр нәшриятта эшләвен дәвам иткән. Зурлап лаеклы ялга озатканнар. Әмма Флакер эшсез өйдә утыра алмавын тиз арада аңлаган һәм чиркәү каршындагы хосписстагы хәйрия кибетенә волонтер булып урнашкан. Шуннан бирле хәзергә кадәр инде 28 ел буе атнасына өч көн эшли. Аның кибетендә – идеаль тәртип, ул хосписстагы кечкенә кибеткә түгел, зур сәүдә үзәгендәге модалы бутикка күбрәк охшаган.

(“Edinburgh Live”).

Умарта-робот

Израильдә заманча умарталыклар саны көннән-көн арта. Шломка Франкин 2018 елда эшләтеп җибәргән стартапта хәзер 100 хезмәткәр исәпләнә. Beehome дип аталган проект умарта-роботлар ясау белән шөгыльләнә. Мәйданы 12 квадрат метрлы роботлаштырылган бокстагы 24 умартаның һәркайсында икешәр миллион бал корты яши. Кояш энергиясендә эшли торган йөзгә якын шундый махсус бокс Израильнең үзендә куелган, ә бер дистәдән артыгы АКШка җибәрелгән. Ясалма интеллект умарта кортларын ашата, эчертә, дәвалый, кирәкле даими температураны саклый, корткычларны юк итә һәм хәтта бал да суырта. Шундый бал быел җәй сатуга чыгарылган инде. “Бал кортлары өчен бу гадәти умарта, ә менә бокс өчен җаваплы хезмәткәр ерактан торып андагы бөтен мәгълүматтан хәбәрдар”, - ди Beewise директоры Нетали Харари. Умарта кортларының юкка чыгу куркынычы турында дөньяда инде утыз еллап чаң сугалар. Әлеге файдалы бөҗәкләрнең күпләп үлеме сәбәпләре – авыл хуҗалыгында пестицидлар һәм башка химик продуктлар куллану, шулай ук Азиядәге тропик быжаннарның төньяк киңлекләргә үтеп керүе (биш шундый ерткыч бөҗәк тиз арада бер умартаны һәлак итә ала). Бал кортлары исә экосистемада гаять мөһим роль уйный, аларның үлеп бетүе серкәләндерүгә мохтаҗ үсемлекләрнең 80 процентының юкка чыгуына китерер иде. Нәкъ менә шуңа күрә Израильнең Beewise роботы тиз арада 76 миллион долларлык инвестицияләр җәлеп итә алган да инде.

(“The Jerusalem Post”).

Газета өчен Алсу ЗӘЙДУЛЛИНА әзерләде.

Дүшәмбе

29 август
«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

3.30 «Әдәби хәзинә». 6+
3.55 «Йөрәктән - йөрәккә». 6+
4.45 «Җырлыйк әле!» 6+
5.35, 14.45 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
5.50, 7.00, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00 «Беренче театр». 12+
10.00, 0.00 «ЛЮБОПЫТНАЯ ВАРВАРА 3». 12+
11.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 12+
11.30, 21.00 «Заман көзгесе». 6+
12.00, 23.10 «АЙ ТУЛГАНДА». 16+
13.00 «Семь дней». 12+
14.00 «Закон. Парламент. Общество». 12+
15.00 «Бердәм булыйк». 6+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә».
16.00 «Татарлар». 12+
16.30 Хоккей. «Ак Барс» - «Салават Юлаев». 6+
19.00, 20.00 «Таяну ноктасы». 16+
22.00 «Вызов 112». 16+
22.10 «Наша Республика - Наше дело». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

6.00, 13.00 «Манзара». 6+
8.00, 17.00, 21.25, 0.15 «РӘХӘТ ЯШИБЕЗ!» 12+
8.40, 23.05 «Башваткыч». 12+
9.50 «Семь дней». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30 «Заман көзгесе». 6+
12.05 «Йөрәктән - йөрәккә». Илһам Шакиров турында телеочерк. 6+
15.30 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 12+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
18.20, 22.20 «АЙ ТУЛГАНДА». 16+
19.10, 21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
20.00 «Таяну ноктасы». 16+

«ЭФИР»

1.00, 14.35 «Реки России». 12+
2.00, 3.00, 7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
8.30, 23.00 «СВОИ-2». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «УХОДЯЩАЯ НАТУРА». 16+
10.30, 21.00 «ЖЕНА ОФИЦЕРА». 12+
11.30, 17.10 «ПОСЛЕДНИЙ ЯНЫЧАР». 12+
12.30, 18.40 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.45 «ИСТИНА В ВИНЕ». 16+
15.00 «Это лечится». 12+
15.30 «Неизвестный COVID. Джокер в мире вирусов». 12+
16.25 «Сказочный патруль. Хроники чудес».
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 18.20, 23.45 Информационный канал. 16+
21.00 «Время».
21.45 «ЗОЛОТАЯ ОРДА». 16+
22.45 «Большая игра». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 Минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
21.20 «ЕЛИЗАВЕТА». 16+
22.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30, 16.50 «Царица Небесная. Феодоровская икона Божией Матери».
7.00 «Другие Романовы». «Всегда Великая княгиня».
7.30 Черные дыры. Белые пятна.
8.10 Легенды мирового кино.
8.45, 15.35 «ПРИКЛЮЧЕНИЯ ЭЛЕКТРОНИКА».
10.00, 15.00, 19.30, 23.40 Новости культуры.
10.15 «Абрам да Марья».
11.10 XX век. Вера Васильева, Валентин Плучек, Михаил Державин, Георгий Менглет, Юрий Авшаров в программе «История одного спектакля. Ревизор».
12.20, 20.30 Абсолютный слух.
13.05, 21.45 «БЕРЕГ ЕГО ЖИЗНИ».
14.15 «Гатчина. Свершилось».
15.05 «Эрмитаж».
17.20 Марафон «Звезды XXI века». Российский национальный оркестр. Валентин Урюпин, Павел Милюков.
18.15 Цвет времени. Анатолий Зверев.
18.35 «Женщины-викинги».
19.45 «Библейский сюжет».
20.15 «Спокойной ночи, малыши!»
21.15 «Запечатленное время».
22.55 «Война без грима».

«НТВ»

5.00 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.50 «Сегодня».
8.25, 10.35 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. ОСОБОЕ ЗАДАНИЕ». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
19.50 «КАНЦЕЛЯРСКАЯ КРЫСА». 16+
21.50 «РИКОШЕТ». 16+

Сишәмбе

30 август
«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
8.00, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00 «Ничек сезнең хәлләрегез?» 6+
11.00, 19.00, 20.00, 21.00 «Туган көнең белән, Республикам! С Днем рождения, Республика!»
15.00 «Мой Татарстан». 12+
15.20 Опера «Кара пулат». 12+
17.00 «Каравай». «Татарстан - многоцветие культур». 6+
18.00 «Болгар радиосы» бәйрәм концерты.
22.00 Праздничный салют.
22.05 «Вехи истории». 6+
22.40 «ЦИРК». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00 «Манзара». 6+
8.00 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
8.40, 23.05 «Җырлыйк әле!» 6+
9.40 «Туган җир». 12+
10.30 «Халкым минем». 12+
11.00, 19.00, 20.00, 21.00 «Туган көнең белән, Республикам! С Днем рождения, Республика!» 6+
15.00, 18.30, 20.30, 0.00 «Яңалыклар». 12+
15.30 «Туган якка мәдхия». 6+
17.30, 19.30, 0.40 «Татарлар». 12+
18.00 «Болгар радиосы» бәйрәм концерты. 6+
21.30 Опера «Кара пулат». 12+

«ЭФИР»

1.15 «Реки России». 12+
2.00, 3.00, 7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
8.30, 23.00 «СВОИ-2». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «УХОДЯЩАЯ НАТУРА». 16+
10.30, 21.00 «ЖЕНА ОФИЦЕРА». 12+
11.30, 17.10 «ПОСЛЕДНИЙ ЯНЫЧАР». 12+
12.30, 18.40 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.45 «ИСТИНА В ВИНЕ». 16+
14.35 «Карамзин. Проверка временем». 12+
15.00 «Не факт». 12+
15.30 «Неизвестный CoVID. Новые вызовы». 12+
16.20 «Сказочный патруль. Хроники чудес».
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 18.20, 23.45 Информационный канал. 16+
21.00 «Время».
21.45 «ЗОЛОТАЯ ОРДА». 16+
22.45 «Большая игра». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 Минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
21.20 «ЕЛИЗАВЕТА». 16+
22.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30 «Пешком...»
7.00 «Другие Романовы». «Есть дар иной, божественный, бесценный...»
7.30, 18.35 «Женщины-викинги».
8.25 Легенды мирового кино.
8.50, 15.35 «ПРИКЛЮЧЕНИЯ ЭЛЕКТРОНИКА».
10.00, 15.00, 19.30, 23.40 Новости культуры.
10.15 «Абрам да Марья».
11.10 Муз/ф «Эти невероятные музыканты, или Новые сновидения Шурика».
12.20, 20.30 Абсолютный слух.
13.05, 21.45 «БЕРЕГ ЕГО ЖИЗНИ».
14.10 «Хозяйки Удоры».
15.05 «Эрмитаж».
16.45 «Школа будущего». «Мир без учителя?»
17.15 Марафон «Звезды XXI века». Александр Малофеев.
19.45 «Библейский сюжет».
20.15 «Спокойной ночи, малыши!»
21.15 «Запечатленное время».
22.55 «Владимир Котляков. Время открытий».

«НТВ»

4.55 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.50 «Сегодня».
8.25, 10.35 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. ОСОБОЕ ЗАДАНИЕ». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
19.50 «КАНЦЕЛЯРСКАЯ КРЫСА». 16+
21.50 «РИКОШЕТ». 16+

Чәршәмбе

31 август
«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35, 14.45 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00, 17.00 «СӨЮЛӘРЕМ СИНЕ ХАК МИНЕМ». 12+
10.00, 23.30 «ЛЮБОПЫТНАЯ ВАРВАРА 3». 12+
11.00, 0.40 «Каравай». 6+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00, 22.10 «АЙ ТУЛГАНДА». 16+
13.30 «Татар халык җырлары».
14.00 «Азбука долголетия». 6+
14.15 «Если хочешь быть здоровым...» 12+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә».
16.00 «Казаннан - казанга». 12+
18.00 «Халкым минем...» 12+
19.00 «Таяну ноктасы». 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112». 16+
20.15 «Туган авылым». 6+
21.00, 0.15 «Соотечественники». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05, 8.40, 23.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00, 13.00 «Манзара». 6+
8.00, 17.00, 21.25, 0.15 «РӘХӘТ ЯШИБЕЗ!» 12+
9.40 «Ачыктан - ачык». 12+
10.30 «Туган авылым». 6+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05 «Йөрәктән-йөрәккә». Искәндәр Гыйләҗев турында телеочерк. 6+
15.30 «Яшьләр тукталышы». 12+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
18.20, 22.20 «АЙ ТУЛГАНДА». 16+
19.10, 21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
20.00 «Таяну ноктасы». 16+
20.30 «Юлчы». 6+

«ЭФИР»

1.15, 14.35 «Карамзин. Проверка временем». 12+
2.00, 3.00, 7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
8.30, 23.00 «СВОИ-2». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «УХОДЯЩАЯ НАТУРА». 16+
10.30, 21.00 «ЖЕНА ОФИЦЕРА». 12+
11.30, 17.10 «ПОСЛЕДНИЙ ЯНЫЧАР». 12+
12.30, 18.40 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.45 «ИСТИНА В ВИНЕ - 2». 12+
15.00 «Это лечится». 12+
15.30 «Экспедиция в прошлое». 12+
16.15 «Сказочный патруль. Хроники чудес».
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 18.20, 23.45 Информационный канал. 16+
21.00 «Время».
21.45 «ЗОЛОТАЯ ОРДА». 16+
22.45 «Большая игра». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 Минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
21.20 «ЕЛИЗАВЕТА». 16+
22.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30 «Пешком...»
7.00 «Другие Романовы». «Прощание с патриархом».
7.30 «Женщины-викинги».
8.25 Легенды мирового кино.
8.50, 15.35 «ПРИКЛЮЧЕНИЯ ЭЛЕКТРОНИКА».
10.00, 15.00, 19.30, 23.40 Новости культуры.
10.15 «Десять колец Марины Цветаевой».
11.10 XX век. «В мире животных. Театр зверей им В.Л. Дурова». Ведущий Николай Дроздов.
12.10 Цвет времени. Илья Репин. «Иван Грозный и сын его Иван».
12.20, 20.30 Абсолютный слух.
13.05, 21.45 «БЕРЕГ ЕГО ЖИЗНИ».
14.15 «Я Гамлета играю для себя...»
15.05 «Эрмитаж».
16.45 «Школа будущего». «Школа идёт к вам».
17.15 Марафон «Звезды XXI века». Каталин Кокаш, Айлен Притчин, Гайк Казазян, Даниил Коган, Александр Земцов, Андрей Усов, Борис Андрианов, Анна Кошкина.
18.25 «Рассвет жемчужины Востока».
19.45 «Библейский сюжет».
20.15 «Спокойной ночи, малыши!»
21.15 «Запечатленное время».
22.50 «Дитмар Розенталь. Человек-грамматика».

«НТВ»

4.55 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.50 «Сегодня».
8.25, 10.35 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. РУБЕЖИ РОДИНЫ». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
19.50 «КАНЦЕЛЯРСКАЯ КРЫСА». 16+
21.50 «РИКОШЕТ». 16+

Пәнҗешәмбе

1 сентябрь
«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35, 14.45 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00, 17.00 «СӨЮЛӘРЕМ СИНЕ ХАК МИНЕМ». 12+
10.00, 23.10 «ЛЮБОПЫТНАЯ ВАРВАРА 3». 12+
11.00, 0.40 «Каравай». 6+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00, 22.10 «СӨЮ КӨТӘ ЙӨРӘК». 12+
13.00 «Кәмит Җәвит». 16+
14.00 «Здоровая семья: мама, папа и я». 6+
14.15 «Фолиант в столетнем переплёте». 12+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә».
16.00 «Казаннан - казанга». 12+
18.00 «Юлчы». 6+
19.00, 20.00 «Точка опоры». 16+
21.00 «Ватандашлар». 12+
22.00 «Вызов 112». 16+
23.50 «Видеоспорт». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00, 13.00 «Манзара». 6+
8.00, 17.00, 21.25, 0.15 «РӘХӘТ ЯШИБЕЗ!» 12+
8.40, 23.05 «Кәмит Җәвит». 16+
9.40 «Кунак БИТ Шоу». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05 «Йөрәктән-йөрәккә». Бакый Урманче турында телеочерк. 6+
15.30 «Халкым минем». 12+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
18.20, 22.20 «АЙ ТУЛГАНДА». 16+
19.10, 20.00, 21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+

«ЭФИР»

1.15, 14.35 «Ученые люди». 12+
2.00, 3.00, 7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
8.30, 23.00 «СВОИ-2». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30 «УХОДЯЩАЯ НАТУРА». 16+
10.30, 21.00 «ЖЕНА ОФИЦЕРА». 12+
11.30, 17.10 «ПОСЛЕДНИЙ ЯНЫЧАР». 12+
12.30, 18.40 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.45 «ИСТИНА В ВИНЕ - 2». 12+
15.00 «Клинический случай». 12+
15.30 «Экспедиция в прошлое». 12+
16.15 «Джинглики».
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
20.00 «ЧУДОТВОРЕЦ». 12+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 18.20, 23.45 Информационный канал. 16+
21.00 «Время».
21.45 «ЗОЛОТАЯ ОРДА». 16+
22.45 «Большая игра». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 Минут». 12+

14.55 «Кто против?» 12+
21.20 «ЕЛИЗАВЕТА». 16+
22.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30 «Пешком...»
7.00 «Другие Романовы». «Легенда об Анастасии».
7.30, 18.35 «Человек - это случайность? Что заставило мозг расти».
8.25 «Первые в мире».
8.45, 15.35 «ВЫШЕ РАДУГИ».
10.00, 15.00, 19.30, 23.40 Новости культуры.
10.15 «Владимир Котляков. Время открытий».
11.00 XX век. «И то же в Вас очарованье... Иван Козловский».
12.20 Абсолютный слух.
13.00, 21.35 «ПЕРЕВОД С АНГЛИЙСКОГО».
15.05 «Эрмитаж».
16.50 «Школа будущего». «Большая перемена».
17.20 Марафон «Звезды XXI века». Российский национальный оркестр. Дмитрий Матвиенко, Никита Борисоглебский.
18.25 Цвет времени. Микеланджело Буонарроти. «Страшный суд».
19.45 Большие и маленькие.

«НТВ»

4.55 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.50 «Сегодня».
8.25, 10.35 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. РУБЕЖИ РОДИНЫ». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
19.50 «КАНЦЕЛЯРСКАЯ КРЫСА». 16+
21.50 «РИКОШЕТ». 16+

Җомга

2 сентябрь «ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35, 14.45 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00, 17.00 «СӨЮЛӘРЕМ СИНЕ ХАК МИНЕМ». 12+
10.00 «Йөрәктән - йөрәккә». 6+
11.00 «Нәсыйхәт». 6+
11.30 «Татарлар». 12+
12.00, 22.10 «СӨЮ КӨТӘ ЙӨРӘК». 12+
13.00 «Башваткыч». 12+
14.00 «Актуальный ислам». 6+
14.15 «Классный час». 12+
15.15 «Тизрәк! Алга! Җитезрәк!» һәм «Алты хәреф».
16.00 «Аулак өй». 6+
16.30 «Әдәби хәзинә». 6+
18.00 «Туган җир». 12+
19.00 «Болгар радиосы» концерты. 6+
20.00, 22.00 «Вызов 112». 16+
20.15 «Кучтәнәч».
21.00 «Юлчы». 6+
23.00 «ОТДАМ ЖЕНУ В ХОРОШИЕ РУКИ». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00, 13.00 «Манзара». 6+
8.00, 17.00, 21.25, 0.15 «РӘХӘТ ЯШИБЕЗ!» 12+
8.40, 23.05 «Ком сәгате». 12+
9.40, 15.30 «Нәсыйхәт». 6+
10.30 «Казаннан казанга». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30 «Татарлар». 12+
12.05 «Күңелем назлары җырымда чагыла...» Флера Сөләйманова турында телеочерк. 6+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
17.30 «Калеб». 6+
18.20, 22.20 «АЙ ТУЛГАНДА». 16+
19.10 «Туган җир». 12+
19.35 «Заман көзгесе». 6+
20.05, 21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+

«ЭФИР»

1.15 «Ученые люди». 12+
2.00, 3.00, 7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
8.30, 23.00 «СВОИ-2». 16+
9.25, 11.25, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ЧУДОТВОРЕЦ». 12+
10.30 «ЖЕНА ОФИЦЕРА». 12+
11.30, 17.10 «ПОСЛЕДНИЙ ЯНЫЧАР». 12+
12.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00, 23.45 «НОВЫЕ ПРИКЛЮЧЕНИЯ АЛЛАДИНА». 12+
15.00 «Не факт». 12+
15.30 «Экспедиция в прошлое». 12+
16.15 «Джинглики». 6+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
18.30 «Fam TV». 16+
21.00 «СЕДЬМАЯ РУНА». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15 Информационный канал. 16+
18.40 «Человек и закон». 16+
19.45 «Поле чудес».
21.00 «Время».
21.45 «Клуб Веселых и Находчивых». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.15 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 Минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
21.30 «Ну-ка, все вместе!» 12+
23.40 «Улыбка на ночь». 16+

«КУЛЬТУРА»

6.30 «Пешком...»
7.00 «Другие Романовы». «Теория разумного эгоизма».
7.30 «Хозяйки Удоры».
8.15 Легенды мирового кино.
8.40, 15.35 «ВЫШЕ РАДУГИ».
10.00, 15.00, 19.30, 23.30 Новости культуры.
10.20 «ПЕРВОКЛАССНИЦА».
11.30 Острова. Илья Фрэз.
12.15 Абсолютный слух.
13.00 «ПЕРВОЕ СВИДАНИЕ».
14.30 «Беларусь. Несвижский замок».
15.05 Письма из провинции. Великий Новгород.
16.50 «Школа будущего». «Школа без звонка».
17.20 Цвет времени. Иван Мартос.
17.35 Всероссийский конкурс молодых композиторов «Партитура».
19.45 «Смехоностальгия».
20.15 Искатели. «Говорящие мумии Чегемского ущелья».
21.00 Линия жизни. Надежда Бабкина.
21.55 «ОСЕНЬ».
23.50 Памяти Татьяны Москвиной. «Критик».

«НТВ»

4.55 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00 «Сегодня».
8.25, 10.35 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. РУБЕЖИ РОДИНЫ». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.45 «ДНК». 16+
17.55 «Жди меня». 12+
19.50 «КАНЦЕЛЯРСКАЯ КРЫСА». 16+
21.50 «РИКОШЕТ». 16+
23.50 «Своя правда». 16+

Шимбә

3 сентябрь «ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
6.00 «Йөрәктән - йөрәккә». 6+
7.00 «Сиңа Миннән Сәлам». 6+
9.00 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
10.00 «Кайнар хит». 12+
11.00 «Татар халык җырлары».
11.30 «Казаннан - казанга». 12+
12.00 «Каравай». 6+
12.30 «Видеоспорт». 12+
13.00 Хоккей. «Динамо» (Москва) - «Ак Барс». 6+
15.30 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 12+
16.00 «Мин бәхетле». Ришат Төхфәтуллин концерты. 6+
18.00 «Кәмит Җәвит». 16+
19.00 «Халкым минем...» 12+
19.30, 21.30 Новости в субботу. 12+
20.00 «Адымнар». 12+
20.30 «Җырлыйк әле!» 6+
22.00 «КунакБит- шоу». 12+
23.00 «УЧИТЕЛЬ АНГЛИЙСКОГО». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00 «Идрис Газиев тәкъдим итә. Габәши язмышы». 6+
7.00, 15.00 «Сиңа Миннән Сәлам». 6+
9.00 «Кәмит Җәвит». 16+
10.00 «Кайнар хит». 12+
11.00, 18.15 «Башваткыч». 12+
12.05, 19.05 «Җырлыйк әле!» 6+
13.00 «УКСЕЗЛӘР». 12+
14.30 «Җырлап яшик, туганнарым!» Георгий Ибушев концерты. 6+
17.10 «Казаннан казанга». 12+
17.45 «Халкым минем». 12+
20.00 «Адымнар». 12+
20.30 «Элэктегезме?..». «Мунча ташы» спектакле. 12+
23.30 «Яратып яшик». Раяз Фасихов концерты. 12+

«ЭФИР»

5.00 «Тайны анатомии». 12+
5.30 «Ученые люди». 12+
6.30 «Клинический случай». 12+
7.00 «Катя и Эф. Куда-Угодно-Дверь».
7.30 «Лео и Тиг».
8.00 «Путеводитель по вселенной». 12+
8.25 «Вокруг света во время декрета». 12+
8.50 «ТРОЕ В ЛИФТЕ, НЕ СЧИТАЯ СОБАКИ». 12+
10.25 «МЫШЕЛОВКА НА ТРИ ПЕРСОНЫ». 12+
12.00, 20.00 «Fam TV». 16+
12.30, 20.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00 «УДАЧА ЛОГАНА». 16+
15.00 «Инвиво». 12+
15.30 «90-Е. ВЕСЕЛО И ГРОМКО». 16+
19.00 «Город». 16+
21.00 «КОРОЛЬ РАДБОД. ПОСЛЕДНИЙ ВИКИНГ». 16+
23.40 «КОГДА ЗОВЕТ СЕРДЦЕ 5». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

6.00 «Доброе утро. Суббота».
9.45 «Слово пастыря».
10.00, 12.00, 18.00 Новости.
10.15 «Поехали!» 12+
11.10, 12.15 «Видели видео?»
13.55 «ЖЕНЩИНЫ».
15.55 «Дети Третьего рейха». 16+
18.20 «Батальон «Пятнашка». На стороне добра». 16+
19.10 «Сегодня вечером». 16+
21.00 «Время».
21.35 «ТОБОЛ». 16+
23.30 «Петр Первый. «...На троне вечный был работник». 12+

«РОССИЯ»

5.00 «Утро России. Суббота».
8.00 Вести. Местное время.
8.20 Местное время. Суббота.
8.35 «По секрету всему свету».
9.00 «Формула еды». 12+
9.25 «Пятеро на одного».
10.10 «Сто к одному».
11.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.55 «Доктор Мясников». 12+
13.00 «ВМЕСТО НЕЁ». 16+
18.00 «Привет, Андрей!» 12+
21.00 «ТРИ ДЕВИЦЫ». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30 «Библейский сюжет».
7.05 Мультфильмы.
7.50, 23.10 «ТАНЯ».
9.45 «Мы - грамотеи!»
10.25 Неизвестные маршруты России. «Северная Осетия. Легенды Дигории».
11.05 «МЫ С ВАМИ ГДЕ-ТО ВСТРЕЧАЛИСЬ».
12.40 Земля людей. «Долганы. Откуда дует ветер».
13.10 Черные дыры. Белые пятна.
13.50 «Великие мифы. Одиссея».
14.20 «Большой Барьерный риф - живое сокровище».
15.10 «Рассказы из русской истории». Владимир Мединский.
16.05 «КРАСАВЕЦ-МУЖЧИНА».
18.10 «Энциклопедия загадок».
18.40 Рамон Варгас и солисты музыкального театра «Геликон-опера» под руководством Д. Бертмана на VII Международном фестивале искусств П.И. Чайковского в Клину.
20.05 «ПОСЛЕДНЕЕ МЕТРО».
22.15 «Тулуз-Лотрек. Наперегонки со временем».

«НТВ»

5.05 «Путь к победе. Деньги и кровь». 16+
5.55 «ДЕЛЬТА. ПРОДОЛЖЕНИЕ». 16+
7.30 «Смотр».
8.00, 10.00, 16.00 «Сегодня».
8.20 «Поедем, поедим!»
9.20 «Едим дома».
10.20 «Главная дорога». 16+
11.00 «Живая еда». 12+
12.00 «Квартирный вопрос».
13.00 «Секрет на миллион». 16+
15.00 «Своя игра».
16.20 «Следствие вели...» 16+
19.00 «Центральное телевидение».
20.10 «Шоу Аватар». 12+
23.00 «Ты не поверишь!» 16+

Якшәмбе

4 сентябрь «ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 16+
6.00 «Казан нуры» халык уен кораллары оркестры юбилей концерты. 6+
8.00, 13.00 «Адымнар». 12+
8.30 «Туган авылым». 6+
8.45 «Әти һәм мин».
9.15 «Тамчы- шоу».
9.45 «Яшьләр тукталышы». 12+
10.15 «Ачыктан - ачык». 12+
11.00 «Бир кулыңны». Зәлфирә һәм Алмаз Мирзаяновлар концерты. 6+
12.00 «Каравай». 6+
12.30 «Закон. Парламент. Общество». 12+
13.30 «Халкыбыз мирасы». Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбле концерты. 6+
16.00 «Ком сәгате». 12+
17.00 «Видеоспорт». 12+
17.30 «Соотечественники». 12+
18.00 «Башваткыч». 12+
19.00, 22.00 «Семь дней». 12+
20.00 «Заман көзгесе». 6+
20.30 «Болгар радиосы» концерты. 6+
21.00 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
23.00 «СИБИРСКИЙ ЦИРЮЛЬНИК». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05, 12.35 «Халкым минем». 12+
5.30 «Нәсыйхәт». 6+
6.00 «Заман көзгесе». 6+
6.30 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 12+
7.00 «КӨТЕГЕЗ, БЕЗ КИЛӘБЕЗ». 12+
8.50, 23.25 «Шаян хәлләр». 12+
9.15 «Йөрәктән-йөрәккә». Рәшит Абдуллин турында телеочерк. 6+
10.15 «Туган авылым». 6+
10.30 «Калеб». 6+
10.55 «Бердәм булыйк». 6+
11.10 «Тамчы-шоу». 6+
11.45 «Бергәләп өйрәник». 6+
12.05, 0.40 «Яшьләр тукталышы». 12+
13.00 «Зур туган көн концерты». Гөлназ Сәфәрова. 6+
14.45 Спектакль «Яшь йөрәкләр».
17.15 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
18.10 «Кәмит Җәвит». 16+
19.05, 23.45 «Ком сәгате». 12+
20.00 «Семь дней». 12+
21.10 «Халкыбыз мирасы». Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбле концерты. 6+

«ЭФИР»

5.00 «Тайны анатомии». 12+
5.30 «Ученые люди». 12+
6.30 «Не факт». 12+
7.00 «Катя и Эф. Куда-Угодно-Дверь».
7.30 «Лео и Тиг».
8.00 «Инвиво». 12+
8.30 «90-Е. ВЕСЕЛО И ГРОМКО». 16+
12.00, 20.00 «Fam TV». 16+
12.30, 20.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00 «КОРОЛЬ РАДБОД. ПОСЛЕДНИЙ ВИКИНГ». 16+
15.50 «ТРОЕ В ЛИФТЕ, НЕ СЧИТАЯ СОБАКИ». 12+
17.25 «МЫШЕЛОВКА НА ТРИ ПЕРСОНЫ». 12+
19.00 «Город». 16+
21.00 «УДАЧА ЛОГАНА». 16+
23.00 «ОТКРЫТЫЕ ОКНА». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.35, 6.10 «ЗА ДВУМЯ ЗАЙЦАМИ».
6.00, 10.00, 12.00 Новости.
7.00 «Играй, гармонь любимая!» 12+
7.40 «Часовой». 12+
8.10 «Здоровье». 16+
9.20 «Непутевые заметки». 12+
10.15 «Матильда Кшесинская. Прима императорской сцены». 12+
11.20, 12.15 «Видели видео?»
14.05 «Георгий Жженов. «Вся моя жизнь - сплошная ошибка». 12+
15.00 «ОШИБКА РЕЗИДЕНТА». 12+
17.40 «Свои». 16+
19.05 «Голос 60+». 12+
21.00 «Время».
22.35 «ДВЕ ЖИЗНИ ПОЛКОВНИКА РЫБКИНОЙ». 12+

«РОССИЯ»

5.30 «САМОЕ ГЛАВНОЕ». 12+
7.15 «Устами младенца».
8.00 Местное время. Воскресенье.
8.35 «Когда все дома с Тимуром Кизяковым».
9.25 «Утренняя почта с Николаем Басковым».
10.10 «Сто к одному».
11.00, 17.00 Вести.
11.55 «Большие перемены».
13.00 «ВМЕСТО НЕЁ». 16+
18.00 «Песни от всей души». 12+
20.00 Вести недели.
22.00 Москва. Кремль. Путин.
22.40 «Воскресный вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30 «Энциклопедия загадок».
7.05 Мультфильмы.
7.35 «КРАСАВЕЦ-МУЖЧИНА».
9.40 «Обыкновенный концерт».
10.05 Диалоги о животных.
10.50 Большие и маленькие.
12.35 «Игра в бисер» «Поэзия Юрия Ряшенцева».
13.20 «Элементы» с Александром Боровским».
13.50 Больше, чем любовь.
14.30 Торжественная церемония вручения Премии Евгения Евтушенко «Поэт в России - больше, чем поэт».
16.15 «Первые в мире».
16.30 «Картина мира с Михаилом Ковальчуком».
17.10 «Пешком...»
17.40 Передача знаний.
18.30 К 100-летию со дня рождения Кирилла Молчалова. «Романтика романса».
19.30 Новости культуры.
20.10 «НЕОКОНЧЕННАЯ ПЬЕСА ДЛЯ МЕХАНИЧЕСКОГО ПИАНИНО».
21.50 «Испания. Тортоса».
22.20 «СЁГУН».
23.55 «Леонардо. Шедевры и подделки».

«НТВ»

5.15 «ДЕЛЬТА. ПРОДОЛЖЕНИЕ». 16+
6.50 «Центральное телевидение». 16+
8.00, 10.00, 16.00 «Сегодня».
8.20 «У нас выигрывают!» 12+
10.20 «Первая передача». 16+
11.00 «Чудо техники». 12+
11.55 «Дачный ответ».
13.00 «НашПотребНадзор». 16+
14.00 «Однажды...» 16+
15.00 «Своя игра».
16.20 «Следствие вели...» 16+
18.00 «Новые русские сенсации». 16+
19.00 Итоги недели.
20.10 «Ты супер!» 6+
22.50 «Звезды сошлись». 16+

Самара төбәгендә татарларның Идел Болгарстаны заманнарында ук яшәве, соңрак Алтын Урда составында гомер кичерүләре мәгълүм. Бу хакта археологик истәлекләр дә сөйли. Самара өлкәсендә 2700 дән артык археологик һәйкәлләр булуы билгеле. Әйтик, «Татарика» энциклопедиясе мәгълүматларына караганда, Ставрополь районы Валы авылы янында Идел буе Болгар дәүләтенең көньяк чикләрендәге зур һөнәрчелек үзәге һәм чик буе ныгытмасы – монголларга кадәрге чор Болгар шәһәрлеге (Муром шәһәрчеге), Похвистнево районында Зур Кенәл елгасы ярында XIII–XIV йөзләрдәге зур сәүдә-һөнәрчелек Болгар авылы – Коры Елга авыллыгы, Сызрань районының Междуреченск һәм Үрнәк поселоклары янында Алтын Урда чоры Междуреченск шәһәрлеге сакланган.

Төбәк тарихын – мәктәпләргә!

XVI йөзнең икенче яртысында хәзерге биләмәләрнең төньяк-көнчыгыш өлешендә беренче йомышлы татарлар яшәгән авыллар – Гали, Камышлы, Татар Байтуганы һәм Тупли барлыкка килә.

Иске Кама арьягы (1652–1656) һәм Яңа Кама арьягы (1732–1735) чик буе киртәләре төзелә

башлау белән, татарлар Идел арьягының төньяк районнарын үзләштерә башлый. Монда Казан һәм Сембер өязләреннән хәрби хезмәттәге йомышлы татарлар һәм шулай ук кальга һәм дошманнан саклану корылмаларын төзүдә катнашучы ясаклы татарлар килеп урнаша.

Төньяк районнардагы күпчелек татар авылларына XVIII йөз ахырында – XIX йөз башында, Идел елгасының сулъяк ярындагы буш җирләргә Алатыр, Касыйм, Кормыш һәм Пенза өязләреннән татарлар күпләп күчә башлаган елларда нигез салына. 1798 елда Бөгелмә өязендә – 97, Богырысланда 30 татар авылы (Абдулла Заводы, Камышлы, Кармалы-Гадиләк, Иске Шалты, Шалты Пүчинкәсе һ.б.) исәпләнә.

Бозаулык өязенең көньяк-көнчыгыш өлешендә татарлар Әхмәр, Биккол, Бозаулык Үре, Медведок, Мөлек, Сәет һәм Иске Белогор авылларына нигез сала. XIX йөз уртасыннан Пенза, Саратов һәм Тамбов губерналарыннан күченгән татарлар Самарадагы Идел арьягының көньяк районнарына (Николаевка һәм Яңа Үзән өязләре) урнаша. Самара өлкәсендә бүген дә татарлар күпләп яши. Биредә милләттәшләребез тарафыннан татар һәм рус телләрендә «Самара татарлары» дигән саллы журнал, «Бердәмлек» газетасы нәшер ителә, данлыклы «Яктылык» мәктәбе эшли. Самара өлкәсендә «Болгар мирасы» дигән тарихи-мәдәни фонд та оештырылган.

Шушы көннәрдә Бөтендөнья татар конгрессының конференцияләр залында Самара өлкәсе һәм Питрәч районы тарихчыларының китаплары тәкъдим ителде. Анда Самара өлкәсеннән галимнәр, тарихчылардан торган зур делегация һәм Питрәч районы башлыгы Илһам Кашапов җитәкчелегендә килгән укытучылар, мәктәп директорлары, авыл җирлеге җитәкчеләре катнашты.

Татарстанның «Татар төбәкчеләре» оешмасы рәисе Альберт Борһанов ачыклап үткәнчә, Идел Болгарстанында ислам динен рәсми кабул ителүнең 1100 еллыгы уңаеннан 1 сентябрьдә Самарада беренче фәнни-мемориаль комплекс ачу планлаштырыла. Шушы чара алдыннан журналист һәм язучы Владимир Ерховның «Возвращение к истокам» («Үткәннәргә кайту») дигән әдәби-тарихи очерклар китабын тәкъдим итәргә ниятләгәннәр. Очрашу исә Самара өлкәсендә булдырылган «Болгар мирасы» дигән тарихи-мәдәни фонд һәм Питрәч районы җитәкчеләре тәкъдиме белән оештырылган.

Самарада нәшер ителгән басмада Идел Болгарстаны, Алтын Урда составындагы болгар җирләрендә яшәгән татар халкы тарихы зур урын алып тора. Әдәби-тарихи очерклар жанрында язылган китапта урта гасыр чорында Урта Идел буйларында яшәгән милләттәшләребезнең тамырлары, яшәешләре һәм язмышлары Батыршиннар нәселе мисалында тәгаенләнә. «Болгар мирасы» фонды директоры Гүзәл Сәгадәтова китап тарихыбызны саклауга һәм яшьләрдә ватанпәрвәрлек хисләре тәрбияләүне максат итүен искәртте.

Самарада төбәкне татар тарихы юнәлешендә өйрәнү бер гасыр элек үк барлыкка килгән. Авыллар тарихы буенча аерым мәкаләләр, китаплар чыккан. Химаячеләр советы рәисе Гомәр Батыршин фондның 15 еллар элек төзелүе турында әйтте. Аларның тырышлыгы белән туган як тарихын таныту, аны популярлаштыру ниятеннән Ширяево авылында стела куелган, берничә ел элек Идел Болгарстанының көньяк чикләренә куелган биек постаменттагы ике метрлы Ак барс сыны да һәркемнең игътибарын җәлеп итә. Хәзерге вакытта өлкә олимпиадасын үткәрү мәшәкате белән йөриләр.

Самара төбәгенең тарихчы галиме Шамил Галимов Самара татарлары тарихына багышлап язылган монография, аңа кергән тарихи этнографик очерклар турында сөйләде. Хезмәтнең күләме 600 бит, анда татар җирләре турында тарихи мәгълүматлар бирелгән.

Илһам Кашапов XVII гасыр уртасында яшәгән Мәүлә Колый мирасын аның туган җире – Питрәч районында саклауга багышланган проектлар турында бәян итте. Суфи шагыйрь әсәрләрендәге идеяләр бүгенге көн өчен дә актуаль. Аның иҗатында игенченең намуслы хезмәте – үсеш һәм муллык нигезе булуы, суфичылык, милләтара тынычлык – төп темалар булып тора.

2021 ел азагында М.Колыйга багышланган «Питрәч районы һәм Мишә елгасы буйлары: үткәннән - бүгенгә кадәр» беренче Питрәч фәнни-төбәк тарихын өйрәнү укулары, ә быелның апрель аенда бөтенроссия фәнни-гамәли конференциясе үтүе турында язган идек инде.

«Унҗиденче гасыр шагыйре Мәүлә Колый» (Камил Дәүләтшинның уку әсбабы); «Мәүлә Колый. Хикмәтләр» (төзүче Мәсгут Гайнетдин); «Мәүла Колый поэмалары» (төзүче Рәиф Мәрдәнов)» дигән китаплар яңадан басылып чыгуы, Чытыда алты метр биеклектәге стелага нигез салыну, мәчеткә М.Колый исеме бирелү, авылга керү юлында киләчәк буыннарга мөрәҗәгать белән капсула куелу бу гыйльми җыеннарның күркәм нәтиҗәсе булды. Хәзерге вакытта Чытыда тирәлекне, Мишә яр буен төзекләндерү һәм ямьләндерү, булачак монумент һәм бакча урынында грунтны күтәрү эшләре бара. М.Колый исемендәге туган якны өйрәнү музее да этнотуризмның әһәмиятле бер ноктасы булачак. Моннан тыш ачык һавада борынгы татар авылының тормыш-көнкүрешен чагылдырган музей проектын да тормышка ашыру күз алдында тотыла. Шушы көннәрдә исә «Уроженец Пестречинской земли Мауля Колый: жизнь, деятельность, наследие и его вклад в духовно-культурную жизнь татарского народа» дигән саллы җыентык та дөнья күргән. Анда 100 гә якын мәкалә урнаштырылган. Утырышта Россия дәреслекләрендә татарлар бик чамалы чагылдырылуы, мәктәпләрдә Татарстан һәм төбәк тарихларына урын бик аз бирелү кебек мәсьәләләр дә күтәрелде. Тарихчы-галим Дамир Исхаков тарихыбызны балаларга нинди юллар белән сеңдерергә тиешлегебез турында искәртте. Хәзер борынгы төрки чор буенча әһәмиятле материаллар тупланган. Татар тарихының беренче томын яңадан язу сорала. Галим төбәкчелек белән шөгыльләнгәндә гомуми академик тарих кысасында эшләү әһәмиятле булуын искәртте. Чөнки аны фундаменталь белемле галимнәр эшли.

Д.Исхаков А.Борһанов һәм аның тарафдарлары шөгыльләнгән хәрәкәтне Россия күләмендә формалаштырырга тәкъдим итте. «Татар булмаган урын Россиядә юк. Безнең 400 дән артык оешмабыз бар. Алар бер йодрыкка тупланган булырга тиеш. Россиядә «Российское историческое общество» бар. Татарларның да шундый җәмгыятен булдыру кирәк. Без аны төбәкчеләр хәрәкәте аша формалаштыра алабыз. Вакыт-вакыт җыелып, фикерләрне уртага салып киңәшү дә сорала, кирәк вакытта сүз дә әйтергә тиешбез. Кайбер вакыйгалар күз алдында була, без аңа үз вакытында бәя бирә алмыйбыз», - диде галим. Ул Самара өлкәсендә Аксак Тимергә һәйкәл куярга омтылыш ясаулары вакыйгасын искә төшерде. Белгәнебезчә, Аксак Тимер - татар тарихында бик тискәре фигура. Ул Алтын Урданы – безнең бөек империяне җимерүчеләрнең берсе. Әмма безнең дус булып саналган үзбәк халкы аңа Самара өлкәсендә һәйкәл куймакчы иде. Бериш Самара татарлары башта аптырап калды, арада хәтта яклап чыгучылар да булды. «Әле ярый татарлар арасында аңлылар күбрәк. Без проектны капладык, Аксак Тимер Россия эченә үтеп керә алмады», - диде Д.Исхаков. – Ул русларга карата да начар гамәлләр кылган шәхес. Руслар арасында да аңлаучылар булды. Шуңа күрә тарих белән шөгыльләнгәндә, киңрәк караш кирәк, тарихның сәяси ягын да онытырга ярамый».

Саба районы төбәкчесе Илдар Сафин, район тарихы дәреслеген язган кеше буларак, Татарстан тарихы да мәктәпләрдә ел дәвамында нибары ун сәгатькә генә калдырылуын әйтеп, Питрәч районы тарихы дәреслеген язарга кирәклеген белдерде. «Шушы дәреслекләрне Саба, Питрәч районнары гына түгел, барлык районнарда, расписаниегә кертеп, төбәк, район тарихларын укыта башларга кирәк. Балык Бистәсендә, Чистайда бу эш алып барылды. Мәктәпләрдә төбәк тарихын укыту өчен мөмкинлекләр бар. Әйтик, бишенче сыйныфта – дүрт, алтынчыда биш сәгать дәрестән тыш вакыт бирелгән. Аны шахмат буенча шөгыльләнү, БДИ га әзерләнү өчен һ.б. алалар. Безгә тарихчыларга, укытучыларга бу вакытны туган як тарихын укыту өчен файдалану кирәк», – диде И.Сафин.

Сөембикә КАШАПОВА.
Автор фотолары.

ИГЕЛЕКЛЕ АЙЗИРӘК

Түбән Каманың сынлы сәнгать укытучысы, рәссам Айзирәк Мостафина 1961 елда мөгаллим Альфа һәм Альберт Фарукшиннар гаиләсендә Свердлов өлкәсенең Түбән Серги районы Шөкер авылында туган. Гаилә 1968 елда Сарман районының Саклаубаш авылына кайтып төпләнә. Ул кыз туганнары Лилия һәм Резеда, ир туганнары Алмаз һәм Нияз белән шушы авылдагы урта мәктәптә белем ала.

«Укытучы баласы буларак, мин һәр укучы өчен үрнәк өлгесе булырга тиеш идем, – дип искә ала рәссам. – Бу, ахрысы, укытучы гаиләсенең һәрберендә искә төшереп торган гадәттер инде. Мин дә шушы юлдан тайпылмадым. Бервакыт үз тормыш юлыңны анализлап чыгарга өйрәтүче укыту-сәламәтләндерү курсына эләккәч, үзем өчен шуны ачыкладым: мин һәрчак алга, якты идеяле көннәргә генә омтылганмын, беркем талантыннан да көнләшмәгәнмен икән бит... Әни без өч кыз балага берәр-берәр кап төсле каләмнәр бирә дә, үзе эшкә китә иде. Әтием дә мәктәп директоры, эшләре күп иде. Рәсем ясарга сәләтем – әниемнән, җырга сәләтем әтиемнән дип саныйм. Без гел рәсем ясауда булдык. Нәтиҗәдә, мин Казан дәүләт төзелеш-инженерия институтының архитектура факультетын сайладым. Ләкин «сопромат», төзелеш физикасы, сызым геометриясе һ.б. белән җәфаланып, очы-кырые булмаган сызымнар сызып, тәмам ардым. Әмма II курстан соң архитектор Ренат Мостафин белән гаилә коргач, барысы да уңай якка үзгәрде дә куйды. Без Чабаксарга күчендек һәм мин укуымны андагы педагогика институтының сынлы сәнгать һәм графика факультетында дәвам иттем. 1988 елда гаиләбез Түбән Кама каласына юл алды. 1988-1992 елларда биредәге 7 нче урта мәктәптә рәссам укытучысы булып эшләдем.

1992 елда мин яңа гына ачылган 2 нче татар гимназиясендә эшли башладым. Һәм менә шунда чын иҗади эшчәнлегем башланды. Балаларга сәнгати белем бирү буенча яңа, прогрессив программаларны гамәлгә керттем. Гимназия карамагындагы сәнгать студиясе өчен, югары сыйныфлар өчен сәнгать буенча авторлык программаны һәм сәнгать мәктәбе буенча авторлык концепциямне төзедем. Балалар белән төрле материаллардан күп әйберләр ясадык, курчак театрын үз итеп, хәтта спектакльләр дә куйдык... Вакытны санамыйча, бирелеп эшләргә туры килде... 10 ел гимназиядә укыттым һәм анары 4 ел дәвамында ишек алды клубы директоры вазифаларын башкарып, балаларны рәссамлык серләренә төшендердем.

Үз балаларыбызның өчесендә дә рәссамлыкка сәләт бар, ләкин аларның һәммәсе дә шушы һөнәрне сайламады. Улыбыз Ирек – пешекче-ресторатор, Гүзәл туризм өлкәсе буенча академия тәмамлап, өч ул үстерә, ә Миләүшәбез Кама дизайн һәм сәнгать институтын тәмамлап, дизайнер һөнәрендә.

2002 елда мин олылар һәм балалар өчен шәхси сәнгать студиямне ачтым. Үзем дә төрле курслар үттем. Хәзер белем күп, аны башкаларга бирергә генә өлгер! Шуңа күрә бүген дә теләге булганнар өчен ун көнлек «Синдә рәссам яши» дип аталган сынлы сәнгать курсларын үткәрәм».

Бу җәйдә Айзирәк Альберт кызының шәхси күргәзмәсе Яр Чаллы үзәк китапханәсендә зур уңыш белән барды, ул анда тамашачылары белән дә очрашырга өлгерде. Рәссамның иң беренче шәхси күргәзмәсе 2013 елда Чаллы картина галереясында ачылган булган. Айзирәк Мостафинаның шәхси күргәзмәләре 2015 елда – Түбән Кама шәһәр музеенда, 2016 елда – Саклаубашта, 2020 елда – Татарстанның халык рәссамы Ә.Фәтхетдинов музеенда, 2021 елда – Түбән Кама сынлы сәнгать мәктәбендә, 2022 елда Кама Аланында да уңыш белән узган. Каланың 55 еллык юбилеена багышланган шәһәр бәйгесендә «Мәктәп бульвары» триптихы белән II урынны яулаган. «Бу шәхси күргәзмәләремне күбрәк үз-үзем алдында хисап тоту дип кабул итәм. Чөнки мин җитди картиналарымны 45 яшем тулгач кына ясый башладым», - ди ул.

Иҗатында майлы буяулар, майлы яки коры пастель каләмнәр, сыек акрил куллана, эбру, монотипия, ботаника барельефларын ясауга, китап бизәүгә өстенлек бирә. Айзирәк ханым ясаган портретларда да без бары тик игелекле йөзләр генә күрәбез, аларның күбесендә ул үз әнисен, балаларын, туганнарын, танышларын сурәтләгән. «Мин һәр мизгел саен рәсем ясарга телим. Бу инде гадәти. Тирә-юнебездәге матурлыкка сокланам һәм аны башка кешеләргә дә җиткерәсем килә! Рәсем ясарга өйрәткәндә башкаларның сәләтләре ачылуын күреп куанам. Моны хәтта бер могҗизага да тиңлим», – диде әңгәмәбез ахырында көләч йөзле рәссам.

Зилә НИГЪМӘТУЛЛИНА.

Мәдәни җомга

ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ – «ТАТМЕДИА» АКЦИОНЕРЛЫК ҖӘМГЫЯТЕ

«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы директоры – баш мөхәррир

Вахит Шәих улы ИМАМОВ

Җаваплы сәркатип Илгизәр ЗӘКИЕВ

Шылтыратыгыз:

222-09-83 (1562) – кабул итү бүлмәсе;
222-05-47 (1560) – җаваплы сәркатип, компьютер үзәге;
222-05-47 (1561) – иҗтимагый-сәяси тормыш, мәгариф һәм фән, сәнгать бүлекләре; хатлар һәм социаль көнкүреш, тәрҗемә бүлекләре;
222-09-84 (1266) – бухгалтерия.

Реклама хезмәте телефоны: (843)222-05-47 (1560)

Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләр өлкәсенә күзәтчелек итү федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2019 елның 9 октябрендә ПИ №ФС 77–76961 нче санлы теркәү таныклыгы алды

Индекс П2355

Авторлар фикере редакция фикере белән аваздаш булмаска да мөмкин

Редакциянең рәсми оешмаларда юллаучы булып йөрү мөмкинлеге юк

Хатлар, кулъязмалар, фотографияләр, рәсемнәргә бәяләмә бирелми һәм алар кире кайтарылмый

© Газетада чыккан материалларны күчереп бастырганда редакциядән язмача рөхсәт алу мәҗбүри

Реклама һәм белдерүләрнең төгәллеге өчен реклама бирүчеләр үзләре җаваплы

Безгә иганәлек ярдәме күрсәтергә теләүчеләр өчен редакциянең исәп-хисап счеты:
ИНН 1655144950 КПП 165802012
ПАО «АК БАРС» банк, г. Казань
р/с 40702810600020010312
к/с 30101810000000000805
БИК 049205805 ОГРН 1021600000124

НӘШЕР ИТҮЧЕ – «ТАТМЕДИА» АҖ

420097, Казан, Академия урамы, 2

Редакция, гамәлгә куючы һәм басмаханәнең адресы:
420066, Казан, Декабристлар урамы, 2
E-mail: m-jomga@mail.ru

«Мәдәни җомга» газетасы Интернетта:
www.madanizhomga.ru

Басмаханә гаебе белән җибәрелгән сыйфат җитешсезлекләре хакында 562-10-61 номерлы телефон буенча шылтыратырга

Газета һәр атнаның җомга көнендә чыга. Бу санның чыгу көне 26.08.2022

График буенча бу санга 15 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 14 сәгать 30 минутта.

«Татмедиа» АҖ филиалы – «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды

Газетаның сатудагы бәясе ирекле

Тираж – 2600 данә

Заказ 2767

16+